
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 ОКТЯБРЬ № 10

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ЯСАЛМА КИРТӘЛӘР

кайдан ярдәм көтәргә

ЭЗЛӘМӘ МИНЕ...

кирегә юл юк

ЗӨЛФИЯ ВӘЛИЕВА СЫЙЛЫЙ:

«Кытай фонарьлары»

Венера БИКМӨХӘММӘТОВА:

— КОМБАЙН ШТУРВАЛЫНДА – КҮҢЕЛЕМ КУШКАНГА...



PRESSA.RU

БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СИНЕҢ БЕЛӘН МӘҢГЕ БЕРГӘ, СӨЕМБИКӘ!..



«Саубуллашу». Фиринат Халиков эше.

Казан ханлыгының соңгы патшабикәсе, фаҗигале язмыш иясе булган Сөембикәнең тууына быел 500 ел.

«Сөен-бикә үзенең матурлыгы илә бөтен Казанда атаклы булдыгы кеби, акыллылыгы илә дә атаклы иде, – дип яза халкыбызның мәгълүм тарихчысы Һади Атласи үзенең «Сөен-бикә» исемле китабында. – Кызганыч, Казан ханлыгы үзе өчен иң кирәкле булган тиңсез бер башлыгын югалтты. Сөен-бикәнең токтын ителүе бер хатынның токтын ителүе булса да, чынлабында, бөтен халыкның токтын ителүе иде. ... озак елларга чаклы Казан кешеләренең күзләреннән яшьләре кипмәде. Казан халкы һәрвакыт Сөен-бикәне искә төшерә, аны сагынадыр иде. Чынлап та, Сөен-бикә сагынырлык хатын иде. Казанның борынгы падишаһлары ханлыкның кайсыдыр сыйныфларын алда тоталар, үзләренең күбрәк багышлауларын шуларга гына багышлыйлар, халыкның күбрәген исә коры калдыралар иде. Сөен-бикә исә алай булмады. Ул, Казан олугъларыны дәрәҗәләрендә карап багышладыгы кеби, Казанның урта һәм түбән дәрәҗәдәгеләрене дә онытмыйдыр, һәркайсына үзенең сыеннан өлеш чыгарадыр иде... Сөен-бикәнең яхшылыклары, кояш нуры кебек, Казан халкының һәрберсен каплаган, һәртөрле кешегә шул яхшылыктан өлеш чыккан иде. ...Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урнашкан булганлыгы өчен, алар Сөен-бикәне тиз генә оныта алмадылар... Ул үзе күңелләрдә калдыгы кеби, аның исеме дә телләрдә калды».

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



10’2016

Директор-баш мљхђррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны	222-09-77
Директор урынбасары	
Рәмзия Кашапова	222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары	
Гөлнур Хәсәншина	222-09-78
Җаваплы сәркатип	
Лариса Маликова	

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Венера Бикмөхәммәтова
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 11.10.2016 ел.
Заказ М-2605.
Тираж 5678.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в ПАО «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002



PRESSA.RU





«Кояш баюга багышланган моң». Анастасия Бузунеева эше.

ШАГЫЙРЬНЕҢ ТУУЫНА – 70 ЕЛ

Мөдәррис ӘГЪЛӘМОВ

Җылы эзләп

Су өсләре, әнә, тимгел-тимгел –
Кабан күле ята шадраланып;
Күксел дулкыннары егылалар
Ярга барып.

Җылы эзләп ярга йөгерәләр,
Йөгергәндәй учак тирәсенә.
Ашыгудан капкан сулышлары,
Күкрәкләре еш-еш күтәрелә.

Җылы эзләп, көзге киңлекләрнең
Канат җилпи барча тарафлары;
Сикерәләр җиргә җылы эзләп
Чаганнарның елгыр яфраклары.

Трамвайга кошлар килеп керә,
Аерылып калган гарип кошлар...
Көз – озату чоры.
Моңсу гына
Озатып кала көзге тукталышлар.

Көз – озату чоры. Торналарның
Канатларын тоя Сөембикә...
Кремльнең ап-ак стенасы
Киноэкран кебек:
Көзге күктә
Нинди кошлар, нинди болыт уза –
Һәммәсен дә тора чагылдырып.
(Хет булмаса, килер буыннарга
Сәер сурәтеңне калдыр, болыт!)

Сүрәнләнә кояш, сүрәнләнә,
Үз-үзенә җәелеп, эреп бара.
Бөтен дөнья ашыга...
Бөтен дөнья
Җылы эзләп кышка кереп бара.

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

12



КОМБАЙНЧЫ ВЕНЕРА
Ә. Самат

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

8



ЭЗЛӘМӘ МИНЕ...
М. Авзалова



ЯСАЛМА КИРТӘЛӘР
Л. Гәрәева

16

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

24



ТОЗ-ТҮБӘ КАРБЫЗЫ
Г. Сафиуллина



28

ТӨП ЙОРТ КИЛЕНЕ
Ә. Мөхәммәтҗанова

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 




38 **КУНАК АПА**
Р. Усманова

ЯШӘЕШ 

42 

БАЛАН ӘЧЕСЕ...
Х. Мөдәррисова




50 **ПРАГА — УЛ ДИАГНОЗ!**
Э. Закирова

ШУЛАЙ УК: 

32 **«ТАНУ – АЛЛАНЫ, БЕЛҮ – ДӨНЬЯНЫ...»**
Н. Гыйматдинова
Р. Зәйдулла

44 **«ҖЫР ИКӘНСЕҢ, ТОРМЫШ...»**
А. Маликова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60 

«АЛТЫН КӨЗ» БРОШКАСЫ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ГОМЕРЛЕК ФАҖИГА. БУЛГАН ХӘЛ

«ӘТИГӘ КИРӘКМИМ, АХРЫСЫ». ЯЗМЫШ

«МИН ЯРАТАМ СИНЕ...» МАРАТ КӘБИРОВ. ХИКӘЯ

ГӨЛНАЗ СӘФӘРОВАДАН МАСТЕР-КЛАСС



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Баулы шәһәрендә Гөлбакча исемле урам бар. Үзәк урамнардан читтәрәк ул. Бу урамның тынлыгын ябалдашларын болытларга терәгән өянкеләр саклый.

Бакчаларның сирәк рәшәткәләре арасыннан узган-барганнарга, җәйнең кай вакыты туры килүгә карап, хуш исле чалмабашлар, куш йодрык чаклы розалар, тыйнак кашкарыйлар елмаеп кала. Бәхетле кешеләр яшидер бу урамда. Андагы бер адрес миңа да таныш. Анда Сәгъдия белән Илгизәр Васиковлар яши. Хәер, ул йортны кем дә белә торгандыр. Чөнки Сәгъдия ханым үзе Баулылар өчен бик дәрәҗәле бер ханым. Ике дистә елдан артык эшләгән соңгы эш урыныннан – Баулы үзәк китапханәсе директоры вазыйфасыннан пенсиягә киткәненә байтак гомер узган булса да, китаплар белән генә түгел, бәлки ул китапларны язган авторлар белән эшләүдә дә гаять бер осталык, фидакарьлек үрнәге булган Сәгъдия Васикованы, Баулы китапханәсен лидерлар рәтенә чыгарган, «Ел китапханәсе» итүгә ирешкән 45 ел стажлы китапханәчене, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрен гади халык та, җитәкчеләр дә бик нык хөрмәт итә. Кичәнең буеннан-буена аягөсте сәхнәдә торып, тылсымлы сүзе белән тамашачыны сихерләп, Сәгъдия ханым үткәргән ул кичәләр әле дә онытылмаган икән. Заманасында Баулы районының җитәкчеләре якташ язучыларга кинәттән генә игътибарлы булып киткәннәр икән, монда да Сәгъдия Васикованың роле зур. Аның иренмәве, тырышлыгы белән Баулының зур залларында Тукай премиясе лауреатлары Фәнис Яруллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Миргазиян Юныс, Рәшит Әхмәтҗанов, Рафаэль Мостафин иҗатлары халыкның – якташларының рухи табынына куелды.

Сүзне ничек итеп әйтәсең, ничек итеп сөйлисең бит аны. Сәгъдия белде. Сүзне дә, сәхнәне дә, китапны да зурлый, уйлаганын уйдырып әйтә белде. Аның хакында хезмәттәшләре: «Сәгъдия апа кичәләр, очрашулар үткәрүгә шулкадәр җаваплы карый иде – һәр чарага яңа киемнән чыгарга тырышты». Беләм аның ул сыйфатын. Баулы хатын-кызлары арасында чалбарлы костюмнар кию модасын да ул керткән иде бугай... Бу хакта үзе сөйләсен әле:

– Сере бар инде аның. Мин бит тугыз яшемә кадәр йөри алмадым. Мәктәпкә дә тугыз яшьтә генә киттем. Тайган аякны табиблар гипска катырып куйганнан соң, ул аягым корый башлаган минем...

Бу урыннан үзем сөйлим әле. Сугышларны йөреп, имгәнеп, ватылып кайткан Кәшфетдин солдат белән кыр станында аш пешереп торучы Кәшифәнең төпчек кызлары көн дә саен капка төбенә чыгып утыра. Күзләрен йөргән-йөгергәннәрдән бер дә алмый кызыкай. Бәхетлеләр! Иң күп йөгергәне Нажия апа икән. Димәк, иң бәхетле кеше дә ул! Югары Оч белән Түбән Оч арасын очып кына үтә бу апа. И-и, аякларым мине тыңлый башласа, мин дә шул апа кебек гел йөгереп йөрер идем, дип хыяллана кызыкай. Нажия апасы Югары Очта китапханәдә эшли, Түбән Очка әнисенең хәлен белергә бара. Көн саен! Сәгъдия дә китапханәче булса, шулай йөгереп кенә йөрер иде микән? Мәктәпне тәмамлагач, Алабугадагы китапханәчеләр училищесына, аннары Казандагы мәдәният һәм сәнгать институтына китергән хыял бу! Ул вакытта теге имгәнгән аяк исән аякка иптәш булырлык кимәлгә килгән, әмма кышкы юлларда туңып җәфалый торган кыска аяк булып калган. Кыз бала өчен фаҗига инде бу дия күрмәгез. Сәгъдия исемле бу кыздагы рухи ныклык бернинди фаҗига, кимлек, бәхетсезлек дигән төшенчәләргә баш бирмәслек дәрәҗәдә. Булганы белән нечкә күңелле чакматаш ул! Һәр яктан да Нажия апасы төсле ул хәзер. Баулыда (Югары Очта) китапханәдә эшли, Томбарлыга (Түбән Очка) әнисе янына «йөгерә». Атна саен! Айлар үтә шулай, еллар үтә, кышкы юлларда өзелеп-өзелеп теге аяк туңа. Иң кызганычы – яшь гомер узып китә. Кәшифәттәйнең дә кызы өчен йөрәге өзелә. Ялгыз кала бит бала. Эшне бит аны үзең белән түшәккә салып булмый. Ул әле һаман кыр станында ашарга пешереп тора. Колхозга шефлык ярдәме белән килгән шофер халкын да күздән яздырмый. Берәве бигрәк кундәм, йомшак күренә, ял иткәндә гармунын да алып утыра. Дуадак адәм икән. Ана тәвәккәлли: «Улым, минем бик юньле кызым бар. Син дә яшь түгел, салырга да яратасың бугай. Кызымның да яше узып бара. Сүзеннән чыкмасаң, кеше итәр ул сине». Теге кыюсыз адәм Илгизәр исемле икән. Кәшифәттәйгә каршы сүз әйтми, чөнки аның үзенең дә

инде күптәннән берәр нык кулга эләгәсе килеп тора. Шуңа күрә ялында кайтып, әнисенең бөтен эшен кырып-себереп эшләп йөргән кызны иплəп кенә күзәтә. Кимчелеген дә абайлап ала. Бер кичне ишегалдында яткан бүрәнәгә утырып гармун сузып җибәргәнен, гармунына кушылып:

Иделләре-Иделләре,
Иделләре-күлләре,
Син – минеке, мин – синеке
Димәдең бит элгәре, – дип

җырлап җибәргәнен сизми дә кала.

Шул көннән башлап бу җырны икәү җырлый башлаганнарына да 33 ел вакыт үтеп киткән икән инде. Инде берданбер кызлары Илсөярнең кызы үсеп килә. Оныкка Солтания дип исем кушканнар. Сәгъдиянең кыз фамилиясе Солтанова булганга күрә онык – Солтания. Нәселдән исем югалмасын өчен.

Шунысы сөенечле: теге биек өянкеләр бу йортның иминлеген генә түгел, соңлап табылган, әмма озын гомерле мәхәббәтне дә саклый. «Бәхетне мин аны үзем табып яшәдем», – дип әйтергә ярата Сәгъдия Васикова.

Асия СӘГЫЙТОВА.
Баулы.



***Авылыбызның иң матур урынын Кави мулла нигезе дип йөртәләр.** Нәфисә абыстай һәм Габделкави Кавиевлар заманында авылда мәктәп ачтырып, балаларны укырга-язарга өйрәткән укымышлы, фидакарь кешеләр.*

Алар мәгърифәтче Каюм Насыйри белән аралашып, аңа туган як тарихын язарга булышалар, һава торышы хакында көндәлек алып баралар. Аларның эшен соңыннан уллары Сәлим (1880–1942) дәвам итә. Ул Казандагы мәдрәсәдә белем алып, үзләренә указлы мулла булып кайта. 1904 елда – 24 яшендә хаҗга бара. Сәяхәт иткән җирләрен картага төшерә. Хаҗдан кайткач, Сәлим Кавиев Яшел Үзән районы Шырдан авылының урта хәлле крестьяны Шәмсетдин кызы Закирәгә өйләнә. 1906 елда беренче балалары Хәмит туа. 1908 елда туган уллары Мәҗит геология фәннәре докторы, Татарстанда геология-нефть разведкасын җитәкли. Алардан соң тагын Мөршидә, Тәлгать, Суфия, Рифкать, Әнвәр (Казан сабын заводында фаҗигале төстә һәлак була), Сәлимә, Шамил дөньяга килә. Аларның кайберләре балачакта ук гүр иясе була. Исән үскәннәрдән дүртесе – Бөек Ватан сугышында катнаша. Иң олы балалары булган Хәмит – фронтовик язучы. Ул Казанда педагогика техникумын, аннан педагогика институтын тәмамлый, аспирантурада укый. Биолог булса да, әдәбиятка тартыла. Бик күп сәяхәт итеп, китаплар бастырып чыгара: «Кавказ таулары аша җәяү», «Боз диңгезгә таба», «Кузбасска сәяхәт» (1934), «Сәяхәт» (1939) – барлыгы унлап китап язып калдырган.

Мех техникумында укытканда Хәмит Кавиев Әтнә районының Нуртәк авылында туып-үскән Мәрьям Хәлилова белән гаилә кора. Беренче сөенечләре – уллары Илдар туа. Гаилә дусты булган Абдулла Алиш еш кына, уены-чынын кушып: «Хәмит дус, нишлим, синең Мәрьямеңә гашыйк булдым бит», – дип әйтергә яраткан. Бик актив кеше була Хәмит абый, техникумда театр студиясе ачып, аны җитәкли. 1939 елда Мәскәүгә кадәр чаңгылы сәяхәт оештыра. Моның өчен аңа Тышкы сәүдә халык комиссары имзасы белән исемле сәгать бүләк итәләр. 1941 елның августында икенче уллары Илгизне алып кайталар. Аңа нибары 40 көн булганда Хәмит Кавины сугышка алалар. «Исән-сау кайтсам, балаларыбыз күп булыр. Аларга «Ил»дән башланган исемнәр кушарбыз», – ди ул хушлашканда.

1943 елда аны Чиләбе шәһәренә танклар алырга җибәрәләр. Юл уңае ул бер-ике сәгатькә генә Казандагы гаиләсе янына кереп чыга. Бу аның кадерле кешеләре белән мәңгегә аерылышу сәгатьләре була. Фотода аларның бергә төшкән бәхетле мизгелләре сурәтләнгән. Мәрьям кулында ике бала, ике әни кала. Әле җитмәсә, көнне төнгә ялгап, тире иләү заводында эшләү.

Ире Хәмит шушы китүдән Идел буеннан илебезнең көнбатыш чикләренә кадәр юл уза. 1944 елның 15 июнендә Көнбатыш Украинаның Волынск өлкәсендәге Дружкополь дигән урында генерал-лейтенант Ватутин армиясе сугышчыларына бандерачылар һөҗүм башлый. Өлкән лейтенант Хәмит Кавиев җитәкләгән танк экипажы да көрәшкә керә. Бандерачылар танкны яндыралар. Кавиев үзенең ике көрәштәшен – Актаныш егетләрен – аскы люк аша чыгарып җибәрә, үзе исә танкны дошман өстенә алып китә. Дөрләп янган танктан чыга алмый инде ул – танк белән бергә 38 яшьлек ябь-яшь ир үзе дә янып үлә. Аның бу батырлыгы маршал Жуковның «Хатирәләр» китабында да искә алына. Хәмит Кави исеме Дружкопольдәге туганнар каберлегендәге мәрмәргә уелган.

Аның улы – геология фәннәре кандидаты Илгиз Кавиев нәсел шәҗәрәсен барлап, китап туплаган. Алар хатыны Камилә Гарифулла кызы белән инде 50 ел матур гаилә булып яши. Шамил һәм Рәшит исемле уллар үстергәннәр. Оныклары Әмир әлегә армия хезмәтендә.

Укытучы, язучы, танкист Хәмит Кавиның сугышта тагын өч туганы да катнаша: Тәлгат, Суфия, Рәфкать. Медицина институтыннан сугышка алынган Суфиялары Германиягә кадәр барып җитә. Өлкән лейтенант Суфия Кавиева Кызыл Йолдыз ордены, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены, күпсанлы медальләр белән бүләкләнә.

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
ТР Журналистлар берлеге әгъзасы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU

ӘЗЛӘМӘ МИНЕ...



УЛ ҮЗЕНЕҢ БӘЛӘКӘЧЕН КУЛЫННАН ДА ТӨШЕРМИ. ӘНИСЕ КОЧАГЫНДА НАЗЛАНГАН МАЛАЙГА ХӘЗЕР ИНДЕ ӨЧ АЙ ТУЛЫП КИЛӘ.



Мәдинә АВЗАЛОВА

Алар мине ишек төбенә кадәр озата киләләр. Аякка кигән арада исемә төшкән бер анекдот сөйләп, көлдереп тә алам. «Шулай да ачкычны бордыгыз, ә ишекне ачмадыгыз? Нигә?» – дим дә, үзем биргән сорауга үзем үк җавап бирәм. «Әйе, курыктыгыз. Ишек ачарга курыктыгыз...» Ирләре килсә, сугыша башласа... Хатыннар шулай, ди. «Аллам сакла-сын...» Иң курыкканнары шул икән. Саубуллашып, вакытлыча гына булса да шушы бәхетсезләрне үз кочагына сыендырган, үзләрен кеше итеп, баласының әнисе итеп, ниһаять, хатын-кыз итеп хис итәргә мөмкинлек биргән кризис үзәгенең ишеген ябып, чеплә эссе урамга чыгам. Шундук йөземә кайнар һава сулышы килеп бәрелә. Ә күңелдә – давыл, буран... Ишеткән-күргәннәремне кат-кат барлыйм да, хатын-кызның чарасызлыгына, урынсыз йомшаклыгына җаным әрни башлый. Ир каһәренә, ир җәберенә түзеп яшәргә нәрсә мәҗбүр итә аларны?! Әйе, беләм: «Бала», – диярсез, «Яшәр урын, яшәү чыганагы булмау», – диярсез... Ә нигә, нилектән юк соң ул яшәү урыны, балаларың белән бергә сине фатирыңнан куып чыгарырга кемнең хокукы бар?! «Мондый хәлдә калганда беркем якламый. Үзегез хәл итегез генә диләр», – дигән иде әлеге сорауны биргәч волонтер, ә тиздән Кама Тамагында оешачак шушындый ук кризис үзәге җитәкчесе Гөлнара Исхакова. Димәк, законнар чыгаручы, безнең хокукларны саклаучы органнар, хатын-кызның хокукларын якларга алынган дистәләгән җәмәгать оешмалары кешелекнең гүзәл яртысын бу баткаклыктан чыгарырга, ярдәм кулын сузарга җыенмый да. Бу мәсьәләдә бер-ике хатын-кызның язмышын уңай хәл итеп кенә күкрәк кагып йөрү файдасыз. Тамырдан үзгәрешләр, хатын-кызны шул залимнәрдән яклый-саклый торган закон-кагыйдәләр турында бара сүз.

Әле ярый да бу мәсьәләне көн үзәгенә куя белгән, бүгенге көннең иң җитди проблемасы дип кабул иткән, акчасыз эшләргә дә ризалык биргән «Добро Даром» ише мәрхәмәт үзәкләре бар. Кая барырлар иде язмыш тарафыннан кыйналган ул бичара хатыннар?! Болай диюгә, күз алдыма ире кыйнап чыгаргач, ике баласын җитәкләп (берсенә – 15, икенчесенә 7 яшь), өченчесе карынында килеш үзәккә килеп «капланган» Оля; баласын күпер астында табып, чактан гына исән калган Гөлбаһар; 58 яшендә фатирсыз урамда калган Фәһимә исемле ханым күз алдына килеп баса. Алар сөйләгән сүзләр чаң суккан кебек яңгырый.

Фотода: Гөлбаһар улы белән. «Добро Даром» хәйрия фонды архивыннан.

«Мин аны жәллим»

Башка сыймый торган бу сүзләрне Оля әйтә. Ире аңа: «Кайтасы булма...» – дип, балалары белән өйдән куып чыгарган. Хәзер әнә: «Өйне миңа яздыр», – дип, артыннан калмый йөри. Ә хатын аны жәлли. Нигә, нәрсә өчен жәлли? Сораштыра башлагач: «Мин шундый инде», – дип кенә куя. Ә бәлкем беренче чиратта балалар турында уйларга кирәктер? Ерткыч ирне түгел! Оля балалар йортында тәрбияләнгән. Ә ятимнәр, гадәттә, үзләрен яклый белми. Күп кенә бәхетсезлекләр, фаҗигаләр еш кына шуның аркасында килеп чыга да. Моңа бик күп мисаллар китерә алам. «Балалар йортыннан чыгып киткәндә күпмедер акчам бар иде. Ипотекага фатир алдык. Ике бала тапкач, ана капиталын да шунда салдым. Фатир ирем белән икебезгә язылган. Ә хәзер фатирны үзенә калдыру өчен мине эзли. Эзләмә мине, без хәзер чит кешеләр, дидем», – ди Оля. Берәр кеше ишеккә кагылган саен, ул калтырап төшә: ире түгелме?

– Адвокат кирәк миңа, – ди Оля киләчәге өчен кайгырып. – Ул фатирны сатып, яңаны алырга... Югыйсә көн күрсәтмәячәк ул миңа.

Алар аерылышкан. «Ник, алай булгач, куркасың соң аннан? Ул синең өчен хәзер ят кеше. Кул тидерде исә закон буенча җавапка тартыла...» – дим. Ул тагын: «Аерылышканыбызга өч ай үтмәде бит әле», – дип, мине дә уйга калдыра. Ир белән хатынның юллары икесе ике якка каерылган, инде аларны берни дә бәйләмәгән очракта да, хәтта шунда да, өч ай үтмичә, тынычлык күрәм, ул явыздан ычкынам, дип уйларга иртәрәк. Тупас итеп әйткәндә, аерылган хатынын залимнәр әле тагын өч ай дәвамында килеп дөмбәсләп китә ала икән. Оля шулай, ди. Нәрсә инде бу, ә, җәмәгать?! Моны ничек аңларга?! Полиция хезмәткәрләре нәрсә карый? Хатын сентябрь ахырлары – октябрь башларында өченче баласын табачак! Ул күп балалы аналар исемлегенә күчәчәк. Аңа социаль хезмәткәрләрнең дә ярдәме кирәк булачак.

Язганым да бар: чит илләрдә (бу хакта миңа Татарстанда кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил сөйләде) ир хатынга бер генә мәртәбә кул күтәрсә дә, аны шундук гаиләдән читләштерәләр. Ир гаиләсен бер чакрымга читләтеп үтәргә, якын килмәскә тиеш. Нигә безнең Гаилә кодексына да хатын-кызны җил-давылдан аралый торган шундый җөмләләр кертмәскә? Ир белән хатын-кыз арасындагы тигезлек турында сөйлибез. Хак Тәгалә бәндәләрен тигез итеп яраткан. Беркем дә беркемгә физик көч кулланырга тиеш түгел. Куллана икән, җавап бирсен, андый залимнәр өчен күрсәтмә судлар оештырылсын. Бәлкем, шул чагында көчләрен кая куярга белмәгән бәндәләр уйлана калыр. Чыннан да, кемнең хатын кыйнап төрмәгә эләгәсе килсен? Моны мин әйтмим, бер танышым әйтә.

«Бала табарга күпер астына төштем»

«Бир әле миңа да, яратыйм», – дим. Гөлбаһар елмаеп җибәрә, кадерле «төргәген» кулыма тоттыра. «Синме инде ул күпер астында туган малай?» – дим баланы иркәләп.

Әнисе – үзбәк, әтисе таҗик булган бу хатын белән кайсы телдә сүз кушарга белми аптырап торам. Ә ул безнең телдә – татарча сөйләшә икән. Гөлбаһар Казанга Таҗикстанның ерак бер авылыннан ирен эзләп килүе, берничә ай ире белән төзелештә эшләве, төзүчеләргә ашарга пешереп торуы, аннан йөккә калуы турында сөйли-сөйли дә, елап җибәрә. Бала тудырыр алдыннан гына ире юкка чыккан. Әле дә, инде ничәмә-ничә ай узып китсә дә, ирнең хәбәре юк. Ул аның кайда йөрүен белми. Кризис җитәкчесе Ольга Бакаева фаразлавынча, ирне, документларының срогы чыгу сәбәпле, Татарстаннан чыгарып, иленә кайтарып җибәргән булырга тиешләр. «Телефоннан үзенең кайдалыгын хәбәр итә алмыймыни соң?» Юк, алмый икән. Чөнки хатынның телефоны юк. Өендә, үзе әйткәнчә, «кышлак»та аны әле тагын өч баласы һәм инвалид әнисе көтә.

Хатын ирен бер атна көткән дә, кайтмагач, үзе дә күзе кай якка карый, шул якка чыгып киткән. Баланың дөньяга килер сәгатен сизенгән ана. «Күпер буйлап барам шулай, – дип, татарчага үзбәк сүзләрен кыстыра-кыстыра сүзен дәвам итә ул, – каршыма бер малай килә. Кит тизрәк, кит, дим. Куам тегене. Ә ул тораташ катты да калды. Нинди җүләр хатын дип уйладымы икән инде. Ничек кирәк алай күпер башына барып җиттем дә, аска төштем. Хәзер миңа баламны табарга беркем комачауламаячак. Үзем белән кайчы, бинт, чүпрәк-чапрак ише кирәкле әйберләр алган идем. Күпер астына төшеп тә җиттем, тулгагым башланды да. Тиз таптым, тилмертмәде ул мине. Ана баласына наз тулы карашын төби. – Сизенгәндер минем нинди хәлдә икәнемне».

> *Җәбер-золымга түзә алмыйча өеннән чыгып качкан хатын-кыз әле озак вакытлар иреннән качып яшәргә мәҗбүр.*

Ул кайчы алып баланың киндеген кисә. Баланы чүпрәккә төрә. Аннары, аз гына хәл алганнан соң, торып аягына баса. Нәниен кысып кочаклаган килеш, күпер өстенә менеп, юлын дәвам итә. Ниндидер бер урамга килеп чыга. Әйтүенә караганда, бу – Азино тирәләре. Бер татар карчыгын очрата. «Әби, зинһар, ярдәм ит. Әле генә бала таптым», – дим. Була бит дөньяда мәрхәмәтле кешеләр. «Әйдә, кызым, әйдә», – дип, ул мине өенә алып кайтты. Шундук юынырга ваннага су җыйды. Башта үзем кердем, аннары улымны коендырдым. Ике көннән әбигә мең рәхмәтләр әйтеп чыгып киттем. Җибәрәсе килмәде, кал, дип үгетләде. Ә мин уңайсызландым. «Хастаханәгә бар», – дип тә әйтте әле.

Шулай да хастаханәгә барырга туры килә аңа. Янә юлында шәфкатьле кешеләр очрый. Гөлбаһар бер машинаны туктата. «Хастаханәгә илтегез, хәлем начар», – ди. Шофер аңа «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакырта.

PRESSA.RU

Гөлбаһарны бер хастаханәгә, малайны икенчесенә озаталар. Ана ун көн ут йотып яши. Аны иленә озатып, баланы алып калсалар... Менә шул чагында ярдәмгә килә дә инде «Добро Даром» кризис үзәге хезмәткәрләре. Хәер, бер алар гына түгел, Идел буе районының балигъ булмаган балалар белән эшләүче хезмәткәрләре дә ананы баласыннан аермас өчен барын эшлиләр.

– Документлар артыннан йөрибез, – дип сүзгә кушыла Ольга Бакаева. – Балага туу турында таныклык эшләсәләр, озатып җибәрергә дә була аннары. Бик кайтасы килә Гөлбаһарның.

Хокук саклау органнары хезмәткәрләре «гаилә эше», дип, хатын белән ир арасындагы мөнәсәбәтләргә тыкшынмыйлар. Шул рәвешле, залим ирләргә «яшел урам» ачалар.

Шөкер, мәрхәмәтле, игелекле кешеләр күбрәк бу дөньяда. Алар әле тагын да күбрәк булырлар. «Добро Даром» хәйрия фонды җитәкчесе Рушан Хәкимовның киләчәккә планнары зурдан: ул мондый үзәкләрне республиканың бөтен районнарында булдыру хакында хыяллана. Ә моның кирәкле һәм котылгысыз эш булуына иманыбыз камил. Коткарса, хатын-кызны бәладән шул хатын-кыз гына коткарыр инде. Аның ярдәмчеләре – Ольга Бакаева, Гөлнара Исхакова, Фәһимә Төхвәтулина тиздән кайсы кая таралыр. Ольга – Казандагы кризис үзәген, Гөлнара – Кама Тамагындагы тиздән ачылачак үзәкне, Ә Фәһимә ханым Балтачның Пыжмара авылында эшләп китәчәк кризис үзәген җитәкләр.

– Авыл хатыннары – аеруча түзем, аеруча сабыр, – ди Гөлнара Исхакова. – Бер уйласаң, түзмичә кая барсыннар?! Барып сыеныр почмаклары булмагач... Кайберләре ирләренә ияреп, эчүгә сабыша. Ир йодрыгына алкоголизм проблемасы да килеп өстәлгәч, гаиләдәге хәлләрне күзаллау кыен түгел.

Берсеннән-берсе катлаулы вазгыятьне – кеше язмышларын хәл итәргә алынган әлеге ханымнар бирегә күктән төшмәгән. Хәтер төбен айкый башласалар, һәркайсының үзенә бер җан көйдергеч тарихы... Алар шул сират күперен кичеп чыга алганнар. Хәер, үз башыңа төшмәсә, кеше кайгысы кештәктә бит ул... Бүген, әнә, аның каруы, Ольга да, Гөлнара да институтта укыйлар, белем күтәрәләр. Аларга психолог һөнәре дә, социаль хезмәткәр белгечлеге дә бик ярап куяр. Чөнки кризис үзәгенә килеп эләккән хатыннарның проблемаларын хәл итү өчен шушы гыйлемнәр кирәк. Тормыштан гайрәтләре чиккән, төшенкелеккә бирелеп, кемнәндер куркып, шикләнеп яшәгән качкын хатыннарны кайда яшим, кая эшкә урнашыйм мәсьәләсе генә борчымый. Аларның барысы да диярлек тормышка өмет-ышанычлары калмагач, үзләрен югалтып киләләр үзәккә. Киләләр һәм ике-өч ай эчендә яңадан тормышка кайталар.

Мондый үзәкләрне районнарда, авыл җирләрендә оештыру акыллы һәм төптән уйланылган гамәл. Беренчедән, тыныч, беркем тими. Икенчедән, әлеге дә баягы, авыл җире бит, ни дисәң дә, үзеңә кирәклесен чәчәргә, утыртырга, үстерергә була. Кеше күзенә карап, эшсез ятмыйсың, кыскасы. Аннары хатыннар үзләре дә элек яшәгән урыннарыннан читкәрәк, ераккарак китү ягында. «Тудырсаң, өйгә кайтма», – дип янаган ирнең күзенә күренмәвең мең хәер.

– Документлар әзерләнеп беткәч, Балтачка – Пыжмара авылына китәм, – ди ихлас куанып Фәһимә ханым Төхвәтулина. – Утыз сутый җире бар. Помидоркыярын утыртырбыз, бәрәңге чәчәрбез. Гел хәйрия акчасына гына яшәп яту килешмәс.

Фәһимә ханымга – 58 яшь. «Ничек килеп эләктегез монда?» – дигән соравыма, ул авыр сулап куя. Әйе, адәм баласын иртәгә ни көтәсен бер Аллаһы Тәгалә генә белә. Ул да тормышы кинәт кенә менә шулай булып китәр дип башына да китереп карамагандыр. Гомерең узып барганда, фатирсыз калуны күз алдына китерүе дә авыр бит.

Балалар йортында үскән Оляның ни әнисе, ни әбисе... Ул балаларын җитәкләп, кая барыр, кемгә килеп сыеныр иде?! «Минем өчен бу үзәк – мәхшәрдән котылу урыны», – дип тикмәгә генә әйтми яшь хатын. Ул бүген ялгыз түгеллегенә, аны биредә беркем дә рәнҗетмәячәгенә чын күңелдән ышана. Һәм дөрес эшли.

Үзәк хезмәткәрләре һич тә кыен хәлдә калган хатын-кызларны авыр тормышка яраклашырга, ирләре белән килешергә һич тә үгетләмиләр. Алар алга таба ничек яшәячәкләрен үзләре, бары тик үзләре хәл итә. Дөрес, биредә ике-өч ай яшәгәннән соң, ирен «сагынып», элеккеге тормышына әйләнеп кайтучылар да юк түгел. Ләкин алар берничә айдан тагын үзәккә килеп сыенырга мәҗбүр. Димәк, хатын-кызга нинди оешмалар гына, кемнәр генә булышлык күрсәтмәсен, әгәр дә ул шундый хәлдә акыллы карар кабул итми икән, аны инде беркем дә үзе сайлаган тәмугтан аралап кала алмый.

БЕЛМӘСӘҢ БЕЛ...

■ Казан читендә урнашкан әлеге үзәктә, ике ел эчендә түбәсез, таянычсыз-ярдәмчесез калган ике дистәләп хатын-кыз булып киткән. Ике дистәләп хатын-кызның язмышы хәл ителгән. Күпме бала әнисез калмаган дигән сүз бу. Өйләреннән, кризис җитәкчесе әйтмешли, бер футболкадан чыгып качкан әниләрнең, сеңелләрнең кесәләрендә бер телем ипилек акчалары булмый. Ә шундый үзәк барлыгын белмәсәләр?!
Үзәк әниләрне эшкә урнаштыра, юридик ярдәм күрсәтә, кирәк икән, адвокатлар чакыра. Алай гына да түгел, ул күп балалы әниләргә бала өчен кирәк-яраклар тарату белән дә шөгыльләнә. Бушлай килгән, күктән яуган бәхетне матди авырлык кичергән әниләр теләп кабул итә.

ХАТЫН-КЫЗ, ИР ХАТЫНЫ, АНА...



Аннары гына эшлекле ханым, бизнес-леди. Эшлекле ханымнарның IV форумында катнашучылар, фикер алышканнан соң шундый фикергә килделәр. Әлбәттә, яңалык әйтмәделәр. Гомер-гомергә шулай булды ич инде: Беренче урында – гаилә, ир, балалар... «Бөек ир артында бөек хатын-кыз тора», – дип тә әйттеләр. Монысы да хак. Ә бәлкем киресенчәдер дә. «Гаилә һәм бизнес. Гармонияле берлек» дип аталган утырышларның берсе нәкъ менә шушы мәсьәләләргә багышланды да. Утырышны алып баручы спикерларның чыгышларын тыңлаганнан соң, күпкырлы сәләтләргә ия, еш кына ирләр күтәрә алмастай эшләргә алынган гүзәл затлар моңарчы без белмәгән, яңа яклары белән ачылып киткәндәй була.

Ольга Шмелева, «Эфир» компаниясенең гаилә психологы:

– Гаилә бәхете – ул ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләргә бәйле. Биредә һәркем үз урынын яхшы белсен. Хатын ирне яратырга һәм иң мөһиме: хөрмәт итәргә тиеш. Чөнки күп нәрсә бездән тора. Әгәр дә ул балалары янында әти кешегә кычкыра, аны өйрәтә башласа, гаиләдә ир кешенең дәрәҗәсе шундук түбән тәгәри. Моны күреп торган баланың әтисе сүзен тыңламавы гаҗәп түгел. Ирләр һәрчак безгә – хатын-кызга таяна. Беркайчан да аларга: «Мин акчаны синнән күбрәк эшлим», – дип әйтмәгез. Гаилә таркалулар шуннан да килеп чыга. Эшмәкәр ханымнар һәрвакыт исләрендә тотсын: бизнес – бары сезнең эш, беренче урында – гаилә. Ир хатыны булуыгызны, тормыш кору сәнгате сезнең кулларда булуын беркайчан да онытмагыз!



Вера Ивановская, гаилә психологы, «Онлайн» кинотренингы проектын оештыручы:

– Компьютер, интернет, гаджетлар заманы. Без күп вакыт үз мәшәкатьләребезгә чумып балаларның ни белән мәшгуль булуын белмибез дә, белергә тырышмыйбыз да. Чөнки һәркайсыбызның үз эше. Әти кеше эштән кайта да, арыдым дип, диванга ята. Әниләр, гадәттә, кухняда. Ә бит ул да эштән кайткан, ул да арыган. Тавыш чыга, бәхәс китә. Өйдә кем нәрсә эшләргә тиеш? Ә балалар – һаман компьютер каршында. Алар беркемгә комачауламый, әти-әнигә дә шулай уңай. Берни белән кызыксынмый, укымый торган буын үсеп килә. Алда аларны ни көтә? Үсеп җиткәч, югары уку йортларына керер вакыт җиткәч, әти-әни борчыла башлый: инде бала нишләр, кая барыр, кем булыр? Ата-ана баласын нинди дә булса (сорап тормыйлар, кызыкмы ул аңа, юкмы) уку йортына кертү өчен барысын да эшли, ә менә улы кызы белән аралашыр өчен вакыт тапмый. Гаиләдә һәркайсы үз дөньясында яши.



Эльмира Кәлимуллина, Татарстанның атказанган җырчысы:

– Без бу дөньяга тикмәгә генә яратылмаган. Тормышта һәркемнең үз вазыйфасы. Кызганычка каршы, аны еш кына кешенең ни дәрәҗәдә уңышка ирешүе, социаль статусы белән бутыйлар. Бу – күңел халәте, без үзебезнең нәрсәгә сәләтле булуыбызны, нинди эшнең безгә зур бәхет, ләззәт китерүен белергә, урау юллар белән булса да, шуңа килергә, шуңа ирешергә тиеш! Әйе, күп очракта баласының киләчәк шөгылен ата-ана билгели, кайчандыр үзләре булдыра алмаган хыялларын тормышка ашырып, баласын корбан итә. Бәлкем, киләчәктә ул зур уңышларга да ирешер, күренекле кеше дә булыр, әмма хезмәте генә аңа зур шатлык китермәс. Шуңа һөнәр сайлауны баланың үзенә тапшырыгыз, акыллы киңәшләрегез белән дөрес юнәлеш табарга ярдәм итегез.



Фикер алышуларда катнашучы «Бэби-клуб» җитәкчесе Алсу Камалованың сүзләре дә һәркайсыбызга сабак булырдай: «Биредә әйтелгәннәр белән килешәм, – диде ул. – Балаларны телевизордан аерып ала алмагач, аны бөтенләй алып куйдык. Алар нишләргә белмичә, бик кадерле әйберләрен югалткандай, башларын салындырып, үзләренә урын таба алмый йөрделәр. Карыйбыз, бер ай үтүгә, барысы да онытылды. Боларга телевизор да кирәкми, компьютер да. Өйнең астын-өскә китереп уйныйлар. Арыгач, утырып китап укыйлар. Вакытында чарасын күрергә һәм ул әти белән әнинең уртак карары булырга тиеш.



Яһүд халкының бик яхшы бер гадәте бар: һәр атнаның җомгасын алар үзара аралашуга багышлыйлар. Әти-әни бала белән күзгә-күз карап сөйләшә, аның уй-теләкләрен белә. Шул вакытта бөтен серләр чишелә, әйтеләсе сүзләр әйтелә. Әни кеше бу көнне хәтта савыт-саба да шалтыратмый. Балалар бер-береңне ишетү, килешү, тыңлау сәләтенә әнә шулай кечкенәдән өйрәнәләр. Татарстанның «Эшлекле ханымнар» берләшмәсе җитәкчесе Лиана Сәетова әйткәнчә, гаилә ул – ике кешенең хезмәте, кулга-кул тотынып бер юнәлештә баруы.

Шулай да, ничек кенә эшем кешесе булырга тырышмыйк, без, беренче чиратта – хатын-кыз. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Рафис Борһанов, бу фикерне куәтләп: «Без сезне күбрәк көчсез булып кыланганда, йомшак күңелле булганда яратабыз», – диде.

Мәдинә АВЗАЛОВА



PRESSA.RU

КОМБАЙНЧЫ ВЕНЕРА

КОМБАЙН ШТУРВАЛЫ АРТЫНА БАСАРГА АНЫ БЕРӘҮ ДӘ МӘҖБҮР ИТМӘГӘН, УЛ БЕРКЕМНЕҢ ДӘ (БУ ОЧРАКТА БЕР ИР ЕГЕТНЕҢ ДӘ ДИЯРГӘ КИРӘК!) УРЫНЫНА ДӘГЪВА КЫЛМАГАН.

Бары тик йөрәк кушуы һәм, әлбәттә, хыялый хисләре алтын басуларга әйдәгән, тулышкан башакларны җыйнап алуда катнашырга ымсындырган.



Әлфия САМАТ



«Хатын-кызның ирләр эшенә алынуын мин бер дә өнәмим. Хатын-кыз гаиләдә, балалар янында булса, өйнең яме, ашның тәме арта төшә», – дигән иде район башлыгы Айдар Сәлахов, Түбән Тәкермән авылы комбайнчысы Венера Бикмөхәммәтова турында сүз чыккач. Әлбәттә шулай, бу хакта ниндидер бәхәс куерту гел урынсыз. Сугыш чоры түгел бит, ирләр кулы җитешми диярга дә сәбәбе юк. Ә менә, йөрәге җитеп, комбайн тикле комбайнны иярләргә алынган Венера ханымның әлеге гамәле соклангыч түгелме, һәм бу хакта дәшми калу мөмкинме? «Органик Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең «Чулман» агрофирмасында эшләүче комбайнчы Венера Бикмөхәммәтованың, йортындагы кырыкмаса-кырык төрле хатын-кыз мәшәкатьләрен, дүрт баласын калдырып, ирләр эшен башкарырга батырчылык итүенә генераль директор Илдар Гыймадиев та башта сәерсенеп һәм булдыра алырына шактый ук икеләнеп караган икән әле. Авылда сүз тиз йөри бит ул, Илдар Шамил улының шик-шөбһәләрен тиз тараткннар. Венера турындагы мәгълүмат генераль директорның колагына бик тиз килеп ирешкән. Ире Илгиз Бикмөхәммәтов белән бергә 2007 нче еллар тирәсендә берничә ел комбайнчы ярдәмчесе булып эшләп, ярыйсы гына тәҗрибә туплагач, икенче сезонны аның үзенә өлкән комбайнчы сыйфатында ашлык суктыруда катнашырга туры килгән икән. «Ирләрне дә уздырырлык итеп эшләп, күпләрнең, кем әйтмешли, кикрикләрен шиңдергән Венера әле ул», – дигәннәр Гыймадиевка.

Венераның үзен исә баштарак: «Балаларыңны карап өеңдә генә ятасы урында, нишләп тимертомыр арасында тыкшынып йөрисең?» – дип аптыратканнар. Аңарчы да әле, Минзәләнең үзендә укып йөргәндә дә, таныклык алу өчен шактый тир түгәргә мәҗбүр булган ул. Янәсе, кая инде хатын-кызга трактор-комбайнда эшләү? Үҗәтләгән, булдыра алуын Венера шунда раслаган. Дөрес, аннан соң 6-7 ел гомер узган узуын. Иген кырларында беренче сынауларны узган дәвердә үк 4 һәм 3 яшьлек кызлары Фәридә белән Фәриягә иптәшкә тагын ике кыз – Фәзилә белән Дилбәрне алып кайтырга өлгергән. Инде менә өлкәннәре үсеп җитеп кул арасына керә һәм кечкенәләрне карый ала башлагач, йөрәгенең җилкенүен тыеп тора алмаган Венера ханым.

– Узган елны ук инде, урып-җыю эшләренә керешкәндә, авылыбыз комбайнчыларының басуга китүләрен кызыгып карап кала идем, – ди Венера. – Әмма балалар кечкенә булгач, насыйп булмады. Быел чыктым, җанга җылылык иңгәндәй тоелды. Түбән Кама шәһәрендә яшәүче кайнатам белән кайнанам җәйгелеккә кайтып торгач, кызларым өчен күңелем тыныч иде. Олы кызлары йорттагы бар эшне ялт итеп эшләп куя, ике сеңелләренә дә – күз-колак. Әле бит безнең ике савым сыерыбыз да бар. Иртән үзем савып китсәм, кичкелеген Фәридә белән Фәрия сава. Кошкортны да шактый мулдан асрыйбыз. Бакча-яшелчәсе дигәндәй, эш күп, кыскасы. Балаларның эшләп үсүе безнең өчен генә түгел, киләчәктә үзләре өчен дә файда. Урып-җыю вакытында үзләрен күреп тә булмый әле: иртән киткәндә дә, кич кайтканыбызда да йокыда булалар. Битләреннән үбеп кенә узган вакытлар аз түгел...

Әйе, Венера шулай уйлый. Эшнең сөяк сындырганы юк. Хәзерге заманда күпләр балаларын балдамайда йөздереп, эш эшләтергә жәлләп тәрбия кылганда, Бикмөхәммәтовларда башка фикер. Хәер, Венера үзе дә бик җиңел тормышта үскән кыз түгел. Минзәлә районының кечкенә генә Мортыштамак авылында туып-үсеп, мәктәпне күрше Кадрәк авылына җәяүләп йөреп укыган чакларын искә төшерү дә җитә. Ишегалды тулы мал-туар, әти-әнисе көннәр буена диярлек колхоз эшендә, берсе тракторда, икенчесе – фермада. Тырыш, булдыклы, карусыз хезмәт кешеләре. Гаиләдәге ике кызга – апасы Вален-



Илдар ГЫЙМАДИЕВ, «Органик-Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять генераль директоры. Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, Россия агросәнагать комплексының мактаулы хезмәткәре.

«Без әле яңа гына оешкан предприятие. Минзәлә районындагы «Минзәлә», «Чулман», Мөслим районындагы «Урожай», «Ык» агрофирмаларын һәм Мөслим ашлык кабул итү предприятиесен берләштергән «Органик-Групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең хезмәт уңышлары да әлегә тыйнак түгелдер. Әмма һәрбер предприятие икътисадый яктан үзен акларлык хезмәт куярга бурычлы дип саныйм. Әгәр былтыргы нәтиҗәләргә күз төшерсәк, проблемалы ел булган ул. Оештыру эшләре, структура үзгәрешләре белән шөгыльләндек. Быел инде алга таба күзгә күренерлек сикереш сизелде дисәм, артык күпертү кебек тоелмас. Чыннан да, байтак яңалык кертелде. «Минзәлә» агрофирмасы җыйнаклындырылды, Аю һәм Мәлкән хуҗалыкларында 800 башка исәпләнгән савым сыерлар фермасы эшләп китте. Күрсәткечләребез, әйткәнемчә, тыйнак. Әмма без бу юнәлешне үстерүгә тотынганбыз икән, бер урында таптанып тормабыз, югары нәтиҗәлелеккә ирешкәнче тырышырбыз дип уйлыйм. Агрофирмаларда уңышлы старт алынды, ныклы база булдырылды. Инфраструктураны үстерүгә игътибар бирәбез...»

Илдар Гыймадиевнең сүзләрендә хаклык бар. Ул әле бик тыйнак сөйләшә. Ә бит, быел Минзәлә районында моңарчы күрелмәгән рекордлы уңыш нәкъ менә «Органик-Групп» ҖЧҖ карамагында Йорт авылы басуларыннан алынган. Биредәге бер басуның гектардан 57 центнер уңыш бирүе турында матбугат шаулап алган. «Җиргә кадер-хөрмәт күрсәтсәң, ул сине шулкадәр мул уңыш белән сөендерә ки, үз күзләреңә дә ышанмыйча торасың хәтта, – ди «Чулман» агрофирмасының баш агрономы Илгиз Хәкимов. – Инвестор булып Илдар Гыймадиев килгәч, игенчелек тармагына өр-яңа сулыш өрелде сыман. Тулбай авылындагы парга калдырылган җирләрне горчица-сидерат белән ашлагач, уҗым бодае чәчкән идек, гектардан 40 ар центнер уңыш җыйнап алдык. Министр Марат Әхмәтов килгәч, бу басуларга югары бәя биреп китте...»

PRESSA.RU



Техникага хирыслык аңа бала-чага вакытыннан ук килә торгандыр.

тина белән Венерага да «хезмәт тәрбиясе» күп эләккән. Ә менә техникага мәхәббәт димәктән, монысын Венера үзе дә белми, дияр идең... Әтисе Әдһәм Җәләлетдинов Татарстанның атказанган механизаторы исеменә лаек булган шәхес. «Әле бәләкәй чакларында ук кызларым минем янда басуда булдылар, – дип искә ала Әдһәм ага. – Башта Валентина-Вәсиләне (минем хатыным Клара – керәшен кызы, шулай ике исем белән йөрттек олысын), аннары икенчесен күтәреп утыртам тракторга. Ялыкканчы шулай йөриләр болар. Ә Венерасы исә, мәктәптә укыган чагында да, букчасын гына кертеп куя да, йөгерә-йөгерә килеп җитә иде. ДТ-75 тракторына менеп утыра да көн буена диярлек янымда йөри. Ул тавышка ничек чыдагандыр балакай...»

Холкындагы сабырлык, чыдамлык, булдырам дип тырышу галәмәте әнә шул чылбырлы тракторның баш миләрен бораулап кергән гөрелтесе астында барлыкка килгән дә инде. Эссе җәйге кояш астында, тузан йотып, бер караңгыдан икенчесенә кадәр штурвал киеренкелеген тоеп, икмәк өчен барган көрәшне әллә җиңеп чыга алыр идеме ул нәфис куллар? Ә менә хатын-кыз кулы тигән комбайн чисталыгы-пөхтәлеге белән дә башкалардан аерылып тора. Тәрәзәләренә элгән пәрдәләренә кадәр ялт иткән булыр! Быелгыдай чиллә җәйдә баш белән салкын суга чумасы килгән чаклары да булмый калмагандыр комбайнчы ханымның. Әмма ул ярдәмчесе, Чаллы көллиятендә белем алучы авылдашы Ленар Гобәев белән әлеге кайнар көннәрнең кадерен белеп калырга омтылып, барысына да түзеп, тизрәк, күбрәк һәм сыйфатлырак итеп игеннәрне суктырып алу җаен карый. Нәтиҗәләре дә куанырлык шул: «Дон»нар арасында агрофирма күләмендә генә түгел, район комбайнчылары арасында алдынгылар рәтенә чыкты ул. Урып-җыю эшләре ахырында исә Венера Бикмөхәммәтова 14000 тоннадан артык икмәк суктырып, районда икенче урынга чыгып төгәлләде уракны.

– Бу җиңүдә Ленар белән икебезнең генә түгел, ирем Илгизнең дә өлеше зур, – ди Венера ханым. – Әгәр авыр минутларда ул булышмаса, вакытында «ашыгыч ярдәм» күрсәтмәсә, бәлкем, алдынгылыкка чыга да алмас идек. Илгиз үзе дә комбайнчы булып эшләп, техника белән «җенләнгән» кеше. Аңа телефоннан шылтыратып: «Шул җиреннән шундыйрак тавыш чыгара, бу җире болай, теге җире...» – дип әйтү дә җитә, шундук диагнозын куеп, киңәшен бирә. Тыны белән дә тоя, диләр андыйларны. Хәзер ул шушы хуҗалыкта инженер вазыйфасын башкара. Мине дә ул өйрәтте бу эшкә. Башта кеше булмаганга гына, ярдәмгә генә дип чыккан идем бит мин. Аннары, бер тотынгач, иген кыры, техника мине үзенә әсир итте...

Илгиз – шәһәр егете. Әнисенең туган нигезенә ул биредә гомер кичергән Фәүзия әбисен карарга кайткан. Кайткан һәм авылда төпләнеп калган. Әбисен 85 яшенә кадәр тәрбияләп, мәңгелек йортка кадер-хөрмәт күрсәтеп озатканнар. Хуҗалыклары шактый зур. Гаилә ишле булгач, йортны зурайту хаҗәте килеп чыккан. Әле кечкенәләр дә укырга керсә, дәрес әзерләргә урын җитмәячәк бит. Йорт мәшәкатьләренә чумып йөргән мәлләре Бикмөхәммәтовларның. Урып-җыю эшләре төгәлләнгәч, Венера машина-тракторларны ягулык белән тәэмин итү станциясендәге эшен дәвам итә. Авылда балалар бакчасы юк, шунлыктан ике кечкенә кыз да әниләре белән көн дә диярлек «эшкә йөри». «Бер хезмәтнең дә гаебе-кыегы юк. Нинди генә һөнәр сайласалар да – аларның үзләрендә. Мин дә бит көллияттә укып, юридик белем алган идем, язмыш үземне иген кырлары белән бәйләде. Шунлыктан, балаларга да минем юлдан китмәгез, дия алмыйм...»

Минзәлә районы.

ҖӘМГЫЯТЬ



■ **Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Латвия Республикасы Президенты Раймондс Вейонис белән очрашты. Ул ике арадагы эшлекле элемтәләрне һәм үзара хезмәттәшлекне киңәйтүгә юнәлтелгән иде. «Татарстан Республикасы делегациясенең сәфәре мәдәният, мәгариф һәм башка тармакларда хезмәттәшлекне ныгытуда бик мөһим», – дип билгеләп үтте Латвия Президенты. Татарстан җитәкчесе Латвиянең татар иҗтимгый оешмалары активистлары белән дә аралашты, Латвия татарларының «Идел» җәмгыяте эшчәнлеге белән танышты. Татар халкының мәдәни-әхлакый кыйммәтләрен саклаган һәм үстергән өчен җәмгыятькә ТР Президентының Рәхмәт хаты тапшырылды. Эшлекле визит кысаларында шулай ук AirBaltic җитәкчелеге белән сөйләшүләр үтте, Казан белән Рига арасында һава юлларын ачу проекты 2017 елның маеннан тормышка ашырыла башлаячак.**

МӘДӘНИЯТ

■ Нидерландта һәм Бельгиядә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының гастрольләре уза. Тамашачыларга Дж. Верди музыкасына «Набукко» операсын тәкъдим итәчәкләр. Көзге гастрольләр вакытында аны 30 тапкыр күрсәтү планлаштырылган. Артистлар Эйндховен, Роттердам, Гауда, Харлем, Амстердам һәм башка шәһәрләрдә чыгыш ясаячак.

■ Театр мәйданында зур бәйрәм ясап, Г. Камал театры 111 нче сезонын ачты. «Камал театрын колачла» дигән акция үткәрелде. Татар театрын яратучылар, кулга-кул тотынышып, Камал театры бинасын урап алды.

■ Балтач районы Мәдәният йортында «Ак калфак» район хатын-кызлар оешмасы «Бишек туе» бәйрәме уздырды. Бишекләр куелган күргәзмә күпләр игътибарын җәлеп итте. Татарстан Республикасының Премьер-министры урынбасары – Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов үскән бишек тә куелган иде. Районның иң яшь гаиләсенә бишек бүләк ителде. Миләүшә һәм Марат Дәүләтшиннарның улы Сәмир талчыбыктан үрелгән бишектә үсәчәк.

■ Казан Эрмитажында «Петербург модерны. 1890–1910 нчы еллар. Стиль һәм затлы затлар модасы» күргәзмәсе ачылды. Анда 219 экспонат – Россия патшабикәләре кигән күлмәкләр урын алган. Романов династиясе вәкилләре Мария белән Александра Федоровналарның күлмәкләре хатын-кыз матурлыгы һәм гармония эпохасы белән таныштыра.



КОТЛЫЙБЫЗ

■ **«Оренбург шәлчеләре» предприятиесе җитәкчесе Альбина ӘБСӘЛӘМОВА халкыбызның гореф-гадәтләрен, милли һөнәрчелеген саклауга керткән өлеше өчен «Сөембикә беләзеге» белән бүләкләнде.**

МӘГАРИФ



■ **«Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәгендә Укытучылар көненә багышланган тантана узды. Анда Татарстан шәһәр һәм районнарыннан меңләп укытучы катнашты. Соңыннан мәгариф хезмәткәрләре М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Эсмеральда» балетын тамаша кылды.**

■ **2015–2016 елда югары нәтиҗәләр биргән 500 мәгариф оешмасының 21 е – Татарстан мәктәпләре. Рейтинг мәгълүматлары буенча, Россиянең 25 мәгариф оешмасына ике Татарстан мәктәбе дә кергән. 15 нче баскычта – Чаллының 26 нчы гимназиясе, 19 нчы баскычта – Казанның 131 нче лицее.**

■ **Татарстан Дәүләт Советы бинасы янында республиканың 22 районының мәгариф оешмасына яңа автобус ачкычларын тапшыру тантанасы булды. Балаларны йөртү өчен 22 кешелек 25 яңа Ford Transit автобусы ачкычларын ТР Премьер-министры урынбасары – фән һәм мәгариф министры Энгель Фәттахов тапшырды.**

СПОРТ

■ Казанда «Милләтләр кроссы-2016» Бөтенроссия йөгерү ярышлары узды. 1 километрга массакүләм стартларда 20 меңнән артык кеше катнашты. VIP ярышларда хакимиятнең дәүләт һәм муниципаль органнары вәкилләре ярышты. Хатын-кызлар арасында 3 нче урынны – ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова; 2 нче урынны – ТР Министрлар Кабинетының сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы Гүзәл Шакирова; 1 нче урынны «Татарстанның Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды»ның дәүләт учреждениесе директоры Алсу Мифтахова яулады.

PRESSA.RU

ТӨШЕМДӘ АНЫҢ ДИҢГЕЗ БУЙЛАП ЙӨГЕРГӘНЕН КҮРӘМ. НИ ТАТЛЫ ТӨШ, ТИК УЛ МӘҢГЕ ЧЫНГА АШМАЯЧАК. ДИҢГЕЗ – АНЫҢ ДА, УЛ ИСӘН БУЛГАНДА МИНЕМ ДӘ ХЫЯЛ ГЫНА БУЛЫП КАЛАЧАК...





Лилия ГӘРӘЕВА

ЯСАЛМА КИРТӘЛӘР

Күрше Нина түти кергән. Күз яшьләре белән генә еламый. Аның яшендәгеләр йөрәк, кан басымы, радикулит... дип, табиб ишек төбен саклаганда, ул башка ишекләрне шакырга мәҗбүр. Гәрчә, йөрәк белән кан басымы аңа да бик таныш. Ләкин Нина түтинең боларны уйларга вакыты юк: оныгы ташлап киткән ике ятимне аякка бастырасы бар аның. Күз яшьләре белән генә еламый, дигәч, бу балаларны тәрбияләү авырлыгыннан сыктый икән дип уйламагыз. Үз сөяге үзенә авыр түгел аның. Бүтән нәрсә борчый Нина түтине. Берсенә – 4, икенчесенә 2 яшь чактан ук җил-яңгыр тидерми үстергән шушы балаларны ничә сумлык ашатуы, ничә сумга кием алуы, сабын-порошок ише кирәк-яракка күпме акча тотуы хакында опека һәм попечительлек органына ел саен бирелә торган хисапның чираттагысын тапшырыр көн килеп җиткән. Алай-болай гына түгел – һәр алган нәрсәсен тауар чегы белән раслаган, җиде-сигез битлек төп-төгәл хисап ул! Моннан тыш, банктан бер белешмә, пенсия фондыннан икенчесе кирәк...

Бик яхшы аңлыйм Нини түтине. Үзем дә опекун – бертуган апамның опекуны. Опекун гына дию берни дә аңлатмас, мин – аның аяклары, аның куллары, аның яклаучысы, аның дөнья белән ике арадагы күпере, бөтен хаҗәтен үтәүчесе. Аннан башка минем әле ирем, мин үстерергә тиешле ике балам да бар. Уены-чыны белән әйткәндә, үзем мин дәүләткә шактый гына файдалы кеше. Беренчедән, эшләп, казнага салым түлим, икенчедән – киләчәктә шушы илгә

хезмәт итәчәк балалар үстерәм, дәүләткә артык чыгым чыгармыйча гына беренче группа инвалид апамны тәрбиялим, аның барлык мәшәкатен йокым һәм ялым хисабына үзем хәл итәм. Моның өчен бер тиен акча сорамыйм, апага аерым бәдрәфе, инвалидлар өчен уңайлы юыну бүлмәсе булган иркен фатир дауламыйм, гәрчә андый фатир бер дә комачауламас, һәм өйдәге авыр ис, апаны юындыру җәһәтеннән гаиләбездә килеп чыккан күп кенә низагларны булдырмый калырга ярдәм итәр иде.

Сират кичү

Әни үлгәч, дөнья яшәүдән туктар кебек иде. Туктамады. Кешелекнең бар проблемасын төяп, галәм караңгылыгындагы мәңгелек юлыннан алга баруын белде. Әнине җирләп, кырыгын уздыруга, алдыбызга авырлыкның иң беренчесе һәм иң зурысы килеп басты. Әни исән вакытта, бу хәл кайчан да бер булачак бит, дип, хәтта уйларга да курыктык, менә ул көн килде – үзенүзе йөртә алмаучы апамны Казанга алып китәргә кирәк. Галәмәт авыр, өйдә фәкать шуышып кына йөргән, гомерендә дә авылдан чыгып карамаган, бүрәнә кебек гел бөгелмәс гәүдәсе куркудан дер-дер калтыранган апаны! Машина табып (үз машинабыз юк иде әле), алып чыгып сала алган хәлдә дә, бишенче катка ничек алып менәрбез аны? Алып менеп тә, коммуналь фатир бүлмәсендә ничекләр көн итәрбез! Бәдрәфе дә, мунчасы да, ашау-эчүе дә, яшәве дә шушы бер бүлмә булачак бит. Әле күршеләр кертергә ризалашса! (Апа авылда яшәсә дә, пропискасы гел Казанда булды.)

Авырлыкның берсен җиңдек дип, җиңел сулауга, икенче авырлык калыкты. Апага пенсиясен бирмиләр. Бер ай – юк, икенче, өченче ай – тагын юк. Авылда яшәгәндә почтальон өйгә кертә дә бирә иде. Монда менә бирмиләр. Үзе килеп, кул куеп алсын, диләр. «Килә алмый ул, йөри алмый! Аягына да баса алмый! Гарип ул, тумыштан гарип!» Җан әрнүе белән кычкырганым начальникларына ук ишетелгән икән: «Нотариус раслаган ышаныч кәгазе дә ярый. Шул булса, пенсияне үзегез килеп алырсыз», – ди. Ниһаять, караңгы тоннельдә яктылык шәйләнде, дидем, куанып. Безгә бит нишләсен, кая, кемгә мөрәҗәгать итәсен дә әйтүче юк. Сукыр кешедәй, барасы сукмакны капшап кына тапмалы. Авылда апаның документлары белән бәйле мәшәкать беркайчан тумады. Апа ничек туган булса, шулай яшәде. Паспорты бармы – бар, кул куя беләме – белә, шул җиткән. Артыгын сорамадылар. Барыбызны да үз кубызына биеткән, синнән-миннән акыллырак итеп сөйләшкән апа ла ул!

...Нотариус апаның имзасы куелган ышаныч кәгазен расламады. «Судка мөрәҗәгать итегез!» – диде ул.

Юләрлеккә таныклык

Дәү әни суд юлында йөрүдән бик курка иде безнең. «Суд юлыннан үзең сакла!» – дип тәмамлана иде кылган догалары. Мин дә куркам. Курыксам да, чара юк – суд ишеген дә ачарга туры килде менә. Гафу ит, апам, бәгърем. Үз ирегем белән сине «юләр» дип танытучы кәгазь артыннан йөрим. Безнең өчен син юләр дә, ахмак та түгел. Тик шушы кәгазь булмаса, миңа бөтен җиргә сине күтәреп алып барырга туры киләчәк. Аңла инде яме, рәнҗемә.

...Суд-медицина экспертизасы аны дөрестән дә акылга зәгыйфь, дип таныды. Рәхмәт табибларга, апаны күтәреп йөрисе булмады, хәлгә кереп, өйгә үзләре килде. Әмма... Ник йөрәгем сыза икән минем бу кадәр? Үземне укырга, санарга өйрәткән, гомеремдә беренче тапкыр Шүрәле, Су анасы, Камыр батыр белән таныштырган апага «юләр» мөһере суктырган өченме?..

Хисап көне

Телефоным шалтырый. Опека бүлегеннән икән. Хисабыгыз тапшырылмаган, диләр, тизрәк килергә кушалар. Тагын эштән сорап китәргә кирәк инде. «Әллә опекун булган өчен бик күп акча түлиләрме? Шуның өчен хисап бирәсеңме?» – дип сорый таныш-белеш. Үз туганымны караганга кем түләсен, ди, инде? Казна эшендә эшләмәгән опекуннарга аена мең сум тирәсе түләнә бугай үзе. Аларның миңа акчалары да кирәк түгел. Юк-бар белән генә җәфаламасыннар. Яшәдек бит әле моңарчы, берәүнең дә бездә гаме булмады. Апаны какмадык-сукмадык, ачлыктан, суыктан тилмертмәдек. Шулай булмаса, 48 яшенә кадәр яшәр идеме ул?! «Пенсиясеннән баш тарт! Акчасы өчен генә карыйсыз дигәннән котылырбыз, ичмасам», – ди ирем.

Сау-сәламәт кеше – бәхетле. Үзең дә сәламәт булып, урында яткан хастаң да юк икән, дөньяда синнән дә бәхетле кеше юк.

Кызык та инде бездәге законнар. Гарип балаңа 18 яшь тулганчы аның тормышы белән берәү дә кызыксынмый. Ә инде аңа 18 тулдымы – әни кеше үзенең опекун статусын раслатырга тиеш. Шунсыз ул баласының бер генә проблемасын да хәл итә алмый. Әмма хәзер аның һәр гамәлен опека һәм попечительлек органы күзәтәчәк. Баласының пенсиясен кирәкмәгәнгә тиздыра күрмәсен тагын! Шул рәвешле, аны үз әнисеннән, бәлки әле бердәнбер кайгыртучысыннан да яклый дәүләтебез.

Ярты көнемне опека бүлегенең ишек төбен саклап уздырганчы, мин бу вакытымны апама багышлый алыр идем. Болай да эштән соң кайтыла, аңа игътибар аз. Кемдер монда килеп хисап бирү өчен авыру баласы янында кеше яллап калдырырга мәҗбүр.

Эшемне прокурор тикшерә

Хисапны дөрес тутырмаганмын икән. Бүлектәге хезмәткәрнең күзе маңгаена менгән: «Сез берничек тә моның кадәр акча тота алмыйсыз. Мин сезнең хисапны кабул итмим, дөрес итеп тутырыгыз!»

Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU

Без ул елны моннан күбрәк тә акча тоттык әле, чөнки фатирга ремонт ясаттык. Апаның пенсиясе дә, иремнең хезмәт хакы да, минеке дә шул ремонтка кереп бетте. Җитмәде дә әле, кредит алырга туры килде. Менә шушы гамәлем – апаның бөтен пенсиясен ремонтка сарыф итү ошамаган тегеләргә. «Апагыз өчен конкрет нычә сум тоттыгыз, безне фәкать шунысы гына кызыксындыра». Кем белгән дә, кем исәпләп торган инде аны ул вакытта. Әмма шунысын беләм – апа яткан бүлмәне ясап чыгу өчен генә дә пенсиясе җитми. Әле бит авылда өй дә бар безнең. Апама әнидән калган мирас ул. Апа үзе анда бер кадак кага алмаса да, опекун буларак, мин бу йортны да төзек килеш, рәтләтеп торырга тиеш. Апаны да карарга кирәк, эшлисе дә бар, балалар да кечкенә, инде бу йортны да сөйрәрлек көч юк, булмаса, сатыйкмы дигән идек, анысына опека бүлеге рөхсәт бирмәде. Бабай салган, әни гомер буе яшәгән, без көчтән килгәнчә булышкан үз йортыбызны, апа исемендә булгач, хәзер сата да алмыйбыз икән.

Инвалид караучының болай да тормышы катлаулы. Гамәлдәге законнар, ярдәм итәсе урынга, аңа өстәмә мәшәкатьләр генә тудыра.

Закон буенча, ел буена апаның пенсиясенә сатып алган әйберләрнең чеклары җыелып барырга тиеш. Аның язуы инде ике айдан ук танылмый башлый. «Сез аларның копиясен алып куя торган булыгыз», – диләр. Өендә хастасы бар кешенең болай да мәшәкате муеннан. Инде көн саен чек төшереп йөрисеме? Бу мине бик гарьләндерә. Минем алай исәпләп, бүлеп, хисап биреп тә йөрисем килми, вакытым да юк. Эштән кайткач, минем әле апаны ашатып-эчертәсем, чиләген түгәсем, керен юасым, иртәгәсен ул минем ярдәмнән башка гына ашый алырлык ризык хәстәрләп калдырасым бар. Әмма законнар белән дә исәпләшми булмый. Хисап тутырмасам, опекунлык комиссиясе банктан апаның пенсиясен алырга рөхсәт язуы бирми. Әле кулында тиешле документларың булып та, ай саен кассадагы кызга апаның ни өчен үзе килә алмавын аңлатырга, аның пенсиясен үзем алырга хакым барлыгын расларга туры килә. Моннан биш-алты ел элек шушы ук банктагылар апаның пенсиясен картага килә торган итеп ясаганнар иде. Харап уңай иде ул, ай саен банкка барып, чиратлар торасы юк иде. Кибеттән әйбер алганда да җайлы, телефонга «смс» килә дә, хисап тутырганда шуларны шпаргалка урынына кулланасың. Быел ул картаның срогы чыкты. Яңага алыштырыйм дисәм, инвалидларның пенсиясен картага күчерергә ярамый икән. Регламентта каралмаган, ди. Ә бит опекуннарның болай да мәшәкатьле тормышына бер уңайлык өсти иде пенсиянең картага гына килүе.

Көтелмәгән «кунак»лар

Менә бүген тагын... Эшкә генә килеп утырган идем – телефон! «Сезнең ишек төбендә торабыз, ачыгыз!» – диләр. Район хакимиятеннән апаның торак хәлен тикшерергә килгәннәр. «Менә бит ничек кайгырталар. Торак хәле начар булса, аны ничек тә яхшырту җайларын табарга тырышырлар», – дип уйлый күрмәгез тагын. Апаны авылдан алып килгәч, шактый еллар коммуналь фатирдагы бүлмәдә яшәдек без. Җылы суы, ваннасы юк иде. Сез аны ничек күтәреп менгерәсез, ничек төшерәсез, кайда юындырасыз дип, беркем дә кызыксынмады. Ә хәлебез бик тә кыен иде. Инде ул бүлмәне сатып, аерым фатир алу өчен нинди җәфалар күргәнебезне сөйләмим, озакка китә. Фәкать шуны гына әйтәм, акылга зәгыйфь инвалид яшәгән фатирны сату өчен өч төрле оешмадан рөхсәт кирәк. Аларның һәрберсендә документлар берәр ай карала торгач, төптөгәл өч ай уза. Бездән бүлмә сатып алучы да өч ай көтәргә тиеш, безгә үз фатирын сатучысы да. Соңгы инстанция – район хакимияте. Район башлыгы имзалаганчы, документларга юрист кул куярга тиеш. Ә ул куймыйм: «Кеше саен 18 квадрат метр мәйдан чыкмый. Берәрегез үз өлешеннән баш тарсын», – ди. Уйлап кына карагыз: без ирем белән үз акчабызга фатир сатып алабыз, һәм безгә аны сатып алырга ризалык бирмиләр. Инде менә шул фатирда апаның ничек яшәвен тикшерергә килүләре икән. «Мин бит эштә», – дим. «Өйдә кемегез бар, шул ачсын!» Өйдә кеше юклыгын, апаның исә ишекне барып ача алмавын аңлатам. «Сез аның ялгызын калдырырга тиеш түгел! Сез югында бер-бер хәл булса?» Аллаһ кына саклый күрсен. Чынлап та, мин югында бер-бер хәл булса, ярдәмгә мохтаҗ кешене ялгыз калдырган өчен утыртып та куярга мөмкиннәр. Ә бит гел апа янында гына да утыра алмыйм. Кеше дә яллап булмый – бик кыйммәт ул. Кара, ничек кызык килеп чыга. Опекуннар эшләмәсен дә (чөнки авыруның берьялгызын калдырырга ярамый), аның пенсиясенә дә яшәмәсен. Ә ничек яшәсен?

Депутатка сүзем бар

Беркөнне бу хакта Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдиновка да әйттем. Журналистлар белән очрашуга килгән чагы иде. Апаның шәһәр транспортында бушлай йөрергә хакы бар, әмма йөрер өчен аяклары юк. Аның аяклары – мин, үзем йөрим аның хаҗәте артыннан. Тик инде түләп йөрим. Апаның бушлай йөрү хокукы аның опекунына күчми. Яки менә парковкаларны гына алыйк. Инвалидларга бушлай ул, ләкин шул инвалидның эше белән йөргән опекунга түләүле. Мөмкинлеге чикле кеше 18 яшькәчә инвалид бала статусында була. Андый балаларны тәрбияләгән аналарга нindидер ташламалар бар, ул пенсиягә дә бераз иртәрәк чыга. Апама 48 яшь. Ул инде инвалид бала статусында түгел. Аны караган өчен беркем дә мине пенсиягә иртәрәк җибәрмәячәк. Әмма... апага 10 яшь булса да, 50 яшь булса да, безнең мәшәкать гел бертөсле. Апа балигъ булды дип кенә, аның авыруы

чигенмәде, карау-тәрбияләү җәһәтеннән бераз уңайлылык тумады. Хәтта киресенчә, 10 яшьлек бала белән чагыштырганда, 48 яшьлек кешене күтәреп йөртүе, юындыруы, киендерүе, ашату-эчертүе күпкә кыенрак. Мондый кешеләр 1 яшендә дә, 50 яшендә дә бала булып кала. Менә шушыларны да җиткерәсе иде закон чыгаручыларга.

Үзем яшәгән районның опека бүлегендәгеләр дә законнарның камил булмавын таный. Яңарак кына бер хатын белән сөйләштем. Икесенең дә акчасын иренең исеменә салып барганнар. Көтмәгәндә иргә инсульт булган. Хатын теге акчаларны ала алмый. Ире сәламәт булса, алар аны теләсә нишләтә алырлар иде, хәзер исә ул акча опекунлык комиссиясе контролендә – «недееспособный» кешенең милкен комиссия рөхсәтеннән башка хәтта үз хатынына да (гәрчә анда хатынның үз өлеше булса да) тотарга рөхсәт юк.

...Безне тагын тикшерергә киләселәр. «Кайчан киләсегезне әйтсәгез, ул көнне эштән сорап калырмын», – дим. (Әле, апага табиб чакырттым, дип, әле, кая да булса апаның документын илтәсе, дип, мин болай да эштән гел сорап китәргә мәҗбүр. Ярый, эштәгеләр хәлемне аңлый, сүз әйтми. Ә бит кемдер эштән китә алмаска да мөмкин.) «Без килә дип, сез аны киендереп, юындырып куячаксыз. Без менә көтмәгәндә генә килеп тикшерергә телибез». «Берсен дә кертмә! – ди ирем. – Дәүләт биргән фатирда яшәмибез лә. Безнең ничек яшәүдә кемнең ни эше бар?» Комиссия әгъзаларының да үзләренә тиешле эшне башкаруын аңлыйм мин. Тикшерү дә кирәктер анысы Кайдадыр, бәлки, авыру кешене тиешенчә ашатмыйча, салкын, караңгы бүлмәләрдә тоталардыр. «Фатирыбызда җылылык 18 градус кына. Апа туңып ята. Шуны хәл итәргә булыша алмыйсызмы?» – дим, район хакимияте вәкилләренә. «Ул безнең вазыйфа түгел», – диләр. Вазыйфалары опекуннарның еллык хисабын тикшереп, инвалидның пенсиясен банктан барып алырга рөхсәт кәгазе бирү, аның нинди шартларда яшәвен барып тикшерү икән. Ә ул шартларны ничек тә булса яхшыртырга ярдәм итүче генә юк. Анысы – фәкать опекунның гына вазыйфасы. Болай булырга тиеш түгелдер, ди күңелем. Инвалид кешенең проблемалары туып кына тора. Бәлки, опекуннарга ул проблемаларны җиңелрәк юл белән хәл итәргә булышыргадыр бу комиссияләргә. Мәсәлән, фатир сатып алганда акчабыз җитеп бетмәде. Мин яшь бала белән өйдә утыргач, банктан кредит та ала алмадык. Ә бит шул чагында инвалидларга торак хәлен яхшырту өчен дәүләттән биш йөз мең сум акча бирелә торган булган. Үзең белмәсәң, аны сиңа беркем, беркайчан да әйтмәячәк. Без дә белмәдек. Район хакимияте каршында эшләүче опекунлык комиссияләрендә андый гына мәгълүматлар буладыр бит инде. Һичьюгы, мәгълүмати ярдәм күрсәтсеннәр иде.

Еламаган балага имезлек бирмиләр. Безгә, опекуннарга, үз проблемаларыбызны үзебезгә күрсәтми булмый. Бу язганнарым зарлану өчен түгел, булган мәсьәләләрне ачыктан-ачык итеп күрсәтү өчен иде.



Опека һәм попечительлек белән бәйле сорауларга Казан шәһәренең Совет районы опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Ирина СМИРНОВА җавап бирә.

Опека кемнәргә билгеләнә?

Опека ятимнәргә һәм әти-әни тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (РФ Гаилә кодексының 121 нче маддәсе, 1 нче бүлек), шулай ук балигълык яшендәге, әмма эшләү сәләте чикләнгән яки эшкә бөтенләй ярамый торган кешеләргә билгеләнә.

Опека белән попечительлекнең аермасы нәрсәдә?

Опека – 14 яше тулмаган балаларга, попечительлек 14 яшьтән 18 яшькәчә булган яшүсмерләргә һәм суд тарафыннан эшкә яраксыз дип танылган кешеләргә билгеләнә.

Кемнәр опекун була алмый?

Ата-ана хокукыннан мәхрүм булганнар, хөкем ителгән кешеләр, җинаять җаваплылыгына тартылган кешеләргә (акланган яки җинаять җаваплылыгыннан азат ителгәннәр бу категориягә керми) опекунлык рөхсәт ителми.

Җәза срогын үтәмәгән яки тулысынча үтәмәгән кешеләр, бер җенесле никахта торучылар яки шундый никахлар рөхсәт ителгән ил гражданнары да опекун була алмыйлар.

Хроник алкоголиклар һәм наркоманнар кайчандыр опекун вазыйфасыннан читләштерелгән затлар, асрамага бала алып, үз гаепләре аркасында ул бала алардан кире алынган граждannар, шулай ук сәламәтлекләре буенча РФ Гаилә кодексының 127 нче маддәсенең 1 нче бүлегендә күрсәтелгән категориягә керүче кешеләр дә опекун була алмый.

Опека ничә төрле була, һәм опекунга дәүләт ярдәм итәме?

Опека һәм попечительлекнең ике төре бар.

Берсе – түләүсез генә опекунлык итү. Бу очракта опекунга баланы ашату-киендерү өчен мәктәпкәчә яшьтәге балаларга аена 7 мең 615 сум, мәктәп яшендәгеләргә 8 мең 783 сум түләнә. Бу – Татарстан Республикасында 2016 елга билгеләнгән сумма.

Икенчесе – түләнә торган очрак. Монысы – сыендырган гаилә статусындагы опекуннар. Баланы ашату-киендерү өчен түләнә торган акчадан тыш, аларга:

- һәр бала өчен өстәмә 3 мең сум бирелә;
- опекунның медицина яки педагогик белеме булса, аңа минималь хезмәт хакының 50 проценты күләмендә өстәмә акча түләнә;
- өч яшькәчә булган баланы, гарип баланы, физик яки психик тайпылышлы баланы караган өчен опекунга тагын 30 процент өстәп түләнә.

Моннан тыш, Казан шәһәренең Башкарма комитеты опеканың түләүле төрен башкаручыларга ай саен 2000 сум өстәп түли.

Караучысыз калган балаларны опекуннарга тапшырган вакытта дәүләт бер тапкыр акчалата ярдәм күрсәтә. 2016 елда аның күләме 15 мең 512 сум 65 тиен.

Сорау-җавапларны тулысы белән сайтыбыздан укый аласыз.

PRESSA.RU



Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ЗАГС идарәсе

ЧИТТӘН КАРАГАНДА МЕНӘ ДИГӘН ПАР, БАЛАЛАРЫ ҮСӘ, ЭШ УРЫННАРЫНДА ДӘРӘҖӘЛЕ КЕШЕЛӘР... ҺӘМ КИНӘТ ШУНДЫЙ ХӘБӘР: «АЕРЫЛЫШАБЫЗ...» ЧЫНЛЫКТА, МОНДЫЙ ХӘЛЛӘР «КИНӘТ» КЕНӘ КИЛЕП ЧЫКМЫЙ ИНДЕ УЛ – ЧИТЛӘР КҮЗЕНӘ БИК БӘРЕЛЕП ТОРМЫЙ ТОРГАН СӘБӘПЛӘРЕ ҺӘРВАКЫТ БУЛА.

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

БЕР – ЯШЬЛЕКТӘ, БЕР – КАРТЛЫКТА

– Йөрисең! Күрше Хәлим белән очрашасың!

Ире аңа үзен яклап сүз әйтергә дә ирек бирмәде, үз туксаны – туксан: «Йөрисең!» Ятса да шуны кабатлады, торса да... Капканы ачып, урамга чыгу, каядыр бару, кем беләндер сүз алышу турында уйларга да мөмкинлек калдырмады: «Хәлимнән хәбәр китергәннәр, хат керткәннәр, кая яшердең?» – дип үзәгенә үтте. Хатыны ишегалдына чыкса – ияреп чыкты, өйгә керсә – керде. Мунчага барса, артыннан барып, мунча өйалдында саклап утырды. «Балалардан, килённән, тирә-күршедән оят, Хәлимнең гаиләсеннән яхшы түгел», – дигәнне ишетмәде. Сүз белән җанны кыйнавы бер хәл, аннан кул күтәрә үк башлады... Йөз-бите күгәреп йөрүләр берничә тапкыр кабатлангач, Галимә апа түзмәде. Дөресрәге, ул, бәлки, тагын алга таба да сабыр иткән булыр иде дә, читтәге балаларының түземлеге төкәнде: «Шушы яшьтә әнине кыйнатып ятып булмый бит инде», –

дип, кайтып, Галимә апаны үзләренә алып киттеләр. Ул каршы килмәде. «Аерым торып карыйк, бераз сүрелсен, акылына килсен, аннары кире кайтырмын», – дип уйлагандыр инде. Ә ире, ул китүгә, судка аерылышырга гариза язып, араларны рәсми рәвештә дә өзеп куйды... Юллар бөтенләйгә ябылды. Яшьли кавышкан, биш бала тәрбияләп үстергән ир белән хатын шулай итеп картлыкларын икесе ике җирдә уздырдылар. Көнләшүенең урынсыз икәнен соңлап булса да аңлады да бит ире, әмма өлкәнәйгән көндә үзен ил-көн алдында шулай түбәнсеткән, хурлыкка калдырган өчен Галимә апа аны инде гафу итә алмады шул... Соңгы урыннары исә менә барыбер янәшә: авыл зиратында бер чардуган эчендә яталар – анысын балалары шулай хәл итте.

...Кушылып яши дә башламаган килеш шактый яшьләрнең аерылу турында сүз кузгатуына инде күнегеп киләбез. Статистика мәгълүматларына караганда, баштагы дүрт елда никахларның 40 проценты таркала. Һәр икенче пар аерылыша дигән сүз бу. Белгечләр, ун ел элек һәр өченче пар гына аерылыша иде әле, ди. Гомергә бергә булырга вәгъдәләр бирешкән егет белән кызның бер-берсеннән шулай тиз күңеле сүрелүе, аларны кавыштырган мәхәббәтнең сүнүе фаҗига, әлбәттә. Бигрәк тә – балалар туарга өлгергәндә. Ятимнәр тагын арта, димәк... Ә менә 20-25 ел бергә яшәгән ир белән хатынның: «Аерылышабыз», – диюен без кайчак бөтенләй аңламыйбыз, кабул итәргә теләмибез бугай.

«Холыклар килешмәде...»

Аерылышканда, яшьләр генә түгел, өлкәннәрнең дә күбесе шушы сәбәпне атый икән. «Ничек инде, шул гомер килешкән дә, хәзер генә ярамый башлаганмы?» – диясе килә... Чыннан да, шулай икән, бу хатаны элегрәк тә төзәтеп булгандыр бит. Әйтергә җиңел... Бездә кыз баланы: «Барган җиреңдә таш бул!» – дип, ә ир баланы: «Берне алып – бер белән яшәргә», – дип үстерәләр. Ике арада аңлашылмаучылыклар өйләнешеп яши башлауга туса да, шуңа күрә күпләр: «Кеше ни әйтер?», «Әти-әниләр борчылыр», дип, проблеманы «онытырга», «күрмәскә» тырыша, «тора-бара ияләшербез, бер-беребезгә күнәрбез», диләр. Балалар туа. «Аларны үстерергә, аякка бастырырга кирәк», – дип уйлый ир белән хатын. Яшь чакта мәшәкатьләр дә күбрәк була бит: йорт-җирне кайгыртасы, булмаганны – булдырасы, карьера турында уйлыйсы... Нәрсәнедер үзгәртергә, гадәттә, вакыт та табылмый, үзгәртәсе дә килми. Аннан балалар үсеп җитә, таралыша, ир белән хатын икәү генә кала. Менә шул чакта элегрәк күз йомган, күрмәмешкә салышкан проблемалар баш калкыта да инде. Икәү генә торырга, иртәдән кичкә кадәр гел икәү генә булырга әзер түгелләр икән бит: бер-берсе белән аларга рәхәт түгел, күңелсез... Бер түбә астында ике ят кеше! Иренең (яисә хатынының) мең дә бер кимчелеге күзгә ташлана башлый: йоклаганда гырылдый, башкаларның гел начар якларын гына күрә, саран, чәчен атнага бер генә юа, үзе турында гына кайгырта... Яшьлектәге кебек

Акыллы киңәшләре белән мәгълүм Карен Лодато исемле ханымга ике тапкыр аерылышырга туры килгән. Димәк, аңа аерылышу хәлләренең бөтен авырлыгы таныш. «Ялгышларымны соңлап аңладым, – ди ул. – Бер авызың пешкәч, кайнар суны да өреп кабасың...» Гаиләсен, мәхәббәтен саклап калырга теләгәннәргә аның берничә киңәше бар:

■ Ирегезне санлап яшәгез. «Ул моңа лаек булган чакта хөрмәт итегез аны», – димим мин. Ир-атка үзен хөрмәт итүләрен тою бик кирәк, ул хөрмәтне бигрәк тә хатынынннан көтә. Ә без тискәреләр: «Хөрмәтне яулап алырга кирәк», – дибез. Иребезнең гап-гади бер кеше икәнен нигәдер гел онытабыз. Ул да хаталардан хали түгел, ул да ялгыша... Әмма тормыш иптәше итеп аны сез үзегез сайладыгыз. Хөрмәткә лаек кешене сайлагансыздыр бит инде. Киңәшемне тотсагыз, ышаныгыз, ул үзгәрәчәк, хөрмәткә лаек булырга омтылачак. Тик хөрмәт иткән булып кыланырга, уйнарга кирәкми – чын йөрәктән булсын.

■ Үз-үзегезне алдамагыз: ирегез малны күбрәк таба башлавы, яхшырак машина, зуррак фатир алу гына сезне бәхетле итмәячәк. Нәфеснең чиге юк. Боларына ирешкәч, ул тагын башкасына, зуррагына ымсытачак. Бүгенге тормышыгыздан канәгать, рәхмәтле була белегез. Үзегезне яки ирегезне булдыксызлыкта гаепләргә ашыкмагыз. Йөрәгегезне саклагыз!

■ Аллаһы Тәгалә, ир, балалар. Нәкъ менә шушы тәртиптә булсын. Бу очракта кайсы динне тотуыгыз әһәмияткә ия түгел: ир барыбер балалардан мөһимрәк. Самолетка утыргач, очыш алдыннан стюардесса һәрвакыт ул-бу булган очракта, үзебезне ничек тотарга икәнен искә төшерә. Хәтерләсәгез, башта кислород битлеген үзебезгә кияргә, аннары гына балага кигертергә куша ул. Дөрес бит: үзебез сулый алмасак, балага ничек ярдәм итик, ди?! Гаиләдә дә шулай. Гаилә таркала икән, балагызны тиешенчә тәрбияли алмаячаксыз. Аннан шундый көн җитәчәк: ул-кызларыгыз оядан очачак, ә сезне, ирегез белән уртак тел таба алмасагыз, ялгызлык көтәчәк.

■ Кичерегез. Беребез дә фәрештә түгел, ялгышабыз. Гафу итүне гадәткә әйләндерсәгез, көндәлек вак-төякне онытып барсагыз (мин үзем, мәсәлән, иремнең юынганнан соң көн саен сөлгесен элеп куясы урынга, ванна шкафы өстенә куеп калдыруын гафу итәм), күңелдәге ачу тау булып өелмәс.

■ Күбрәк сөйләгез. Ир-атлар бездән үзгәрәк: алар алай ук сизгер түгел. Нәрсә теләгәнеңне, ни уйлаганыңны аларга һәрвакыт әйтеп торырга кирәк.

■ Аерылышу дигән сүз авызыгыздан чыкмасын. Чынлап торып бу адымны ясарга уйламыйсыз икән, әйтмәгез. Аерылышу белән куркыту дөрес түгел ул.

■ Ирегез турында начар сүз сөйләмәгез. (Минем үземә моңардан туктау бик авыр булды!) Гаиләгез авыр чор кичерә икән – психологка мөрәҗәгать итә аласыз. Киңәш сорап ирегезне, сезне белгән якын кешеләргә мөрәҗәгать итә күрмәгез. Алар бу очракта объектив була алмаячак. Бигрәк тә – әниегез.

Фото: Камилә Димөхәммәтова

PRESSA.RU

«үзгәрер», «үзгәртермен» дигән өметләр инде юк, була да алмый. «Калган гомерне сине аңламаган, «синеке» булмаган шушы «чит» кеше белән ничек яшәп бетерермен?!» – дигән уй парларның берсен (кайчак икесен дә) айнытып җибәрә. Хәер, шушы уй башларына килеп тә, язмышлары белән килешеп, гаиләдә яшәп калучылар да байтак. Әмма аерылышырга тәвәккәлләүчеләр дә бар.

Белгечләр, «холыклар килешмәде»нең төп сәбәбе ир белән хатынның үзара аралаша, бәхәс-конфликтларны чишә белмәвендә дип аңлата. Холыкның монда катышы юк, диләр.

Быелның тугыз аенда Татарстанда 10 108 пар аерылышкан. Шуларның 1601 е (ягъни 15,8 проценты) бу карарга бергә инде егерме ел һәм аннан да күбрәк яшәгәч килгән.

«Эчүеннән арыдым...»

– Очрашып йөргән чакта, салгаларга яратуын сиздермәде шул, – дип сөйли Гөлсинә апа. – Туйдан соң бер туганнарына кунакка бардык: ирем ике чәркә аракыны бер-бер артлы күтәрде дә куйды! Шуннан башланды... Буемда бар иде инде: бала тугач туктамасмы, дип өметләндем. Булмады... «Кыз янына малай алып кайтсаң, эчмим», – дип тәүбә итте. Ышандым. Улыбыз туды, ә ул эчүен ташларга уйламады да. Балалар «әти» дип әйтергә тилмермәсен, дидем, тагын түздем. Хәзер үкенәм: исерек белән араны яшь чакта ук өзәргә кирәк икән. Язмышым бөтенләй башкача булыр иде... 25 елдан соң аерылыштык. Үз йортыбыз белән тора идек: рәсми рәвештә аерылышсак та, бер түбә астында яшәп калдык. Балалы бер хатынны ияртеп кайтты. Алар зал ягында тордылар, мин – йокы бүлмәсендә... Өч ел шулай яшәдек. Моны яшәү дип атап булса... Хәзер әнә: «Кертәсеңме, кире кайтыйм әле», – ди. «Юк инде, чыгып киткән җирендә генә тор», – дим...

Сер түгел: яшьрәк чакта күпләр якын кешесе хакына күп нәрсәгә түзә, күз йома, килешә, кичерә. Аның бәйрәмнәр яратуын да, бар тапканын комарлы уеннарда юкка чыгаруын да, вакыт-вакыт кул күтәрүен дә... Әмма түземлекнең дә чиге була! Олыгаеп килүче хатын-кыз, болай да гомере буе түзгән исерек белән җәфаланганчы, ялгызы, балалары, оныклары белән генә яшәүне инде өстенрәк күрә.

«Балабыз юк...»

Аерылышуларның бер сәбәбе – кысырлык, ирнең яки хатынның бала алып кайтырга теләмәве. Кайчакта парлар әти-әни булуны белә торып суза: башта карьера ясыйк, яхшы фатир алыйк, дөнья күрик, диләр. Тик һәрнәрсәнең үз вакыты шул: бала сөю теләге туганда, алар инде моңа сәләтсез булып чыга. Россиядә гаиләләрнең 15 проценты бу бәхеттән мәхрүм... Яшьрәк чакта: "Иртә әле, өлгерербез", – дип, хатынын бәби алып кайтудан тыеп торган ир-атның күбесе, бала табу белән бәйле берәр проблема туугач, аерылышу турында сүз кузгата. Аерылып, яшьрәк хатынга өйләнеп тә куя. Бер парны беләм: балалары булмауга ир гаепле икәне яшь чакта ук ачыкланса да, хатыны аның белән кала. «Язмышым шулдыр», – ди... Икесенә дә 45 яшь тулгач, ир: «Берәүне очраттым... Ичмасам, аның уллары булса да сөярмен», – дип, ике балалы хатынга китеп барды.

«Ул мине канәгатьләндерми...»

Ике арада рухи якынлык булмау, ир белән хатынның уртак түшәгенә дә үтеп керә. Аларның бер-берсенә

БЕЛГЕЧ КИҢӘШЛӘРЕ



Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы, профессор:

Өлкән яшьтәге аерылышучыларны мин ике төркемгә бүлеп карар идем. Беренче төркем – пенсия яшенә җитеп килүчеләр яки күптән түгел пенсиягә чыккан кешеләр (50-65 яшь); икенче төркемдә – 65 яшьтән өлкәнрәкләр. Беренче төркемдәгеләр гаилә таркатуга шактый еш бара һәм аның сәбәпләрен бераз соңрак карарбыз. Ә менә инде олы яшьтәгеләр арасында аерылу очраклары бик сирәк, юк дәрәҗәсендә диярлек. Өлкәннәр арасында аерылышуның төп сәбәбе – олы яшьтәге кешенең психик статусы, холкы кискен үзгәрү. Кызганычка каршы, картлык үзенә ияртеп бик күп күңелсезлекләр, шул исәптән, психологик проблемалар алып килә. Кешенең холкы үзгәрә, аны тыеп торган бикләр йомшара, психиканың контроль функцияләре кими. Бу үз чиратында яшьрәк чакта акыл, ихтыяр көче басып торган тискәре сыйфатларны өскә калкыта. Кешенең үз-үзен тотышы үзгәрә, ә аерым бер очракларда гомумән дә акылы авыша. Күп гаиләләрдә мондый үзгәрешләрне сабыр гына кабул итәргә тырышалар. Монда туганнарның, күрше-күләннең, балаларның роле зур. Ләкин кайбер очракларда, аеруча холыксызлык аркасында агрессивлык көчәйгәндә аерылышу бердәнбер дөрес юл булып кала. Кызганыч, бу вазгыятьтә бөтен як та оттыра: ир белән хатын картайган көннәрендә күнегелгән тормышларын үзгәртергә мәҗбүр булса, балалар ике ут арасында калып, кайсы якны кайгыртырга белми… Мондый катлаулы хәлгә калган гаиләләргә шуны әйтер идем: бу очракта төп шарт булып чыккан җәнҗалны дәвам

тартылмавы, женси мөнәсәбәтләрнең булмавы яки аз булуы – бу яшьтә аерылышуларның иң төп сәбәпләренең берсе шушы, ди белгечләр.

«Ул миңа хыянәт итә...»

Шагыйрь әйтмешли, әйе, «өчпочмактан тора бу дөнья...» Һәм бу очракта өченче, артык кеше күп вакыт хатын-кыз була. Яшьрәк чакта читтә мавыгулары булса да, гаиләдән китәргә җөрьәт итмәгән ир кинәт хәзер тәвәккәлли. Күпләр бу адымны «урта яшьләр кризисы»н кичергәндә ясый. Бер танышым әйтмешли, ир-ат бер гомердә әллә ничә тормыш яшәмәкче... Картлыктан, тиздән киләчәк үлемнән куркып (әйтерсең, яшь хатын янына китеп кенә аннан качып котыла аласың!) ясалган әлеге адымның күп вакыт мәхәббәт белән бернинди бәйләнеше дә булмый. Гомумән, гаиләсеннән киткән ир-атларның 30 проценты беренче хатынын сагынып яши, ди әнә белгечләр. Күперләрне бөтенләй яндырып китмәгәндә кире кайтучылар да бар. Кайтырга мәҗбүр булучылар да. Бер мисал менә: кызларын кияүгә биргәч, танышымның ире, нәкъ кызы яшендәге сөяркәсе янына чыгып китте. Хатынының ул чакта түккән күз яшьләре! Ашау-эчүдән калды, ябыкты. «Кичке ашны һаман икебезгә әзерлим әле», – дип, бик озак вакытлар сөйләде ул. Ә аннан ире инсульт кичерде һәм... яшь бичәсе аны өенә кире китереп куйды. Нишләсен, «балаларымның әтисе бит» дип, хатыны кабул итте – авыру кешене урамга чыгарып ташлый алмыйсың! Тәрбияләп аякка да бастырды әле. Кемнең кем икәнен аңларлык сабак булды бу иргә, тик күңелләрдә беркайчан онытылмаслык юшкыны гына калды. (Ир-атның акыллысы бу яшьтә гомер иткән хатынын, гомумән, ташламый. «Мин яңа гаилә дә кора алам, ә ул?» – дип уйлый андый ир. Балаларыңның әнисе бит ул, синең белән бөтен авырлыкны бергә кичкән, сиңа таяныч булган кеше...)

«Мин аннан туйдым...»

Кешенең гомер озынлыгы хәзер шактый озын, гел берәү белән генә яшәп ул ялыга – аерылышуларның бер сәбәбе шул, ди белгечләр. Бәхәслерәк фикер. Тормыш юлыннан шулкадәр вакыт янәшә атлагач, ул синең сулар һаваңа әйләнергә тиеш ләбаса! Синең холкыңны, нәрсә ярату-яратмавыңны белгән, теләкләреңне әйтмичә дә аңлаган, үтәгән кеше көннәрдән бер көнне ялыктыра ала димени?!

Кырык яшьтән соң аерылган хатын-кызларның өчтән бере генә яңа гаилә кора.

...Аерылу – канатың каерылу, ди халык. Яшьрәк чакта «яралар азрак җөйләнсен дә, тормышны яңадан башлыйм» дигән өмет бар. Ә бишенче, алтынчы, җиденче дистәне ваклаганда... Алны-артны уйламый ниндидер адымнар ясый торган чор инде артта калган. Бу яшьтә кайбер мәсьәләләрне хәл итү дә шактый катлаулана. Әйтик, акча мәсьәләсе. Ирен эшкә озатып, каршы алып кына яшәгән хатын-кызның күбесе, аерылганнан соң матди кыенлыклар кичерә. Һөнәре, белеме булса ярый әле. Тик кулында «хезмәт кенәгәсе» дә булмаса, эшкә кем алыр? (Һәм, гомумән, гомер уртасында ялгызы калганда хатын-кызга күпкә авыррак, кыенрактыр.)

Тик, ни генә булса да, яшәргә кирәк. «Без күрәсен кеше күрмәс», – дип, тормышыгызда булган шушы үзгәреш белән килешергә һәм яшәргә. Кешегә сынауның үзе күтәрә алганыннан да авыррагы килми, диләр... Иң элек күңелдәге үпкәләрдән арынырга кушалар. Монысы – иң авырыдыр... Ахирәтләргә сөйләп күңелне бушату – бер нәрсә, тик бу очракта белгеч киңәшләренә колак салу дөресрәк булыр.

итмәү тора. Алтын урталыкны табып булмаса да, очрашкан, аралашкан вакытта мөмкин булганча, сабыр, түземле булып калырга кирәк. Балалар исә, кем гаепле, кем гаепсез булуга карамастан, мөмкин кадәр ике якка да ярдәм кулы сузарга бурычлы – аларны бит шул әти-әни тәрбияләп, кеше иткән.

Беренче төркемгә килгәндә, монда башлыча ике сәбәп гаилә таркалуга китерә: эчүчелек һәм яңа гаилә төзү. Беренче очракта хатын-кызлар инициатива күрсәтсә, икенче очракта, гадәттә, ир кеше башлап йөри. Озак еллар буе исерек ир белән гомер кичергән, инде түзәрлеге калмаган хатын, картлыгым булса да тыныч узсын дигән фикердән чыгып, аерылырга карар кыла. Һәм бу адымны бары хупларга гына мөмкин, кызганыч, бу фикергә иртәрәк килмәгән дияргә генә кала.

Яңа гаилә кору белән бәйле аерылышулар бөтенләй башка, тирән, газаплы вакыйгалар аша бара. Моның сәбәбе бераз соңарып килгән, яки озаккарак сузылган «урта яшьтәгеләр кризисы» белән бәйле. Гомер уртасын узган ир-ат (сирәк очракта хатын-кыз) үтеп баручы яшьлекне туктату, озаккарак сузу өчен ни генә кылмый! Ярый ла «тузыну» яшьләрчә киенү-ясану, күңел ачулар белән генә тәгәлләнсә! Еш кына эш гаилә җимерелүгә, яңа яр сайлауга барып җитә. Балалар инде үз тормышы белән яши, гөрләп торган гаилә учагы сүнеп юкка чыга... Мондый катлаулы хәлгә тап булган ханымнарга шуны әйтәсе килә: яраткан иремне кайтарам дип җан көчегез белән тырышудан файда юк. Сезнең өзгәләнүегез, гаиләне таркатмаска тырышып кылган һәр адымыгыз көндәшегезгә көч кенә өсти. Акылы томаланган ир дә сезне аңламастыр... Аның акылына киләсе көне әле алда, ә сезгә бүген яшәргә кирәк: көчегезне юкка сарыф итеп түбәнсенмәгез! Үзегез турында уйлагыз – сәламәтлегегезне кайгыртыгыз, яңа шөгыль табыгыз. Бәлки күптән хыялланып та эшләнмәгән эшләр бардыр, балаларыгыз, оныкларыгыз белән аралашыгыз. Тышкы кыяфәтегезне кайгыртыгыз. Хәсрәткә чумып яшәмәгез!

PRESSA.RU



ТОЗ-ТҮБӘ КАРБЫЗЫ



Гөлнур САФИУЛЛИНА

– СОҢГА КАЛДЫГЫЗ БИТ! СЕЗОН ЯБЫЛДЫ – СУ КОЕНА АЛМЫЙСЫЗ...

«Тоз-Түбәгә барабыз әле», – дигәнне ишетүгә, һәркем шулай дияргә ашыкты. Әйе, күлләр чоры узды, беләм, тик безнең озын юлга кузгалуның максаты башка әле. Карбыз! Тоз-Түбәдә карбыз сезоны – иң зур җиләкнең эрмәкләнеп пешкән, авызда эреп китәрдәй булып балланган вакыты...

Тоз һәм... карбыз

Карбыз тозлыйбыз. Дөресрәге, Светлана тозлый, ә без фотога төшереп, тозлау тәртибен язып барабыз.

– Тозлау өчен карбузның (тозтүбәлеләр шулай сөйләшә – *Г. С.*) «Холодок», «Икар» сортлары әйбәт, – ди ул. – Төшләрен алып, зур гына кисәкләргә бүлгәләп, стериль банкаларга тутырабыз. Өстенә кайнар су коеп, 10 минут тотканнан соң, бушатып, суны түгәбез. Тагын бер кат кайнар су коеп, бу юлы 4 минут тотабыз. Инде карбуз тутырылган 1 литрлы һәр банкага 2-3 аш кашыгы шикәр комы, 1 аш кашыгы тоз һәм 20 грамм серкә салып, өстенә кайнар су коеп, капкач белән ябасы гына калды. Нәкъ помидор тозлагандагы кебек, банкаларны әйләндереп, томалап куябыз. Тозлаган карбузны салкын урында сакларга кирәк булачак...

Карбыз һәм тоз... Сәеррәк яңгырый, әйеме? Алдан ук әйтеп куям: тозлы карбыз һәркемнең күңеленә шунда ук хуш килмәскә дә мөмкин. Мин үзем яраттым. Ә карбыз балы... Анысын яратачагыгызга шикләнмим! Әмма ясарга... Шулай да, сүз чыккач, язып үтәм: карбызның йомшагыннан блендерда сок ясыйбыз. Ике кат иләк аша үткәргәннән соң, 5-6 сәгать әкрен генә утта кайнатабыз. Соңрак гел бутап торабыз. Куерса, кашыктан акмый башласа, балыбыз әзер диген сүз. 5-6 карбыздан 500 грамм бал чыга. Тәмле!..

...Утыз мең кеше яшәгән Тоз-Түбәдә Мифтаховларны белмәгән кеше сирәктер. Беренчедән, гаилә башлыгы Ринат бөтен калага билгеле теш табибы. Үзенең теш дәвалау кабинетын ачкан иң беренче эшмәкәр! Икенчедән, ул Тоз-Түбәдәге иң зур карбыз базарының хуҗасы. Өченчедән, менә диген гаилә башлыгы! Дүртенчедән...

«Ринат урам буйлап барса, аның башы гел селкенеп кенә тора», – дип көлә Светланасы. Күршеләр, дус-ишләр, сыйныфташлар, таныш-белешләр, пациентлар... Кечкенә шәһәрнең язылмаган кагыйдәсе: һәркем белән исәнләшәсе, хәл-әхвәл сорашасы... Шушында туып-үскән ул. Бөтен балачагы әнә шул күлләрдә каз-үрдәк саклап үткән. Ә карбыз... Бүгенгедәй бакчалар тутырып үсмәсә дә, карбыз, әлбәттә, булган.

– Карбыз белән кара ипинең ничек тәмле икәнен белсәгез иде сез?! Урамга күтәреп чыгасың, беләк буйлап карбызның суы ага, бармаклар ябыша... – дип сөйли Ринат. – Колхозлар иген игү белән генә шөгыльләнә иде без кечкенә чакта. Халыкка карбыз үстерергә рөхсәт итмәделәр. Алай гынамы, хәтта тыйдылар. Әмма бездә бик тырыш халык яши, җаен барыбер таба иде. Көзен, ике-өч күрше җыелып, бакчаларында үстергән азмы-күпме карбызны йөк машинасына төяп, гадәттә, Башкортстан ягына алып китә. Бәрәңгегә алыштыралар яки саталар. Бездә бит бәрәңге начар үсә, аңа яңгыр кирәк. Ә карбызга үсү өчен кояш та җитә, суны ул үзе эзләп таба. Әтиләрнең кайтканын түземсезлек белән көтә идек – шул акчага безне мәктәпкә киендерәләр бит...



■ Медицина училищесын тәмамлаган Ринатны районның Маяк авылына эшкә җибәрәләр. Ә Светланалар исә анда бердәнбер татар гаиләсе була. Әлбәттә, танышалар. Әтиләре исә күптән бер-берсен белгән икән, яшьләр аларга: «Безне «ялгыш кына очраштыру» ничек башыгызга килмәде соң?» – дип үпкәләп тә йөриләр әле. Ике кыз үстергәннәр. Бер ай элек төпчек кызлары Ренатаны кияүгә биргәннәр. Һәм шул ук көнне олы кызлары Эльвираның улы – оныклары Таһир туган!

Фото: Алинә Галиәхмәтова

Карбызны зур мәйданнарда үстерә башлау әллә никадәр үзгәрешләр алып килгән. Чәчү орлыгын халык хәзер әзерләми, сатып кына ала. (Орлыкның 1 килограммы 2 мең сум тирәсе. Бер гектарга 500-700 грамм орлык кирәк. Уңыш әйбәт булса, гектардан 10 тонна карбыз алалар.) Тоз-Түбәнең үз карбызы бик нәзберек, аның кабыгы юка – ерак илтеп булмый, шуңа күрә күбрәк Голландия сортларын кайтарталар. Һәм ул сортлар гел үзгәреп тора. Үзләренең «Холодок»лары талымсыз, аңа бөтен җәйгә ике яңгыр җитә, читтән кайткан сортларга исә су сибәргә дә кирәк. Аның каруы, алар тизрәк өлгерә. Ә иртә өлгергәннең хакы бөтенләй башка: июньдә карбызның килограммы 20-25 сум тора. Тоз күленә халык агылганда Тоз-Түбәгә үзбәк, казакъ карбызы килеп тула. Бүген исә Тоз-Түбәдә карбызның иң баллысын саталар. Кызганыч, ул көннәр сүрелә төшкәч, су коенучылар беткәч кенә өлгерә...

Карбызның җир өстендәге сабагы, әйтик, алты метр булса, җир астындагы тамыры да алты метр була икән.

Карбыз дошманнары

Ринат: «Мин сезгә карбыз бакчасын күрсәтәм!» – ди. Барабыз, билгеле, карбызлар җирдә тәгәрәп үскәнне ничек күрми китәсең?! Бакча, әйтүе буенча, алай бик зур түгел. 20 гектарлы гына!

Бер бакчага икенчесе, өченчесе кушылып киткән... Офыкка кадәр җир өсте карбыз гына! Иген игүнең

PRESSA.RU



■ Карбыз тозлау һәм карбыз балын әзерләү буенча мастер-классны сайтыбыздан карый аласыз. «Аш-су» сәхифәсе.

табышлы түгел икәнен күптән аңлаган Тоз-Түбә районы, колхозлар таралгач, тоташ карбыз үстерүгә генә күчкән дисәң дә була. 600 мең гектар мәйдан дигән сүз бу! Волгоград, Әстерхан өлкәләре белән чагыштырганда күпкә күбрәк. (Кызык, алыпсатарлар безгә нишләп бер дә «Тоз-Түбә карбызы» дип тәкъдим итми икән? Себергә кадәр барып җиткәнне, Татарстанны гына урап узмыйдыр бит Оренбург карбызы? Без, иялашкәнчә, сатучылардан Әстерхан, Волгоград карбызы сорыйбыз, алар без ишетергә теләгән җавапны бирә, күрәсең.)

Тоз-Түбә курорты – Россиянең карбыз башкаласы.

– Чебиневлар бакчасы бу. Әнә дядя Коля үзе дә монда икән, – ди Ринат. – Кара, татарча исеме ничек икән аның?

Хөснелхак исемле булып чыкты яңа танышыбыз. (Якташ дисәң дә ярый, әтисе Татарстанның Алексеевский районыннан булган: бәхет эзләп читкә киткән җирдән, сугыш вакытында үзе эшләгән завод белән бирегә эвакуациягә килгән. Сварщик буларак аңа бронь бирелгән. Сугыштан соң завод күченгән, ә ул шушында төпләнеп калган. Тоз-Түбә аның балалары өчен туган җиргә әйләнгән.) «Нишлисең, чит халык арасында яшәгәч, «дядя Коля» булып йөрим. Монда шулай... Минем хатын мөнә игезәк сыңары: Сафия белән Суфия исемле алар. Мәктәпкә баргач укытучылары: «Берегез Валя, икенчегез Галя булыр», – дигән. Гомер буе шулай яшәделәр», – ди. Хөснелхак абый машинасына карбыз төягән: базарга барышы. Ул шулай кырдан аз-азлап алып кайтып, ә хатыны Суфия апа сатып тора икән.

Карбыз үстерүгә Хөснелхак абый 1997 елны тотынган.

– Чөгендер игү кебек, мәшәкатьле эш бу. Дөрес, бәлки бераз җиңелрәктер, – дип сөйли ул. – Трактор белән утыртабыз, аннан ике-өч кат утыйбыз. Сирәклибез, карбызның арасы тыгыз түгел – ике метрга якын калырга тиеш. Шуңа күрә чөгендердән җиңелрәк, дидем. «Продюсер», «Ярило», «Кримсон» сортларын үстерәбез. «Холодок» – үзебезнеке, Тоз-Түбә сорты. Ә менә монысы – «Икар». Аны «Холодок»ны ниндидер сорт белән кушып чыгарганнар – «улы» дисәк тә ярый... Сыйфатлары да «Холодок»ныкы кебек үк: Яңа елга кадәр сакларга мөмкин, тозларга да ярый. Саклау дигәннән, карбызны 8 Март бәйрәменә кадәр саклаганым бар. Элеккегеләр кебек, игенгә дә күммәдем, гаражда гына тоттым. Ә бер елны карбызны майда, бәрәңге утыртканда гына ашадык. Дөрес, тәме әллә ни түгел иде инде...

Үстергән карбызны урнаштыру гына елдан-ел авырлаша. Быел менә «соленщиклар» килергә өлгермәде, Казакъстан карбызын китереп тутырдылар. Хәзер карбызның яхшыларын, 7-8 килограммлыларын 2 сумга алалар. Төягән өчен йөкчеләргә дә биргәч, карбыз үстергән кешегә 1 сум 50 тиен кала. Кайда отасың, кайда оттырасың – безнең эштә әйтү авыр. Бер елны улым Рәшит 2 сум 70 тиенгә сатты, ә өч көннән карбызның бәясе 7 сумга күтәрелде. Нервларның бик нык булуы кирәк монда... Сатмыйча тотар идең – кырау төшүе бар. Россиянең үзәк районнарында салкыннар башланса, сатып алучылар шулай ук килмәячәк: карбыз бик нәзберек бит ул. Салкын да ярамый аңа, бәрелү-сугылу да.

Бакчаның икенче башындагы каравылчылар карбызны угры-фәләннән саклый дип уйлаган идем мин. «Кеше алса – бер-икене ала, анысы зур югалту түгел», – ди бакчачы. Чынлыкта, карбызның иң зур дошманы... карга икән! Чукыдымы – карбыз әрәм булды дигән сүз. Мылтыктан аталар, петарда шартлаталар – шулай куркыталар карганы. Тагын карбызга «һөҗүм» итүче саескан бар әле, куян, йомран, кыр тычканы бар... Яңгыр күп елны «медянка» чире чыга. Карбызның җиргә тиеп торган ягы астында дым калса, «проволочник» үрчи... Кояш пешерә.

– Карбызны үзем бик сирәк авыз итәм, – ди Хөснелхак абый. – Гадәттә, яңа утырткан сорт өлгергәндә, тәмен белер өчен генә ашап карыйм.

Карбыз базары

Ринатның бер гектар мәйданны биләгән карбыз базары шәһәргә кергән җирдә үк урнашкан. 2002 елда ачкан ул аны. Ә аңа кадәр бер дусты белән гектар-гектар карбызны кырда үзе үстергән: бу эшнең бөтен нечкәлекләрен белә. (Бер үк вакытта өе янында теш дәвалау клиникасы салып куярга, апасы, ике кызы белән анда халыкны кабул итәргә дә өлгерә ул!)

...Көн уртасы якынлашып килә. Базар тулы карбыз, кавын төягән машина. «Бу ни бу?! Сатып алучылар бөтенләй күренми... Бакчачылар җиләкләрен кире алып кайтып китәрләрмени?!» – дим. «Барысы да тәртиптә, – дип тынычландыра мине юлдашым. – Сатучы белән сатып алучы бер-берсенең ихтыяр көчен сыный әлегә. Карбызга килгән әзәрбайҗан егетләре базар тирәсендәге кафеларда утыра, каһвә эчә. Берәүләре кыйммәткәрәк сатмакчы, икенчеләре арзангарак алмакчы».

Алучыга караганда, сатучысы барыбер күбрәк кебек тоелды миңа... Алай дисәң, фуралар да аз түгел: Тоз-Түбәдә «Илецк-1» узел станциясе урнашкан – Казакъстан, Үзбәкстаннан килгән барлык җиләк-җимеш, яшелчә шушында бушатыла, логистика үзәге аны бөтен Россиягә тарата.

Безнекеләр

Тоз-Түбә белән танышуны дәвам итәбез. Әлбәттә, күлләргә сугылабыз. Һәр көнне илле мең туристның шушында ял итә алуын күз алдына китерүе авыррак... Һәм бу сан ел саен арта бара! «Безнең шәһәр моңа әле әзер түгел», – ди юлдашым. Ләкин тиздән, мөгаен, барысы да үзгәрер: Тоз-Түбәгә инвесторлар килә башлаган. Шактый күп төзелешләр бара. (Сүз уңаеннан, шәһәрнең үзәгендә гап-гади йорт 4-5 миллион тора аларда. Оренбургның үзендә дә мондый бәяләр юк!) Күлгә килүчеләр озакламый «Россоль»нең тоз шахталарында экскурсиягә дә төшә алыр: Илек тозын 300 метр җир астыннан чыгаралар. Ә анда бик матур, диләр! Өстәвенә, тоз парларын сулау шактый чирләрдән дәва.

Тоз-Түбә диюгә, күпләр «Кара дельфин» төрмәсен искә төшерә. Гомерлеккә хөкем ителгән тоткыннар утыручы төрмәне каланың күрке дип әйтеп булмый булуын...

Сүзебез татарларга таба борыла. Тоз-Түбә районында 5 мең чамасы милләттәшебез яши икән. Татар мәктәпләре юк. Инде күптән юк... «Туган телдә белем алучыларның соңгылары безнең әниләр булган», – ди Ринат. Димәк, татар сыйныфлары узган гасыр урталарында ук ябылган... Соңгы вакытта мәчет каршында «якшәмбе мәктәбе» эшли башлаган: Әминә апалары Нуретдинова балаларга туган телләрен өйрәтә. Уникеләп бала йөри икән. Аз да бит...

Моңарчы Татар Линевкасы авылында гына уза торган Сабантуй быел беренче тапкыр Тоз-Түбәдә дә гөрләгән! Татар автономиясе оештырган аны. Рафаэль Вәлиев дигән депутат егетләре приз фондына 100 мең биргән, калган эшмәкәрләр кем – 20, кем 15 мең...

– Борынгы мәчет булган Тоз-Түбәдә. Аны 60 нчы елларда җимереп, урынына ДОСААФ бинасы салганнар. Кире кайтарырга бик озак йөрдек, – дип сөйли Ринат. – «Яңа бина салып бирсәгез генә», – диделәр. Каланың бөтен мөселманнары – татарлар, үзбәкләр, казакълар, төрекмәннәр кушылып, 4 миллион акча җыйдык. Яңа ДОСААФ төзеттек, автодром эшләдек. Бу атнаны менә Мәскәүдән вәкил көтәбез – документлар алышыну булырга тиеш. 40 сутый тирәсе җир анда. Уфадагы кодам проектын эшләргә вәгъдә итте: халык яңа мәчет төзергә акча җыя хәзер. Икенче мәчетебез булачак бу...

СҮЗЛЕК:

Бахча (бакча) – болай дигәндә тозтүбәлеләр өй янындагы 20-25 сутый бакчаны гына күз алдында тотмый. Карбыз, кавын үсүче 100 әр гектарлы кырларны да «бакча» дип атый алар.

■ «Башкирятник» – хуҗаларның ишегалларында күлгә килүчеләрне урнаштырырга төзелгән кунак бүлмәләре. Тоз-Түбәнең беренче туристлары – Башкортстаннан булган икән.

■ «Соленщик» – күлгә килгән туристларны шәһәр халкы шулай атый.

Селекционерлар бүген Тоз-Түбәнең ак төсле гаҗәеп баллы карбызын яңадан үстермәкче.

Татарлар Муса Җәлил исемендәге клубта очраша. Аны Әхәт Ягъфәров дигән эшмәкәребез сатып алып, ремонтлатты. Балалар шунда бушлай бию түгәрәгенә йөри. Гает бәйрәмнәрендә чәй табыннарын шул клубта әзерләдек. Әхәт Мидхәтович мәчеткә дә бик күп ярдәм итте. Комбат булып хезмәт итте ул, пенсиягә чыккач, эшкуарлыкка кереп китте. Уку китаплары сатудан башлаган иде...

...Тагын аз гына вакыт узар да, Тоз-Түбә бушап, тынып калыр. Хәер, тынып калган кебек тоелыр гына. Чынлыкта, шәһәр инде чираттагы сезон башлануын көтәр. Май җитүгә калага янә халык агыла башлар: кем карбыз утыртырга, кем кафе ачарга, кем күлдә эшләргә, кем төзелешкә...



PRESSA.RU



ТӨП ЙОРТ КИЛЕНЕ

МИЛЛӘТНЕҢ КӨЧЕ – АНЫҢ ТАМЫРЛАРЫНДА. Ә МИЛЛӘТ ТАМЫРЫН ГАИЛӘЛӘР ТӘШКИЛ ИТӘ. ТАТАР ХАЛКЫНДА ГАИЛӘ УЛ – ИЗГЕ ТӨШЕНЧӘ, АҢА БӘЛӘКӘЙ БЕР ДӘҮЛӘТ ИТЕП КАРАГАННАР.

Фирая талантлы шәхесләре белән республикада танылган Зыятдинныкылар нәселенә килен булып төште. Бу гаиләнең тамырларына күз салыйк. Бер нәселнең язмышы аша татар җәмгыятендә һәм гаиләдә хатын-кызның урыны турында фикерләшеп, нәтиҗәләр ясап карыйк.

Тарихтан бик еракка китмичә, Булат кияүнең әти-әнисе Бакый абый белән Мәдинә апа кавышкан көннәргә кайтыйк. Бакый абый үзенең истәлекләрендә: «Без туганлашкан гаиләләр бер-берсенә шактый охшаш булып чыкты. Без алты бала булсак, Мәдинәләр сигез бала үскәннәр. Ике яктан да әтиләр сугыш инвалидлары, сугыштан сыңар аяк белән кайтканнар. Мәдинәләр – Гафурҗан гаиләсе, шул чор өчен таза тормышлы. 1951 елгы янгыннан соң төзелгән өйдә гомер итәләр, каралты-кура нык. Бу ныклык Гафурҗан бабай балта остасы булганга күрә», – дип яза.

Чәй табыны янында кабаклы борай боткасы белән сыйлана-сыйлана бергә эшләгән елларны искә алабыз, әкрен генә тормыш йомгагын сүтәбез. Мәдинә апа: «Әби шулай пешерә иде», – дип, борай боткасының рецептын искә төшерә.

«Мин әби-бабай белән үстем, – ди ул. – Әти-әни көн-төн эштә, безне өлкәннәр үстерде. Берчакны сеңлем Фәймә бәбкә саклаган җирдән йоклап китте. Уянгач, косты-косты да аңын җуйды. Бер атна аңсыз яткан баланы әби карады. Бер сәкедә сеңлем, икенче сәкедә бабай салкын тидереп авырып ята. Әби – икесе арасында. Безгә белгән догаларыбызны укып, сеңлебезнең терелүен теләргә куша. Әти табиб алып кайтты. Әмма ул бусагадан бала ятагына таба килмәде: «Бу балада тиф, минем даруларым юк, үзегез дәвалагыз», – диде дә, борылып чыгып та китте. Сеңлемне үзенең үләннәре һәм догалары белән әби аякка бастырды».

Мәдинә апа укымышлы, зирәк әбисенең сандык тулы китапларын укырга бик кызыга, шуңа гарәп һәм латин алфавитын тырышып өйрәнә, әкренләп укый да башлый. Тик ул укырга керәсе елны мәктәпләргә кириллица кертелә. Әбисе: «Синнән марҗа ясарлар инде», – дип, күз яшьләре белән елый. Юк, марҗага әйләнми Мәдинә. Милләт анасы, авыл анасы булырлык зыялы ханым булып ил-көнгә танылa. Ни кызганыч, төп нигездә каралты-кура ике мәртәбә яна, шул янгында күп истәлекләр белән әби сандыгы янып бетә. Сигез баланың һәркайсы төпле белем алып, сайлаган һөнәрләренең чын осталары була. Мәдинә апа мөгаллимә булып, Карадуган мәктәбенә эшкә билгеләнә. Һәм үзеннән бер көн алдан гына шушы мәктәпкә физика укытырга килгән Бакый Зыятдинов белән таныша.

Егет белән күзләре очрашкач, каушап, югалып кала кыз. Каушарсың да, килешле буй-сын, дулкынланып, күпереп торган чәчләр, күк йөзедәй якты зәңгәр күзләр. (Кызлары Чулпан белән уллары Булат та нәкъ әтиләре төсле.)

Дусларча очрашу-аралашулар чын мәхәббәткә әверелеп, аерылу сынауларын үткәч (егетне әүвәл башка мәктәпкә күчерәләр, аннан армиягә алалар), 1955 елда гашыйк җаннар, кавышып, гаилә кора.

Килен булып төшкән нәселнең тамырлары нык, үзләре укымышлы. Зыятдин карт оныгы Бакыйны яхшы укыган өчен Казанга алып бара. 70 яшьлек бабай белән малай Таузар–Арча арасын җәяү үтә. Бабай очраган юлчыларга: «Отлично»га укыганы өчен шәһәр күрсәтергә алып барам», – дип горурланып сөйли. Зыя карт сугышка кадәр үк «Кызыл Татарстан» газетасын алдырып укый. Нечкә күңелле, җыр-моңга гашыйк тәвәккәл әбиләре беренче бакалар кычкыруга Шушмада су коена, камыштан курай ясап, гаҗәеп моңлы итеп уйный торган була.

Уң кулы белән бишек тирбәтүче Ана, сул кулы белән дөньяны «селкетә» ала.

Мәдинә ханым ата үз урынында булган, ана үз урынын белгән төпле татар гаиләсе – Шәймулла белән Ләмига йортына тугызынчы җан булып килеп керә. Физик һәм рухи яктан көчле, туган җанлы, гармун, музыкага хирыс, нечкә хисле, заман сулышын аңлап яшәүче кайнатасы киленне сабыйларча куанып каршы ала.

Бакый ага бергә яшәгән елларын менә ничек искә ала: «Төп йортка туганнар күп җыела, шуның өстенә мәктәп директорының да кунаклары булып тора. Мәдинә ашсуга оста: чиста өй, хатынымнан якты йөз булгач, миңа тыныч. Эштә – яхшы укытучы һәм класс җитәкчесе, шуңа директор буларак миңа башка укытучылардан эш таләп итү җиңел иде. «СССРның халык мәгарифе отличнигы», районда беренчеләрдән булып «өлкән укытучы» исеменә ирешкән педагогның эш тәҗрибәсе Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтында хупланды, «Мәгариф» журналында язылды».









PRESSA.RU

40 ел мәктәптә укытып, пенсиягә чыккач, Мәдинә апа районда беренчеләрдән булып әхлак дәресләре, дин сабагы укыта башлый. Күренекле галим Ризаэтдин Фәхретдин дә: «Дини тәрбия булмаса – ул тәрбиясезлек», – дип язган. Һәм күп еллардан соң, ниһаять, кабат асылыбызга кайту, балаларны ислам кануннары нигезендә тәрбия кылу башланды.

Зыятдиновлар зыялы, тәртипле, укымышлы өч бала тәрбияләп үстерде. Нурия – югары категорияле табибә, Чулпан – математика мөгаллимәсе, педагогика фәннәре кандидаты. Булат – Казан авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлап, «Игенче» күмәк хуҗалыгында рәис.

Бакый ага 46 ел мәктәптә эшли. Шуның 35 елы – мәктәп директоры вазыйфасында. Оста педагог һәм җитәкче, «Татарстанның атказанган укытучысы», «РСФСРның атказанган укытучысы» исемнәренә лаек була. Бу уңышларда 59 ел янәшәсендә атлап, аңа терәк булган Мәдинә апа өлеше дә бар.

Фираяның машинасы да бөтен гаилә сыярлык – зур.

Мин бу гаилә белән 1973 елда – Карадуган мәктәбенә татар теле, әдәбияты, тарих укытучысы булып эшкә кайткач танышып, җиде ел кызлары Чулпанның сыйныф җитәкчесе булдым. Мәдинә апа белән еш аралаша, киңәш-табыш итә идем. Хәер, ул чакта мәктәпнең гаилә кормаган җиде кызы, ике яшь килене аны «әниебез» дип йөрттек. «Нәсел-ыруын белмичә теләсә кемне гомер юлдашы итеп сайламагыз, күрәләтә бозык холыклы кешегә кияүгә бармагыз. Андыйларны туры юлга күндерү кыен. Артык үзсүзле булып, ирегезнең сезнеңчә генә булуына омтылмагыз, бер-берегезгә ярашып, юл куеп яшәгез. Идеаль ир дә, хатын да булмый. Сабыр булыгыз», – дип өйрәтә иде ул безне.

Мәдинә апа озак еллар Карадуган авыл Советының хатын-кызлар советын җитәкләде. Күп гаиләләрнең таркалмый калуында, тайгак юлга кереп киткәннәрне туры юлга күндерүдә аның өлеше искиткеч зур булды.

Ул – мәктәпнең драмтүгәрәк җитәкчесе һәм режиссеры, төп рольләрне уйнаучы артист. Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» әсәрендәге Миңлекамалны уйнавын әле дә сокланып сөйлиләр. Ул сәхнәдә үзен уйнады!

Милләт анасы, намаз карчыгы, 9 оныкның яраткан әбисе, гаилә терәге бүген дә замана проблемаларына, яшь буынның рухи-әхлакый тәрбиясенә битараф түгел. Республика вакытлы матбугатында аның тормыш мисаллары белән нигезләнгән, төрле проблемаларга үз фикерен белдергән язмалары еш басыла.

«Тәрбия гаиләдә гади генә мөнәсәбәтләрдән башлана. Бала иң элек исәнләшә, рәхмәт әйтә белсен! Боларны өйрәтергә акча да, көч-куәт тә кирәкми. Ата-ана үзе тәрбияле булып, шәхси үрнәк күрсәтмәсә, сүзе белән кылган гамәле капма-каршы булса, бала икейөзле булып үсә. Дәүләткә әхлакый тотнаклы шәхесләр кирәкми, күрәсең, кайсы каналны ачсаң да, үтерешсуеш; исерекләр, фахишәләр замана герое итеп тасвирлана. Кызларны чишендереп, матурлык конкурслары үткәрү – фахишәлекнең бер төре.

Борынгылар бала тәрбияләүне гаилә корудан башлаган. Замана чире – «ирекле мәхәббәт» акылны томалый, фикерне чуалта. Ул хатын-кызны таптау, кимсетү алымы. Элек әти-әни, һәр ике якны ныклап өйрәнеп, димләп кенә кавыштырганнар.

Кечкенәдән ир баланы әти – гаилә башлыгы, аны туендыручы; ә кыз баланы – әни, нәселне дәвам итүче, гаиләнең тәрбиячесе булырга әзерләү кирәк. Бала мөстәкыйльлеккә өйрәнсен, әмма аны күздән ычкындырырга ярамый. Ул безнең ярдәмнән башка яши алсын. Бала уенчык түгел – шәхес. Йөкле хатын матур уйлар, әйбәт теләкләр теләп, хәләл белән тукланып, изге гамәлләр кылып яшәгәндә генә иманлы балалар туа. Бала тәрбияләгәндә нәсел-ыруын искә төшереп: «Синең әбиең оста тегүче иде, бабаң гармунчы яки балта остасы, бик ярдәмчел иде, син әбиеңә яки бабаеңа охшаган», – дигән җөмләләр белән өлкәннәргә хөрмәт, үткәннәргә кызыксыну уятырга мөмкин», – ди Мәдинә апа.

Бакый ага үзе исән чакта гаиләсе белән туганлашкан һәр нәселнең шәҗәрәсен төзеп, килер буыннарга гаять кыйммәтле мирас калдырган.

...Менә шундый затлы нәселгә килен булып төшә Фирая. Авыл Советында сәркатип булып эшләгән әнисе Мөнзирә: «Безгә тыңлап туймаслык лекцияләр сөйләгән Бакый абыйлармы инде ул? Иш итәрләрме икән, бигрәк зыялы нәсел бит?» – дип шиген белдерә.

Фирая – һөнәрчеләре белән тирә-якта дан тоткан Смәел авылы кызы. Әтисе сирәк һәм кирәкле һөнәр (бу һөнәр бабасыннан ук килә) иясе – көймәче була. Элек Шушма ташыганда елга өстенә салынган күперләр агып китә һәм арьяктагылар зур дөньядан бүленеп кала иде. Дөнья булгач, төрле хәлләр була. Андый чакта ярдәмгә Муллазыя абый килә. Кайнап торган елгага, бозлар арасына кереп китә. Боз өстендә агып киткән авылдашын да коткарырга туры килә аңа. «Мин язгы суга карарга куркам, нинди тәвәккәл булган минем әти!» – ди Фирая яшьли бакыйлыкка күчкән әтисен сагынып. Тәвәккәллек, кыюлык кызга әтисеннән күчкән.

Булат белән Фирая иптәш кызының туенда танышалар. Пионервожатый булып эшләүче Фирая белән мәдәният хезмәткәре Ленар туйны искиткеч итеп алып бара! Өченче дистәне тутырган Булат бер минутка да кызны күздән югалтмый. Очрашуның унөченче көнендә кызга тәкъдим ясый, ике айдан никах укытып, туй итеп, Зыятдиновлар нигезенә килен төшерәләр.

Менә 16 ел инде килен белән кайнана бер-берсен аңлап, бер-берсенә ярашып – чөкердәшеп гомер кичерәләр. Нәсел-ыруны куандырып дүрт малай, бер кыз үсеп килә. Беренче көннән киленне куанып каршы алган Бакый абый гомере буе бөртекләп җыйган экспонатлары белән музейны килененә ышанып тапшыра. Ә килен яшьлек дәрте белән эшкә ныклап алына. Яңадан-яңа эш алымнары барлыкка килә. Музей кар-

шында оешкан өлкәннәрнең «Ясмин» фольклор ансамблен районнан еракларда да беләләр хәзер. Фирая тырышлыгы белән никадәр онытылган гореф-гадәтләр, традицияләр яшьләргә кайтарылды. Мәктәптә даими кунак «Ясмин». «Аулак өй күренеше», «Орчык бәйрәме», «Тула басу», «Бәби туе» фольклор композицияләре белән район конкурсларында да җиңү яулап, күрше авыл халкын да онытылган гореф-гадәтләр белән таныштырып, ял иттерәләр. Саллы гына җиңүләре дә бар. «Энҗеләрен барлый халкым» фольклор коллективларының район бәйгесе җиңүчесе. Республика ветераннар Советы һәм Татарстан мәдәният министрлыгы оештырган «Балкыш» фестивале лауреаты.

Фирая аларны спектакль, концертлар карарга Казанга еш алып бара. Бу көннәрдә ул әбиләр өчен дискотека оештыру хыялын тормышка ашыру белән мәшгуль. Фирая Зыятдинова «Нечкәбил» бәйгесенең республика турына үткәч, «Ясмин» ансамбле аны якларга барып, чыгыш ясап, җиңү яулашкан. «Нечкәбил» бәйгесенең җиңүчесе Фираяның борынгы рецепт белән оеткан катыгы һәм казысы дипломга лаек булган.

«Күз тидерделәр, аннан кайткач бер ел тәмле итеп катык оета алмадым», – ди ул. Пешерергә оста Фирая, борынгы мичне дә саклап калган. Шунда мич коймагы, балан бәлеше, ипи пешерә. Шул арада биш баласы, ире белән Мәскәүгә барып җиңү яулап кайтырга да өлгерә. «Күп балалы гаилә һәм кешелекнең киләчәге» дип аталган халыкара форум Мәскәүнең Кремль сараенда 2014 елда уза. Сәхнәдә чыгыш ясап, татарның борынгы йорт җиһазлары, кул эшләре һәм нәсел шәҗәрәләрен туплаган күргәзмә оештырган бердәнбер гаилә була ул. Күргәзмәдә бигрәк тә Фираяның бирнә сандыгына кызыгалар.

Яңа елда бөтен гаилә белән Республиканың төп чыршы бәйрәмендә катнашып, чыгыш ясаганнар. «Биш балага өч төрледән унбиш кием генә әзерләдем, – ди әни кеше. – Мондый бәйгеләр мәшәкатьле: биш баланы көйлисе, ирне күндерәсе, өйдәгеләрне тәртипләп калдырасы бар».

Аралашу вакытында шуңа игътибар иттем. Күп вакыйгаларга килен белән кайнана бертөрле бәя бирә. «Ни өчен тәртипсез балаларны тайгак юлга басканчы беркем дә күрми?» – дип борчыла алар.

«Килен булу берни түгел, кайнана булу авыр», – дигән бер кайнана. «Дүрт малайның әнисе буларак, биемеңнең нинди сыйфатларын үзеңдә тәрбияләргә омтыласың?» – дип сорыйм Фираядан.

– Сабырлык, – ди ул уйлап та тормыйча, – аннан балалар гаиләсенә тыгылмаска, киңәшләр белән алҗытмаска, үзләренчә яшәү мөмкинлеге бирергә кирәк. Безнең әни шулай итә.

Мәдинә апа килененең барлык хатын-кыз эшен белеп, улын хөрмәтләп, өлкәннәргә ихтирамлы булып яшәвенә куана. «Матур җанлы ул, чәчәкләр ярата, өйне ялт итеп тота», – дип мактый.

Әминә МӨХӘММӘТҖАНОВА.
Балтач районы.

«АК КАЛФАК» – ЫРЫНБУРДА

Алты яшеннән үк шәл бәйләргә өйрәнә монда хатын-кызлар. Монда булдыклылык сыйфатларын җуймаган ир-атлар яши. Татарлыгын саклап, тырышып яшәүче Татар Каргалысы... Оренбург истәлекләре бу. «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының чираттагы күчмә утырышы шунда узды.

Казан-Оренбург арасы – 730 километр. Ун сәгатьлек юл. Чит төбәк. Тик, Татар Каргалысы авылына аяк басуга, болар барысы да онытыла. Татарстандагы Саба районының бер авылына барып чыккандай буласың (Каргалыга нигез салучылар Байлар Сабасыннан килеп урнашкан да инде). Нәкъ безнеңчә сөйләшәләр! Гореф-гадәтләре дә бездәгечә. Кунак алдына табынга куя торган бәлешләре генә бераз башкача – эченә мул итеп дөге белән ит салынган. Мактана торган тагын бер сыйлары бар – тәңкә токмачлы аш.


Кайчандыр Каргалыда 11 мәчеттән азан ишетелгән, бүген өчесе сафта. Авыл агайлары бирeдә 13 меңләп кеше яшәгәнлеген хәтерли. Хәзер 4 меңгә якын кеше яши, диделәр. Борынгы зиратларын карап-саклап тоталар. Андагы кабер ташлары һаман өйрәнелеп бетмәгән әле. Яши авыл. Яңа йортлар төзелеп тора, мәктәп эшли, яшьләр үз эшләрен булдыра. Татарстанга йөз тотып, үз тырышлыгы белән татар телен саклап яши Каргалы.

Оренбургның үзендә дә татар эзләре исән. «Ак калфак» утырышы да Мирхәйдәр Фәйзи исемендәге Татар дәүләт драма театры бинасында узды. Залны тутырып Оренбургның төрле район һәм авылларыннан татар хатын-кызлары җыелган. Күрше Казакъстаннан да кунаклар килгән, Башкортстан, Пенза, Пермь һәм әлбәттә, Татарстаннан да делегатлар бар. Шулай залны тутырып утырган туташ һәм ханымнар каршысына чыгып, «Ак калфак» оешмасы рәисе Кадрия Идрисова... ир-атларны мактый. Мактамаслыкмыни?! «Татар Каргалысында чабулап йөргән берәр хатын-кызны күрдегезме? Юк, чөнки җирлек башлыгы һәм өч депутат ир барысына да үзләре йөгерде, бөтен эшне үзләре оештырды. Меценатлык Каргалыда һаман да дәвам итә. Мондагы ирләр милли йөзләрен саклап калган», – Кадрия Рәис кызының бу сүзләрен зал алкышларга күмә.

Күчмә утырышның төп максаты – тәҗрибә уртаклашу. Казакъстаннарга Актаныш тәҗрибәсе кызык, Мамадыш Пенза үрнәге белән таныша. Милләтне, телне саклау турында уйлана «ак калфаклылар».

Утырыш азагында «Сөембикә» дә сәхнәгә күтәрелде. Җирле «Ак калфак» оешмасының җитәкчесе, «Оренбург шәлчеләре» предприятиесенең башында торучы Альбина Әбсәләмовага «Сөембикә беләзеге»н тапшыру өчен! Милләт файдасына эшли торган ханымнарга гына бирелә бу затлы бүләк.

Фәнзилә МОСТАФИНА


Утырышның фоторепортажын сайтыбыздан карый аласыз.



PRESSA.RU



«ТАНУ – АЛЛАНЫ, БЕЛҮ – ДӨНЬЯНЫ...»

(Нәбирә ГЫЙМАТДИНОВА белән Ркаил ЗӘЙДУЛЛА әңгәмәсе)

ҺӘРБЕРЕБЕЗ КОДРӘТ ИЯСЕНЕҢ КҮЗӘТҮЕ АСТЫНДА ТЕРЕКЛЕК ИТӘБЕЗ. БЕЗ ЗУР СЫНАУДА. НИНДИ ГАМӘЛЛӘР КЫЛАБЫЗ, НИЛӘР УЙЛЫЙБЫЗ (НИЛӘР ЯЗАБЫЗ!) – ЯХШЫСЫН ДА, ЯМАНЫН ДА ФӘРЕШТӘЛӘР ТЕРКӘП БАРА.

■ **Үз-үзеңне яратасыңмы?**
Юк, үземне гел тиргәп торам.
■ **Нидән куркасың?**
Ялгызлыктан.
■ **Тетрәнүләрне ничек кичерәсең?**
Авыр. Бер-бер артлы диярлек абый белән әни бакыйлыкка күчкәч, әле дә җаныма урын табалмыйм.
■ **Күңел төшенкелеге белән ничек көрәшәсең?**
Көрәшмим. Чөнки аңа бернинди чара да юк. Үз вакыты белән үтә ул.
Ни ул бәхет?
Минем өчен – саулык.
■ **Кешедәге нинди сыйфатларны аерата хөрмәт итәсең?**
Ихласлык, тугрылык.
■ **Ә кайсыларын күралмыйсың?**
Ялганчыларны, вәгъдәсендә тормаучыларны, ике-йөзлеләрне һәм мактанчыкларны җенем сөйми.
■ **Еш алдашасыңмы?**
Бик еш. «Хәлең ничек?» – дип сорасалар, бик кыен хәлләрдә булсам да, сер бирмим. «Әйбәт, Аллага шөкер», – дип алдыйм.
■ **Яратуны тамчы белән үлчәп буламы?**
Әңгәмә барышында син минем бер генә әсәремне дә атамаган идең, хәзер, мөгаен, «Бер тамчы ярату» бәянын күздә тотасыңдыр. Ярата белгән кеше тамчының хикмәтен белә инде ул.
■ **Әдәби әсәр язар өчен күңел газаплары кичерү мәҗбүриме?**
Юк, тормыш ваклыкларыннан гына арынырга кирәк.
■ **Ике йөз елдан соң фани дөньяга кайтсаң, беренче очраган кешегә ни дип эндәшер идең? Ул сине аңлармы?**
Саумы, туганым, дияр идем. Минем берәр әсәремне укыдыңмы дияр идем. Аңлар, чөнки ул татар кешесе булыр!
■ **Мәрхүм Рөстәм Мингалим әйтмешли, яхшы кеше син, Нәбирә!**

Нәбирә, иң әүвәл сине гомер бәйрәмең белән котлыйм әле. Аллаһы Тәгалә сиңа саулык-сәламәтлек бирсен. Һәм, әлбәттә, алдагы көннәрдә дә тел ачкычларын югалтма. Быел синең өчен истәлекле ел булды – Татарстанның халык язучысы дигән исем алдың, бик затлы китабың дөнья күрде. Олы кайгы да кичердең – әниең бакыйлыкка күчте. Бу җәһәттән мәңгелек сорауны бирәсем килә: яшәү мәгънәсе синең өчен нидә? Адәм баласы ни өчен яши җирдә?
– Моннан өч мең ел элек үк Сөләйман патша тормышны нәрсә мәгънәле итә дигән сорауга җавап эзләгән, ләкин табалмаган. Минем өчен яшәү мәгънәсе ике сүздән генә гыйбарәт: танып белү. Тану – Алланы, белү – дөньяны. Ягъни тәҗрибә туплау, гыйлем эстәү, үзем якын күргән кешеләр белән аралашу, әхлак чиген узмаган әсәрләр язу, соклану, ярату, әдәпле балалар үстерү һәм башкалар... Алар бихисап. Бу җирдә ни өчен яшим дип уйлаганым юк, димәк, Күк идарәчесе шулай карар кылган. Мин бит тугач та берничә айдан үләм. Әни күрше Газизә әбигә йөгереп керә. Карчык бишектә яткан нарасыйга – миңа ясин чыга. Укып бетергәч, битемә ак яулык ябалар. Миңа кадәр инде бер яшьлек апам Нәбирәне җирләгән булалар. Ул – өченче, ә мин бишенче бала. Ходайның рәхмәте, ярты сәгатьтән тәнем җылына, күземне ачам. Газизә әби миңа гел: «Балам, фәрештәләр сиңа яңадан җан өрде», – дип әйтә иде. Минем әби Нәгыймә исемле бик дини карчык иде, гел актан киенде, биш вакыт намазын калдырмады. «Һәрберебез Аллаһыга кайтарылыр өчен яшибез, оланнар. Гомеребез очланганда һәркайсыбыз Мигъраҗ сәфәренә кузгалырбыз», – дигән сүзләрен әле дә хәтерлим. Еш кабатлый иде. Ә мәгънәсен олыгая-олыгая гына аңлыйбыз шул.

Халык язучысы... Халык шагыйре... Әлбәттә, беренче карашка, горур яңгырый. Совет власте еллары искә төшеп күздән яшьләр дә килә. Бу бәяләмәдә күпмедер нафталин исе дә бар, дию-ем. Әдәби әсәр укучылар кимегәндә, әдәбият иҗтимагый ролен тәмам җуеп килгәндә, әлеге титул ничектер абсурд тоела. Шунысын да онытмыйк: урта гасырларда, мәсәлән, шәрык шагыйрьләрен бәяләгәндә, аларны «халыкныкы» дип түгел, ә «шагыйрьләр шагыйре» дип атаганнар. Ул шагыйрьләр дә сокланырлык шигырьләр язган! «Халык» төшенчәсен син ничек аңлыйсың?
– Безнең кайбер татар әдипләрендә, шул исәптән синдә дә, каләмдәшләргә карата нindидер ирония сизелә. «Нигә сиңа, нигә миңа түгел?» дигән көнчелек корты күбесенең җанын кимерә. Чир инде бу... Халык җырчысы, халык артисты, халык рәссамы бар, ә нигә халык язучысы булмаска тиеш, ди?

Әдип белән артистны чагыштыру, минемчә, бик үк урынлы түгел...
– Булсын, без кемнән ким? Уйлама, әлеге бәяләмәне мин көрәшеп, элемтәләр урнаштырып алмадым. Мактануым түгел, факт буларак кына әйтеп китүем, бүген мин 21 китап авторы (аз, билгеле). Барысы да 6–10 мең тирәсе тираж белән басылып, тиз арада сатылып бетеп барды. Бер генә түрәгә дә: «Китапларым складта ята, алыгыз әле!» – дип ялынып бармадым. Халык яратып, эзләп укыды. Безнең тормышыбыз, яшәешебез нindидер бер закончалыкка буйсына. Адәм баласының ашар ризыгы, эчәр суы, сулар һавасы җан яралганда ук билгеләнгән кебек, аның һәр адымы да алдан ук исәпләнелә. Шулай ук шөгыле, ирешәсе биеклеге, тәгәрисе түбәнлеге... Төрле исемнәр, бүләкләр дә, мөгаен, адәм затына алдан ук тәгаенләнәдер. Җәнабе Аллаһ насыйп итсә – ризык та теш ертып керә. «Адәм баласының вазыйфасы – тырышу, әмма нәтиҗәсе Аллаһыдан» диелгән хәдисләрдә. Сахих әл-Бохари болай ди: «Кешеләр кыла торган гамәлләрнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан игътибарга алынулары, дәрәҗә һәм

PRESSA.RU

мәртәбәләре аларның ниятләренә күрәдер, һәр кешенең үз гамәле бәрабәренә булган өлеше нияткә карап була». Әйе, Шәрык шагыйрьләре Шайяд Хәмзә, Сүли Фәкыйр, Дүрбәк, Мөхәммәд, Сөләйман Чәләбиләр һәм башкаларны үз заманында «шагыйрьләр шагыйре» дип аталганнар, без дә алар кебек бу дәрәҗәгә ирешкән Тукай, Хәсән Туфан, Такташ, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәтләр булганын онытмыйк.

Бабам мәрхүм «кара халык – кара сарык» дип әйтә торган иде. Бу аның сүзе түгел, бу үзе үк халык мәкале. Ә тагын бер халык мәкале раслаганча, «халык әйтсә, хак әйтә...» Тарихтан беләбез, иң кабахәт эшләрне дә халык исеменнән башкарганнар. Халык үзе зур язучысына лаекмы ул?

– «Кара сарык»лы мәкальне ишеткәнем юк. Кара халык, диләр. Анда да аның наданлыгына һәм томаналыгына ишарәләп. Син тарихны яхшы беләсең, төрле чуалышларны, түнтәрелешләрне, баш күтәрүләрне уптым халык башламаган, арада берничә фетнәче булган. Аны лидер дисәк тә ярыйдыр.

Халыкның сабыры сынмаса, аны бер фетнәче дә үз артыннан ияртә алмыйдыр...

– Бер гыйбрәтле мәзәк искә төште. Ресторанда кысла сорый клиент. Тәлинкәсе белән моның алдына китереп куялар. Кыслаларның бөтенесе дә селкенә. Клиент официантны чакыра: «Ник болар тере, ник пешермәдегез?» – ди. Теге әйтә: «Аста берсе тере, шул барысын да селкетә», – ди. Октябрь инкыйлабын гына ал: аны бер төркем фетнәче оештырган түгелмени? Шул син әйткән «кара сарыклар» исә бер файда китермәгән. Байларның, алпавытларның йорт-җирен яндырган, җимергән, талаган – шул гына. Әмма тулаем халыкны гаепләргә кирәк микән? Инсанны үз артыннан ияртер өчен бүген көчле әйдаманнар юк. Әлегә нинди халык бар – каләм белән шуңа хезмәт итәргә туры килә.

Борынгы төрки шагыйрьләрнең иң бөекләреннән булган Алишер Нәваине, мәсәлән, шаһ-и-гарибан, ягъни «гарип-горабалар, моңлылар шаһы» дип атаганнар. Ул бик күп хәйрия вакыфлары оештырган, ятимнәр өчен йортлар салдырган. Хәер, вәзир буларак, аның моңа мөмкинлеге дә булган. Мөмкинлеге булганнар тарихта күп, әмма шундый игелекле эшләре белән шагыйрь Алишер гына халык хәтерендә (шулай ук шартлы төшенчә; халыкның хәтере кыска икәнен беләбез) калган. Иҗат һәм мөлкәт... Шул хакта иркенләбрәк сөйләшик әле...

– Син мине ерак гасырларга алып киттең әле, Ркаил. Нәваиның газәлләрен, робагыйларын, аның «Ләйлә вә Мәҗнүн», Низаминың «Фәрхад һәм Ширин» поэмаларын заманында елый-елый укыдык. Хөрәсән дәүләте әмире, әгәр кулында казна акчасы булмаса, Мәһдиев әйтмешли, «едва ли» китапханәләр, мәктәпләр төзетер иде. Бина торгызу әле ул халыкның бәгыренә үтеп керү дигән сүз түгел. Таш өеме бүген бар, иртәгә юк. Аннары, Нәваи, безнең Тукайлар һәм бүтән шагыйрь-язучылар кебек, дәүләт, милләт, тел, мәгариф дип сызланмаган, ул беренче чиратта мәхәббәткә дан җырлаган. Шуңа күрә аның әсәрләре халык хәтерендә саклана да инде. Элегрәк, яшьрәк чакта, иҗат итү – иң зур бәхет сыман тоела иде. Мин университет тәмамлагач, ВЛКСМ Өлкә комитетында пропаганда бүлегендә эшләдем. Сайлау мөмкинлеге бар: йә яңа гына ачылган «Идел» журналына китәм, йә Өлкә комитетына инструктор вазыйфасына алалар. Язам дип, журналга бардым. Тагын бер очрак: илдә базар мөнәсәбәтләре башланды, алыпсатарлар пәйда булды. Сүриядән, Польшадан, Кытайдан тауар ташыйлар. Танышым миңа да тәкъдим ясады: әйдә, үз эшебезне ачабыз! Тагын сайлау: йә иҗат, йә акча. Язам, дидем. Танышым бүген өч коттеджда яши, дүрт кибет тота, ел саен чит илдә ял итә, ә мин «иҗат» учагында күшеккән кулымны җылытам. Күрәсең, иҗат белән мөлкәт бер казанга сыймыйдыр.

Соңгы елларда татар язучыларының олысы да, кечесе дә матди яктан зарлана. Һәм иң гыйбрәтлесе: хәллерәкләре ныграк та лаф ора. Узган корылтайда да, минемчә, иҗат хакында сөйләшүдән бигрәк, ярлылыктан, каләм хакының азлыгыннан зарланып сөйләүләр өстенлек алды. Ләкин без шуны онытабыз, каләм хакы белән тамак туйдыру күпчелек язучы өчен бер илдә дә мөмкин түгел, андыйлар кайда да берән-сәрән генә. Кайберәүләр совет вакытын сагынып искә төшерсә дә, ул чакта да язучылар бай яшәде дип әйтә алмыйм. Ил белән бергә идек. Шуңа күңел тыныч булгандыр. Хәзер бит байлар белән ярлылар арасындагы упкын көннән-көн тирәнәя бара.

– Каләм хакы дисең син, каләм хакы... Нишләп без шушы хакта туктаусыз лаф орабыз икән? Әнә артист җырлый – акчасын ала, кино артисты уйный – гонорарын ала, бары тик язучы хезмәтенә кагылганда гына бәхәс куба. Ул корылтайлар, җыелышлар СССР вакытыннан калган искелек ләбаса! Бездә иҗат турында, гомумән, сөйләшеп булмый! Син, каләм хакы белән тамак туйдыру күпчелек язучы өчен бер илдә дә мөмкин түгел, дисең. Җир шарының кайсы төбәгендә һәркайсы үзен талантлы санаган 350 язучы бар соң? Чит илдә, кереме булмаса, беркем дә язучылык эшенә керешми. Алар бездән акыллырак. Эрвин Кобб: «Әгәр язучы әйбәт эшмәкәр булса, аның язмаска акылы җитәр иде», – ди. Әйтик, «Унесенные ветром»ның авторы Маргарет Митчеллга гонорар суммасын үзенә язып куярга тәкъдим итәләр, ә мәшһүр әсәре өчен аңа 130 миллион доллар түләнә. Стивен Кингның байлыгы 400 миллион доллар белән исәпләнә. Ә менә Гарри Поттерның «анасы» Джоан Роллинг бер китабы өчен генә дә 107 миллион доллар акча алган. Аңа Рәсәй нәшрияты тәрҗемә китабы өчен 100 мең доллар түләгән. Антуан де Сент-Экзюпериның «Нәни принц» исемле юп-юка китабы 140 миллион доллар табыш

китерә. Чит ил язучысын журнал-газета түгел, хосусый нәшриятлар туйдыра. Тикмәгә генә Рәсәйдә Б. Акунин, Л. Улицкая, Э. Лимонов, Э. Радзинскийлар гонорар хисабына бай гына яшәп ятмый инде. Миңа кайчакта: «Сез, татар язучылары, дөнья күләмендә танылыр өчен глобаль проблема күтәрегез!» – дип акыл өйрәтәләр. Бик тә күтәрер идең, бик тә космополитка әйләнер идең, без шул һаман сызлаган җиребезне уабыз. Без татарның үз дәүләте юк, тел һәм әхлак бишеге саналган авыл бетә, катнаш никахлар арткан саен, милләтнең саны кими, маңкортлар үрчи. Татар язучысы, әлбәттә, әрнеп-сыкранып шуларны кәгазьгә төшерә. Урыс туганыбызны яисә океан артындагыларны мондый хәлләр тетрәндерә дисеңмени? Гафу ит, әзрәк читкәрәк каердым шикелле. Әз-мәз зарлану килешер ул, Ркаил, тик мескенлеккә төшмәскә кирәк.

Әгәр дә берәр татар миллиардеры, минем турында китап яз, дип миллион сум акча тәкъдим итсә, бу эшкә керешер идеңме?

– Ә ник ризалашмаска, ди! Адәм баласы йә ак, йә кара балчыктан гына әвәләнмәгән. Бик явыз, әшәке кешедә дә әз-әз миһербанлылык чаткысы булырга мөмкин. Әни мәрхүмә сәнгатьне бик ярата, күп укый, телевизордан спектакльләр карый, Казанга килсә – театрларга бара иде. Ул безгә балачакта бик матур әкиятриваятьләр сөйли иде. Бер кансыз патша булган, имеш. Халкына рәхәт күрсәтмәгән бу, юк гаепләрен табып, аскан-кискән, тапаган-тураклаган. Кыскасы, явызлыгы белән дан тоткан. Төнлә, йоклаганда монын маңгаена нәрсәдер орынган, ди. Кайсы каһәрегез мине тәмле йокыдан уятты дип, сикереп торса, алдында пыр-пыр күбәләк оча икән. И-и җанкаем, чыгарга юл табалмыйсыңмы дип, патша моны учына кундырган да, тәрәзәне ачып очыртып җибәргән.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булганнан соң, күпләр үзләрен рәсми язучы дип саный башлый. Юка гына берничә җыентык чыгарган (спонсор табып!), берничә тапкыр халык алдында чыгыш ясаган, ул инде әлләкем! Бераздан ул үзен бәяләнмәгән дип саный башлый, гаделсезлектән зарлана, күзендә нәфрәт, коточкыч көнчелек... Үзе кебекләр белән берләшеп, премияләр яуларга ыргыла. Бүгенге әдәби процессны мин шулайрак күз алдына китерәм. Ә газета-журналларда нәшер итәрлек хикәя табып булмый. Бездә шигърият югары кимәлдә, дип шапырынырга ярата идек. Ләкин журналларны җентекләбрәк укысаң, төшенәсең: без ул кимәлне дә инде җуйганбыз. Нәрсә көтә безне, Нәбирә? Татар әдәбиятының киләчәге шулай ук аянычлы дип уйлыйсыңмы?

– Әдәбиятыбызның меңьеллык тарихы бар, дибез. Энҗе бик кыйммәт әйбер, ул – табигать байлыгы. Тик аны Аллаһы Тәгалә океан өстенә сипмәгән, төпкә яшергән. Газап чигеп табыгыз, дигәндер. Талант иясе дә энҗегә тиң. Ел саен Тукайлар, Такташлар, Туфаннар тумый. Шагыйрьләрне белмим, ә менә проза өлкәсендә бүген чын-чынлап татар әдәбиятын күтәрерлек 30-35 прозаик санадым. Яше-карты белән. Шуларны тормыш вак-төякләреннән арындырып, матди яктан булышып, дөнья буйлап сәяхәт иттереп, рухи байлык өстәтеп яздыртасы гына югыйсә! Яздырт та, тәрҗемә иттер. Безнекеләр дә танылыр. «Кара алтын»ы белән шаулаган бай Татарстан ла без. Хыял, әйеме?

Хыялланырга безгә куш. 30-35 дөньякүләм әсәр язарлык язучы булу... Моңа ничек шатланмыйсың! Мин үзем алай ук оптимист түгел. Милли әдәбиятны гасырлар дәвамында барлыкка китерәләр, ә юк итәр өчен берничә дистә ел җитә. Ләкин әдәби иҗат ул үзе бик сакраль нәрсә. Аның дәрте кайбер кешеләрнең канына салынган. Ул дәрт бар икән, кеше нинди генә шартларда, нинди генә телдә булсын, барыбер язачак. Зөлфәт Хәким бер телевизион әңгәмәдә, әдәби иҗат ул иблис белән шартнамәнең нәтиҗәсе, дип, кемнеңдер фикерен кабатлаган иде.

– Бу хакта үзем дә уйланам. Йа Ходаем, зиһенем буталып, каләмем ялгыш юлдан кереп китмәсен дип телим. Бозыклыктан сакла, дим. Бездә бит хәзер оятсыз әйберләр сырлаган авторлар күбәйде. Бигрәк тә хатын-кызлар. Аларның әнисе, ул-кызлары укымый микәнни?! Фахишәлек, азгынлык, уйнаш турында ничек татар хатыны тәмләп, җентекләп яза икән дип шаккатасың. Иблис нәкъ шундый пычрак нәрсәләр яздырта, күрәсең.

Мин бүген һич рияланмыйча әйтә алам: бүгенге татар әдәбияты хатын-кызлар кулында! Сурәтлерәк тә әйтеп була: татар әдәбияты бүген хатын-кызларның бармагы арасында... Андый әдәбият дөньякүләм зур була аламы?

– Мин әдәбиятны җенесләргә бүлмим. Ир-атмы, хатын-кызмы – аның исеме бер генә: язучы!

Әйе, Аллага шөкер, бездә мужской, женский родлар юк.

– Сине шомландырган бу хәл иҗатта гына күзәтелми, Ркаил. Бүген җәмгыятькә тулаем хатын-кыз хуҗа! Әгәр аларны өйдә генә утырыгыз дип, куып кайтарсаң, уку йортлары, оешмалар-предприятиеләр ишегенә йозак эленер иде. Әдәби иҗатка килгәндә исә, хикмәт язу куәсендә. Жорж Санд, Габриэла Мистраль, Маргарет Митчелл, Агата Кристилар мәгәр татар илендә яшәп кысылса-кыйналса, нужа чиксә, дөнья күләмендә танылыр иде микән? Монысы шәхси фикерем. Эт чаба дип бет чаба дигәндәй, Фәлән яза бит әле, ник миңа да язмаска дип, спонсорлар эзләп (әрсезләргә акчасын да бирәләр) китаплар бастырып, халык белән очрашуларда үзен язучы дип игълан итеп йөрүче ханымнар күбәеп китте шул. Әдәбият бакчасын чүп басты. Монда сез, татар ир-егет язучылар, үзегез дә гаепле. Син үзең дә бер ханымга, инсценировка диеп, өр-яңа пьеса язып бирдең бит әле. Димәк, әсәрнең сәхнәгә күтәрелерлек рәте юк!

PRESSA.RU

Марсель ГАЛИЕВ шигырьләре... Алар әллә ничекләр итеп җанны актара, рәхәт бер халәттә тибрәтә. Күз алдында төсләр, матур сурәт-картина. Хисләр бии... Аның теле, стиле, аһәңнәре үзенә бертөрле, беркемнекенә охшамаган: затлы, нәзберек, нәфис. Шагыйрьлек җене, хыялый алдану бәхете... Иҗатына бәяләмәне дә шагыйрьнең үз сүзләре белән кабатлыйсы килә.
«Сүз өзелә күңел тәлгәшеннән...»
«Шигырь – мәңгелек упкынында тирбәлгән күңел бишеге...»
«Шагыйрь – Күк белән Җир арадашчысы!»
Болар Марсель Галиев фикерләре. Сүзләре, шигыре күңел тәлгәшеннән өзелгән!



Марсель
ГАЛИЕВ

ҖИРДӘ БӨЕК ЮАНЫЧ БАР...

Күрше кызы

Күзәттем ни, сүз әйттем ни –
үземнең үз күңел эшем:
Чытлыкланып, кәз-кәз басып,
назлыкайның күр йөрешен:
Җилфер керләр эләргә дип
нәзакәтле үрелешен;
Күз карашын тәкатьсезләп
сыгылма бил бөгелешен.

Нинди гадел чишкән Ходай
җете төсләр бүленешен:
Җир кызына өстәп биргән
ягымлы нур – Күк өлешен.
Бар барлыгы әйтеп тора
хисләренең түгелешен.

Күр әле син: үлән-чыкта
эзләренең чигелешен.
Ә егетнең койма аша
үрелеп бер үбелешен.
Бу мизгелдә йөрәгендә
тылсымлы сүз тибелешен
Белми әле: мәхәббәтнең
мең үлеп, мең терелешен;
Назлыкайның, куллар болгап,
томаннарга күмелешен...

Бирмә, Ходай, мәхәббәттән
күңел дәрте сүрелешен.
Ул хәзергә белмәсен дә:
җиңәм, диеп, җиңелешен.

Күзәттем дә, сүз әйттем дә,
Миңа нәрсә, күңел эшем:
Кайтар, Вакыт, назлыкайның,
Ыспай басып, бер йөрешен.
Тик бер генә кабатлачы
Шушы җәннәт күренешен.

Ак яулыклы сабырлык

Ничек соң, мин яшь шаһзадә булып
Килә алмадем сиңа ак атта?
Рәшит ӘХМӘТҖАН

Нинди сөлгеләр элгәнсең
Гомер кашагасына.
Нинди мендәрләр тезгәнсең
Тәкъдиреӊ ягасына.

Нинди догалар белгәнсең
Иблис өнсез калырлык...
Түзгән – иелмәс җаныңда
Ак яулыклы сабырлык.

Андый сабырлык төбендә
Сулкылдар сары алтын.
Нинди бизмәннәргә салып,
Кем үлчәп, аклар хакын?!

...Хыялың – офык артында
Калган буразналарда.
Шул буразна үремнәре –
Киселгән толымнарда.

Томылып чаба, томылып,
Яшьлекнең чаптар аты.
Шунда бит, шунда ялгышның
Борылып кергән чаты...

Күңдәмлеккә күнә барып,
Язмышың читлегендә
Нинди ярсулы назларның
Җене җуелган синдә.

Ак атлы яшь шаһзадәнең
Килерен көткәнсеңдер.
Чәмчәле читек чигешен
Төшләрдә үпкәнсеңдер.

...Ачыла хәтер, ябыла...
Нинди җил килеп кагыла
Капкаңның келәсенә;
Нинди бу – бөек ышаныч
Сөенеч киләсенә:
Ак атта, җилле җайдакның
Тупырдап керәсенә!

Яңабаштан, бер айкалып,
Сөлгеләр эләсең дә...

Яңабаштан, сөеп-сыйпап,
Мендәрләр тезәсең дә...
Нинди бу – рәхмәтле әрнү
Мәхәббәт сүрәсендә?!

Куш мендәрең нәүмиз ята
Күңелең Кәгъбәсендә...

Юаныч
Мең яшә. Гасырларны кич,
Мең рәхәт чик, мең михнәт.
Җирдә бөек юаныч бар:
Бәллүр билле мәхәббәт!

Соклану
(Акварель)
Юашланды Идел дулкыннары,
Су чәчрәтеп миңа
Комлы ярга син йөгереп чыктың.

Манма чәчләреңнән,
Ала-алма күкрәгеңнән,
Тыгыз, көрәнсу тәнеңнән
Йөгерешә ләйсән тамчылар.

Кояш нуры һәм тамчылар
Кушылды да бергә –
Син – салават күпере!
Якын килсәм, ераклашырсың да...
Дәшсәм, капылт сүнәрсең дә...
– Син – салават күпере!

Адашып син, гомерлеккә шулай
Яшьлегеңдә генә калчы!

Сокланудан
Иделемне күмде
керфектәге тамчы.

Күз һәм без
Йөгер әле каен арасыннан,
Ак шәүләсе төшсен йөзеңә.
Яфраклары, сары күбәләктәй,
Кунсын әле, кунсын иңеңә.

Яфракларны ерып кил әле син,
Алтын тынлык дәррәү уянсын.
Тойыйк әле җирдә барлыкны бер,
Көнләштерик урман дөньясын.

Укы мине каен яктысында...
Сары шәмнәр тезгән табигать.
Яшьлегенә кайтсын каеннар да,
Иң кадерле сүзне табып әйт.

Чатыр тау
Ерактан ул – зәңгәр пирамида,
чал Уралның соңгы дулкыны.
Иңнәренә ятып оеп кала
төньяк җилләренең салкыны.

Җил йомгагы булып кылганнары
үзәннәргә таба йөгерә.
Кайнап аккан ак болытлар аша
тау кояшка гүя үрелә.

Ә төннәрен чума офыкларга,
син ерактан карап тор гына;
Алма кебек өзелә дә күктән
тауга йолдыз тама тын гына.

Куакларда әле төн кунаклый,
тау башында инде яңа таң.
Саумы, диеп дәшәм еллар аша,
күңелдәге сынын яңартам.

Якынлашкан саен ерагая,
төшләреңдә күпме чакырма;
Мин ачмаган гаҗәп әкият калган
мәгарәле зәңгәр Чатырда!

Бер көнлек гомер
Йолдыз нурлары калтырый
Иртәнге көмеш чыкта.
Өянкеләр башын ия
Күке кычкырган чакта.

Күке кычкырган чагында
Нигә соң дөнья моңлы?
Затлы тавышын көйләгән
Сандугач хәтта тынды.

Ә син санама гомерең,
Туган як моңын тыңла.
Тыңла да җаныңа сеңдер,
Мәгънәсен сүзсез аңла.

Купшы залларга китереп
Күкене тыңлап кара –
Өянке, инеш, болыннар
Бар моңын алып кала.

Туган җир моңы. Елларны
Сынама. Тыңлап кара.
....

Беркөнлек озын гомерле
Күбәләк очып бара...

Кайту
Йолдызларны коеп, төнге күкне
Сискәндереп өрә этләре.
Пароленне сорый алар, гүя:
Ятмы, үзме? Син соң кем әле?

Морҗалардан савылып күксел төтен
Чиксезлеккә тикле үрелгән.
Ә бер очы яңа яраладыр
Табадагы коймак йөзеннән.

Буран чыкса, көрт басар дип, әнкәй
Капкасын да ачык калдырган.
«Китмәскә дип кайтыр бу юлы», дип
Сөйләнгәндер ятар алдыннан.

Кайтып киләм. Хәтеремә төшә
Җырлап үткән чаклар урамнан.
Кем сүз әйтсен! Авыл үз көенә
Турылыклы борын-борыннан.

Бу якларның керләнмәгән кары,
Исе дә юк салкын буранның.
Ә бит нидер искәртәсем килә
Шау уятып бөтен урамны!

...Аяк тавышына әни чыга,
Йокламыйча көтеп торгандай.
Моңсу күзләрендә мөлдерәп тора
Сары сагыш кебек тулган ай.

Әбиләр чуагы
Бу – әбиләр чуагы бу!
Чатнап яна пәрәвезләр,
Күктә – кошлар көтүе.
Әҗәткә көн алып көздән
Җәйнең бәйрәм итүе.

Бу – әбиләр чуагы бу!
Сары балкыш кая? Уйный
Яшел төсләр тилереп.
Тик күлмәкчән чыккан бабай
Керде салкын тидереп.

Бу – әбиләр чуагы бу!
Очып арган күбәләкләр
Канат какты җанланып.
Борылып җәйгә карадыңмы,
Кадрен белеп, таң калып?

Бу – әбиләр чуагы бу!
Беркатлы карт алмагач та
Ышанып чәчәк атты.
Җәнлек сыман посып кына
Бусагага көз атты.

Бу – әбиләр чуагы бу...

PRESSA.RU



Рафига УСМАНОВА

КУНАК АПА

(Хикәя)

Биш катлы таныш йорт янына килеп җиткәч, Мәдинәнең аяклары хәлсезләнеп, кинәт туктап калды.

«Керәсең! Кермисең!» – дип, ике капма-каршы көч тарткалашты җанында.

Менә ничәнче тапкыр, кеше үтә алмаслык ниндидер киртәгә очрагандай, шул көчләрнең «Кермисең!» дигәненә буйсынып, бүтән монда аяк басмаска ант итеп, елый-елый кире кайтып китә ул. Ә бүген, ниһаять, бернигә карамый керергә, баласына әнисенең сумкасын тапшырырга дигән ныклы карарга килде Мәдинә.

Чыннан да, нигә кыенсынырга тиеш соң әле ул? Аның нинди гаебе бар?

Шундый уй белән йорт подъездына таба ышанычлы бер адым ясады. Тагын туктап калды. Хәлсезләнеп, шунда йорт янындагы утыргычка утырды. Күз алдына (менә ничәнче тапкыр инде!) моннан нәкъ ярты ел элек булган күренеш килеп басты.

...Ике генә көнгә командировкага киткән ире, атна үтүгә карамастан, һаман кайтмагач, шәһәр читендәге гаражлары базыннан бәрәңге алырга барган иде ул. Гараж ишеген ачып җибәрүгә, машина эчендә хәрәкәтсез яткан анадан тума шәрә ике кешене күреп һушсыз калды. Мәетләр икесе дә кара җир төсендә иде. Әмма Мәдинә берсен шундук таныды: газиз ире Рафыйк! Ә икенчесе? Йә Аллам, икенчесе – яшь кенә бер хатын лабаса. Тәүбә! Тәңрем, нинди хурлык бу?! Мәдинәнең иң беренче уе кешеләр чакырып кычкыру булса, икенчесе – бу хурлыктан гаражны бикләп ут төртеп котылу иде. «Машинасы-ние белән! Төтенләп янсын, эзе дә калмасын!»

Ял көне иде шул. Күрше гаражларда кешеләр күренә башлады. Мәдинә томаланып барган аңы белән бу мәсхәрәне яшереп булмасын аңлады. Йөрәгендә бер авыр чәнчү тойды, һушын җуеп, яшен суккан агач кебек капка төбенә авып төште. Егылганда: «Ярый әле, улым күрми. Ярый әле ул армиядә», дигән уй аңыннан йөгереп узды.

Узып барган кешеләр күреп, Мәдинәне шифаханәгә озаттылар, гаражга милиция чакырттылар. Мәдинә әле бик хәлсез булса да, ялынып, ялварып, икенче көнне үк хастаханәдән чыкты. Ни генә булмасын, ирен кешечә итеп җирләргә тиеш ул!

Рафыйк белән аның сөяркәсен: «Ярыйсы гына эчкәннәр, исерек килеш, уйнаш вакытында машина газына тончыгып үлгәннәр», – диделәр.

Эче тулы ут һәм ялкын булса да, Мәдинә Рафыйкка ачы каргышларын яудырмады. Бик авыр иде аңа. Әмма мөселман хатын-кызларына хас сабырлык белән, тешен кысып булса да, түзде. Ирен, бөтен йолаларын китереп, хөрмәтләп җирләделәр. Ләкин күңеле шулкадәр каткан иде,



Рәсем: Наталья Васильева

бер генә бөртек күз яшен дә чыгара, тамчы да елый алмады ул. Якыннарыннан әтисен җирләргә кайткан улы Ринатка Рафыйкны йөрәк чиреннән үлде, дип әйтүләрен үтенде. Улында әтисенә карата нәфрәт уятудан курыкты ул.

Ә теге хатынның кем булуын (аның исеме Фәрбүзә булып чыкты) бер атнадан соң гына ачыклый алдылар. Өч яше дә тулмаган, алмадай матур кызы калган, диделәр. Ире хатынын өзелеп яраткан. Шуңа хыянәтен кичерә алмаган, күрәсең: хатынының мәетен фатирына кертүдән баш тарткан.

«Этләргә бәрегез, тормышымны агулады, кәнтәй», – дип кычкырган икән дип, бөтен шәһәр тутырып сөйләделәр. Җыелган халык кызының: «Әни, әнием. Әниемне кайтарыгыз!» – дип өзгәләнүеннән тыела алмый елаган, имеш. Мәдинәне милициягә чакыртып, машинада Фәрбүзәнең сумкасы юк идеме, дип сораштылар. Баксаң, аның эштәге сейф ачкычлары югалган икән. Фәрбүзәнең ире Фәрит, хатынының эшеннән ачкыч эзләп килүләр ешайгач, милициягә Мәдинәнең адресын белешеп мөрәҗәгать иткән. Шуңа чакыртулары икән.

– Юк, бернинди дә ачкыч күрмәдем, – диде Мәдинә, Фәриткә ачулы карап. Әйтерсең, булган фаҗигагә Фәрбүзәнең ире Фәрит гаепле иде.

Шуннан соң бик акрынлык белән генә авыр тәэссоратлар эчендә ярты ел вакыт үтте. Ачкыч Фәрбүзәнең әниләреннән табылган, ә сумка исә (юк, ул сумка түгел, ә бизәнгечләр савыты иде) чыннан да Мәдинәдә булган. Мәдинә теге көнне машина ишеген ачып җибәргәч, күз алдында пәйда булган оятлы һәм гыйбрәтле хәлне шулай гына җуеп буладыр сыман, кеше күрмәсен дигәндәй, тиз-тиз генә идәндә аунап яткан әлеге бизәнгечләр савытын алып, үз сумкасына яшергән иде.

Тукта, хастаханәдән чыккач, бизәнгечләр савытын кухня шкафы өстенә ташлаган иде түгелме? Ул аны әле яңа гына табып алды. Фәритнең адресын белешеп, косметичканы Фәрбүзәнең кызына йә иренә тапшырмакчы, шул рәвешле авыр хатирәләрдән мәңгегә котылмакчы булды. Юк, бүген һич кенә дә керми китәргә ярамый...

Мәдинә, урлашып тотылудан курыккандай, тирәягына ялт кына күз төшереп алып, тиз генә звонок төймәсенә басты. Тып-тып атлап килгән баланың аяк тавышы ишетелде:

– Кто там? – диде ул русчалап.

– Әтиең өйдәме, үскәнем? – дип чак сорый алды Мәдинә, каушаудан кипкән иреннәрен көчкә кыймылдатып.

– Мама? Әни! Әнием! Әти дә өйдә. Ты только не уходи. Пожалуйста, не уходи, я сейчас открою, – дип йөгергәләп йөри башлады бала. Урындыкка менеп, көч-хәл белән ишек келәсен ачты. Әмма әнисе урынында бүтән ят апа басып торуын күреп, башта яшьле күзләренә гаҗәпләнү билгеләре чыгарды, аннары әнисен тапмавына гаҗиз калып, елап-сыкрап, бөгелеп төште.

– Ты не моя мама! Уходи! Где моя мама? Әни, әнием! – дип үкседе ул.

Өмете өзелгән кечкенә кызчыкны кызганудан Мәдинәнең күзләрен яшь каплады. Көч-хәл белән эчкә үтте. Лилияне (кызчыкның исеме шулай иде) кулларына алып, сөя-сөя күкрәгенә кысты, нindider юату сүзләре әйтте. Фатир эченә күз төшерде. Өйдә җиһазлар, кием-

PRESSA.RU

салым, савыт-саба хәтсез күренсә дә, тәртип беткәнгә охшый. Аш-су өстәлендә башланып ташланган аракы шешәсе, закускалар... Залдагы диванда, исерек булса кирәк, Фәрит гырлый.

Кызчык: «Ашыйсым килә», – дип шыңшыды.

Мәдинә гүя йокыдан уянып китте: сабый ач икән ләбаса. Тиз генә Лилияне киендереп, якындагы кибеткә алып чыгып китте. Күп тә үтми, азык-төлек төяп кайттылар. Лилия дә үзенең кечкенә кәрзиненә тәм-том тутырырга онытмады. Җитмәсә, апасы йомшак мәче дә алып бирде. Сабыйның йөзендә сизелер-сизелмәс елмаю билгеләре барлыкка килде.

Мәдинә, аш пешереп, Лилияне ашатты, төчегә коймак коеп, чәй ясады. Лилия шатлыгыннан ни эшләргә белмәде: мәчесе белән мәш килде, сикергәләде, җырлады, уйнады. Кунак апасы: «Әниең сиңа бирергә кушты», – дип, бизәнгеч савытын кулына тоттыргач, сөенеченнән кычкырып көлеп үк җибәрде. Бүлмәсенә кереп бераз уйнауга, йоклап та китте. Мәдинә аның өстенә япты, вакытсыз ятим калган сабыйны кызганып, елыйелый аркасыннан сөйде, уенчыкларын җыештырды.

Фәрит һаман берни белми йоклый иде. Мәдинәнең бу ике ятимне кызганудан йөрәге чәнчеп куйды. Хәлләренә керергә теләгәндәй, аш, ванна бүлмәсен җыештырды. Үзе: «Фәрит уянып китсә, нәрсә дип акланырмын», – дип борчылды. Әмма башлаган эшне төгәлләргә өйрәнгән ул, Фәрит яткан диванга бик якын бармаска тырышып кына залны да тәртипкә китерде. Тагын бер йокы бүлмәсен ачты. Анда, нишләптер, бар нәрсә дә тәртиптә иде. Урын-җир дә җыештырылган көе. Стенадагы келәм өстенә Фәрит белән Фәрбүзәнең туй киемендә елмаеп төшкән фотолары эленгән. Мәдинә, үзен ярамаган эш кылгандай хис итеп, тиз генә ишекне япты. Әллә нигә тыны кысып, башы әйләнеп китте. Йөрәге белән тоя: бәхетсез булмаган бу хатын. Тормышлары да җитеш. Ни җитмәде икән үзенә?!

Ул үзе, ичмасам, иргә баргач, торырга кирәк дип яшәде инде. Рафыйгы җәбер-золымны аз күрсәтмәде: бер дә юкка көнләшеп җанын кимерде, телеңне йотарлык булганда да пешергән ашыннан, җиренә җиткәндә дә эшләгән эшеннән гел гаеп табып, хурлап торды. Кул күтәрүдән дә тайчанмады. Якыннары: «Болай кыланмас иде, берәр йөргән кешесе бардыр», – дисәләр дә, Мәдинә ышанмады. «Эше авыр, эше җаваплы. Арый торгандыр, үтәр әле», – диде. Тик җаена, көенә торырга тырышты.

...Бәй, нәрсә уйланып тора әле ул? Кайтырга вакыт лабаса. Записка язарга кәгазь эзли башлады. Залдагы өстәлдә Фәритнең шофер таныклыгы, паспорты, башка документлары ята. Бәй, Мәдинә белән яшьтәшләр дә икән бит. Соңлап өйләнгәндер, күрәсең. Мәдинә үзе кияүгә бик яшьли чыкты шул.

Мәдинә Фәритнең блокнотыннан бер бит кәгазь ертып алды. Килүнең сәбәбен аңлатты. Берәр юатырлык җылы сүз эзләде – тапмады. «Ник эчәсең? Балаң хакына тукта!» – дип кисәтмәкче булды. «Хакым бармы соң?» – дип икеләнеп, тагын туктап калды...

«Фәритнең уянып куюы бар. Китәргә кирәк. Китәргә һәм бүтән килеп йөрмәскә...»

Мәдинә шундый уйлар белән, җәһәт кенә ишеккә атлады. Уянып, бүлмәсеннән чыккан Лилия:

– Кунак апа, китмә, мин куркам. Әти эшкә киткәндә, өйдә берүзем калам, – дип, йокылы күзләрен уып, шыңшый башлады.

– Әйдә, – диде Мәдинә, аны ашыгыч киендерә башлап. – Минем иртәгә ялым. Янымда булырсың. Кәгазьгә: «Лилия минем белән», – дип язды да, телефонын, адресын күрсәтеп, кызчыкны җитәкләп кунакка алып китте.

Әмма ул көнне дә, икенче көнне иртән дә телефон шалтырамады: Фәрит килмәде. Тик төш вакыты үткәндә, Лилиягә кунак апасы яңа күлмәк тегеп кидергәч, пәрәмәч пешкәч, ниһаять, кыңгырауга бастылар.

– Гафу итегез, – диде Фәрит кырә-керешкә, Мәдинәгә карарга кыймыйча. – Әйдә, кызым, киен, кайтабыз.

«Юк, югалырдай егеткә охшамаган». Мәдинә аның оялчан күзләренә өмет чаткыларын шәйләми калмады.

– Әти, кара әле, минем нинди матур күлмәгем бар. Кунак апа текте. Кичә ул безгә кунакка килде, бүген син килдең. Әйдә, ю кулыңны, чишен, чәй эчәрбез, – диде Лилия, әтисенә ялынып. – Аракы эчмә! Анда кайтмыйм. Әни юк анда. Монда бар, – яшьле күзләрен тутырып, әле әтисенә, әле Мәдинәгә карады. Өлкәннәр югалып калды. Аның каруы, Лилия һич туктап тормады, түземсезләнеп сораулар тезде:

– Син әнием булырсыңмы? Мин сине яратырмын, әнием диярмен.

* * *

... Елдан артык вакыт үтте. Май аеның кояшлы бер көнендә әти-әнисен җитәкләгән, курчак кебек киенгән Лилия, тимер юл вокзалында, поезд килгәнне көтеп, сикергәләп уйный иде, ниһаять, поезд килеп туктады. Вагоннарның берсеннән солдат киемендәге бер яшь егет сикереп төште. Мәдинә Лилиягә нидер әйтүгә, кызчык аның кулындагы чәчәкләрне алып, солдат абыйсына таба йөгерде.

Ринат башта туктап калды. Аннары, чемоданын җиргә утыртып, елмаеп, Лилияне өскә күтәрде:

– Менә нинди икән минем сеңелкәш, – диде ул. – Кара, нинди зур кыз икән син!

Лилия, шатланып, аны муенынннан кочты. Ул арада Ринатның иңнәренә әнисе килеп асылынды.

Читтәрәк торган Фәрит: «Кайтуың белән, Ринат», – диде, сынаулы карап. Ирләрчә кул кысып күрештеләр. Лилия, сөенче алырга ашыгып, Ринат абыйсының колагына пышылдады:

– Әни минем белән уйнарга бәби алып кайта!

Фәрит белән Мәдинә аның нәрсә әйтүен аңлап, бер-берсенә карадылар. Ринат кыенсынып торган әнисен кочып алды. Язмышлары алда ничек булыр, әмма ул көнне Лилияне күтәргән улы Ринат һәм чемодан тотып, иңнәреннән ышанычлы кочып атлаган ире Фәрит уртасында барган Мәдинә бик бәхетле иде.



Рәмзия
КАШАПОВА

КАДЕРБИКӘ БЕЗНЕҢ МӨШӘРРӘФ ТҮТИЕБЕЗНЕҢ УРТАНЧЫ КЫЗЫ БУЛГАН. АРАДА ИҢ ЧИБӘРЕ, ИҢ УҢГАНЫ ДА УЛ ИДЕ ДИП СӨЙЛИЛӘР.

ЧЕГӘН КАРГЫШЫ

Элекке заманнарда безнең Саба ягы авылларында чегәнннәр еш күренә торган булган. Алар, нигәдер, Саба тирәсен бик яратып, шунда озаккарак тукталып, яманып, төзәтенеп, хәлләнеп, ары таба киткәннәр. Бу хәлгә инде Саба кешеләре дә ияләшеп беткәннәр. Ят халык белән вакытлыча күршелеккә әллә ни исләре китмичә, тыныч кына яшәп ала торган булганнар. Чегән ирләре тимерчелек тирәсендә кайнашкан арада, чегән хатыннары яраткан кәсепләре – багучылык белән шөгыльләнеп алалар икән. Тик татарлар күрәзәчелекне бик өнәмәгәнгә күрә, алар кәсепкә урыс, мари авылларына барып кайталар. Шулай бервакытны алар каяндыр кайтып килешли Кадербикәне очраталар.

Кадербикә, Тимершык авылыннан килеп, Саба мәктәбендә укый икән. Кызның хыялы – алга таба Арча педучилищесында укып, укытучы булу. Бәхетле булу өчен кызның бөтен мөмкинлекләре бар кебек. Табигать аны гаять гүзәл итеп яраткан. Кара кучкыл түгәрәк йөзле, калын толымлы, кара шомырт күзле, алсу битле, чия иренле чибәркәйне күрүгә чегәннәр, бара торган җирләреннән шып туктап калалар. Аларның үзенә игътибарын сизүгә, кыз адымнарын тизләтеп, өйгә ашыга. Чегәннәр дә аңа иярә. Курккуга төшкән кыз йөгерә үк башлый.

«Чегәннәр мине куып киләләр», – дип, коты алынып кайтып керә ул өйгә. Шундук мич артына кача. Кич белән табын янында җыелышкач, бу вакыйганы әби белән бабайга да сөйлиләр. Чегәннәргә тыныч кына карый торган бабай да бу юлы борчылып куя, олы кызының малайларына Кадербикәне мәктәпкә озатып, каршылап йөрергә куша. Киңәштабыш итеп утырганда ишектән бер төркем чегән хатыннары килеп керә. Арадан берсе сүз башлый.



Бабай чегән хатыннарының ни йомыш белән йөрүләрен сораштыра. Әмма чегән абыстаеның гозере барысының да һушын ала. Чегәннәргә, аз да түгел, күп тә түгел, Кадербикә кирәк икән. Хатынның улы Кадербикәгә гашыйк булган. Татар киленне үз кызлары кебек яратырга, кадерләргә, ел саен килеп, аны туганнары белән күрештерергә, мәһәргә күп итеп алтын, шәп атлар бирергә вәгъдә итәләр. Яучылар өч көн рәттән киләләр. Алар хәтта туйны татар йолаларын үтәп уздырырга да ризалар икән.

Кадербикәне базга төшереп, чегәннәрдән яшерәләр. Урлаплар дип курпып, кызны өйдән бер яры чыгармыйлар. «Ни гөнаһларым өчен миңа бу җәза? Бу хурлыкка калганчы балачакта ук үлгән булсамчы!» – дип өзгәләнә 15 яшьлек кыз. Тик өзгәләнәселәре алда булган икән әле...

Өч көн рәттән иртәдән кичкә кадәр яучылаганнан соң, бабайның үз сүзендә чакматаш кебек каты торганын күргәннән соң, теге чегән абыстае каргап чыгып киткән: «Бәхете булмас кызыгызның. Без – чегәннәр чит кавемне арабызга кертмибез. Улымның гашыйклыгын йөрәгем белән сизгәнгә күрә генә ялындык сезгә. Моннан ары кыз үзенә үпкәләсен». Хәтта шушылай каргап сүз әйткәннән соң да бабай какшамаган.

Чегәннәр киткәчтен дә әле бу вакыйгага бик озак телдән төшми. Хәер, хәтта хәзер дә чегәннәргә кыз биреп җибәрү булмастай эш кебек тоелыр иде.

Кадербикә Арча педучилищесын тәмамлап, Казакъстанга китә. Анда аның әнисе белән бертуган апасы яши иде. Шунда алдынгы гына карашлы тоелган казакъ егетенә кияүгә чыга ул. Казакъ егете менә татар гүзәлен тиң итмәгән. Ә бит шул Кадербикә Җизказган төбәгендәге авылда казакъларга мунчаның ни икәнен аңлаткан, алай гына да түгел, мунча мичләрен дә үзе чыгарган, мичтә ипи пешереп күрсәткән, малтуар асрап, балаларына зур белемнәр бирә алган. Ире Молдабай кулына нинди асылташ килеп кергәнен төшенмәгән, күрәсең. Хатынын бик җәберләгән Молдабай. Кыйналган Кадербикә апаның хастаханәдә ятыпятып чыккан чаклары да булгалаган. Әбекәем үлгәнче: «Кадербикәне чегән каргышы гына харап итте», – дип сөйләде. Нилектәндер, Кадербикә апа үзе дә туган ягына кайтып, апалары янына сыенып яшәүне кирәк санамады. Әтиләренә охшап тәкәббер булып, татар әнине санламаска өйрәнеп үскән балалары янынннан китәргә теләмәде.

PRESSA.RU

Балан

Көзге урман, сары ялан...
Коела кыңгыраулар.
Мәк гөледәй кызыл балан –
Каерып сындыралар.

Әнкәй, күңелем елап кала:
«Ник аны сындыралар?
Баланнар бит коелмыйлар,
Коела кыңгыраулар...»

Баланны өзәләр бит,
Җепләргә тезәләр бит.
Ятып елар чаклар була,
Үзәкне өзәләр бит.

Колакта чыңлый һаман,
Эндәшә кебек әнкәм:
«Авыр чаклар бик күп була –
Түзәргә кирәк, балам...»

Әкрен генә чәчтән сыйпап
Эндәшә кебек әнкәм:
«Өлгергәндер инде балан,
Җыярга кирәк, балам».

Колакта чыңлый һаман,
Эндәшә кебек әнкәм:
«Авыр чаклар бик күп була –
Түзәргә кирәк, балам...»



БАЛАН ӘЧЕСЕ...

Әни кала... Елыйсы килә... Алты яшьлек энем мине юаткан була: «Елама, апа, елама, әни еламаска кушты». Кушты да ул, 10 яшьлек кыз балага әнидән аерылуы авыр шул. Энемнең күзләре дә тулып түгелергә тора. Менә шулай, атнаның шимбә кичен әнигә кунакка барабыз да, дүшәмбе иртән, җитәкләшеп, биш чакрым араны авылыбызга таба атлыйбыз, тугызынчы яртыда минем дәресләр башлана. Әни күрше авылда үги әти йортында, әниләре вафат булган дүрт ятим бала янында кала. Энекәш озак чыдый алмады, берничә айдан, сөйкемле сөяк булмаса да, үги әти йортына, әни янына күчте.

Мин: «Бармыйм!» – дидем. Әрнегән йөрәгемне учка йомарлап, үпкәмне эчкә йотып, авыр булса да, әнине бик сагынсам да, изге күңелле нәнәй белән картатай янында үз авылымда калдым. Ныгыр-ныгымас канатларым белән шул оядан зур дөньяга очтым.

Үз әтием безне миңа дүрт яшь булганда калдырып киткән. Бер авылда яшәсәк тә, ул энем белән мине якын күрмәде, балаларым, дип сөймәде, яңа хатынының улын карап үстерде, ул малай белән бер класста укыдык. Нигә аерылышканнарының сәбәбен белмим, белергә дә теләмәдем, әти безгә чит иде.

Үги әти начар кеше булмады. Сугыш чоры балаларының барысы кебек үк үз җилкәсендә күп авырлыклар кичерә. Тик, ни кызганыч, әни килгәч тә заман чире булган

йомшаклыгын, яман гадәтен ташлый алмады. Күп чиләнде әни аның белән, тик чыдады, аерылмады. Уртак энекәш туды. Җидебезгә дә белем биреп, аякка бастырдылар, туйлар ясадылар. Тик үги әти йөрәк белән иртәрәк гүр иясе булды. Әни тагын ялгыз калды. Өч төрле җиде бала тәрбияләде ул. Җан җылысын тигез бүләргә тырышты. Хәзер үз балаларым, оныкларым булгач, аңлыйм, бик яратасы, кысып сөясе килгәндә дә безне – үз балаларын үги балаларыннан артык иркәләмәскә, аларның күңелен китмәскә тырышты. Шуңа микән, мин дә әни куенына кермәскә, аның кулларыннан ераграк йөрергә тырыштым. Үги туганнарым белән бик дусбыз, бертуганнар кебекбез.

Үземнең әти, әҗәл чире белән авыргач, безне эзләп тапты. Әни: «Карагыз, ярдәм итегез, ул сезнең атагыз», – диде. Үзебезгә алып килдек, дәваладык, хәлен җиңеләйтергә тырыштык. Гөнаһлымындыр, әтигә карата күңел төбендә барыбер боз эреп бетмәде. Яшьли сабак алдым: балалар өчен иң мөһиме – тулы гаилә. Ходайга шөкер, иремнең балаларны, оныкларны өзелеп яратуын күреп, йөрәгем шатлык һәм рәхмәт белән тула.

Студент еллары. Яңа елны каршылау киче. Сабакташларым Гөлшат белән Әлфия чыршы бизи. Чыршы ботагында көмеш йөгертелгән пыяла уенчыклар, боз сөңгеләр, чыршы күркәләре, Кар бабай белән Карсылу, кыстыргычка утыртып тезелгән кечкенә шәмнәр. Шул матурлык арасында күзгә бик ташланмый гына, тыйнак кына, тик нindидер зур кирәкле серне үзенә сыйдырган сыман балан тәлгәше асылынып тора... Күңелемне утлы дулкын ярып үтте. Кыш уртасында, ясалма һәм матур ялтыр уенчыклар арасында кипкән, төссез, ләкин чын балан тәлгәше... «Йөрәк кебек кызыл балан...»

Башта зиһендә тоташ рәсем – әни язмышы пәйда булды. Хатынкыз язмышы. Шул язмышка сыйган бәхетле балачак, күкләргә күтәргән мәхәббәт, табыш-югалтулар һәм өмет, өмет, өмет...

«Балан» җыр булып язылмады, ул шигырь булып туды. Икенче көнне үк аны инде цитаталарга бүлгәли башладылар. Кемдер кемендер сагынса: «Авыр чаклар бик күп була, түзәргә кирәк, балам», «йөрәкне өзәләр бит, барыбер түзәләр бит», студентлар шук халык, зачет бирәлмәсәләр дә, шаярып: «Түзәргә кирәк, балам», – дигән тәгъбирләр еш ишетелә башлады.

Иң беренче мин бу җырны Фәнүнә Сиражетдинова башкаруында ишеттем. Ул Илеш районында яшәгән апасы Флизәдән өйрәнгән. Авторларын белмәгәннәр. Фәнүнә гастрольләрдә йөргәндә халык сорап җырлаткан бу җырны, ә ул үз чиратында җырның авторларын табарга ярдәм итешүләрен үтенгән. Ниһаять, Пермь өлкәсендәге концерттан соң, сәхнәгә ап-ак чәчле мөлаем кеше чыга һәм үзен җырның композиторы дип таныштыра. Бу кеше Сәүбән Чуганаев икән. Җыр текстының авторы мин икәнен әйтә. Шигырьне кайдан алганы миңа билгесез. Шунысы кызганыч: без бүгенге көнгәчә композитор белән таныш түгел, язмыш безне күрештергәне юк. Бер-беребезгә кешеләр аша сәламнәр генә җибәрәбез.

Соңрак җыр Нәзифә Кадыйрова башкарыуында киң яңгыраш алды. «Әнинең әйткән сүзләрен искә төшердегез, дип, кочаклап, елап, рәхмәт әйтәләр иде», – ди ул.

«Уятмакчы булсаң халык күңелләрен» дигән телевизион проектта Зөһрә Шәрифуллина башкаруында бу җыр беренче бүләккә лаек була.

Зөһрә Сәхәбиева белән Хәйдәр Бигичевның Уфа гастрольләре вакытында мин бу җырны, ниһаять, беренче тапкыр зур залда – Нефтьчеләр сараенда ишеттем. Эшем буенча ашыгып кына командировкага килгәндә, телефон аша Зөһрә мине концертка – җыр тыңларга чакырды. Кызганычка каршы, мин кичке концертка кала алмыйм. Зөһрә концертка хәтле җырлап ишеттерергә булды. Тамашачы залында Хәйдәр Бигичев, Дилә Булгакова һәм мин идем. Зөһрәнең контральто тавышының тирәнлеге, көче, халыкчан башкаруы, безне генә түгел, җырны ишетеп залга кергән бинаны җыештыручы хатын-кызларны, аппарат артында утыручы тавыш операторларын, сәхнә бизәүчеләрне, яктыртучыларны тетрәндерде. Алар Зөһрәне сырып алды, күзләрендә яшь иде.

Бу җырны үзәкләргә үтәрлек итеп Хәния Фәрхи дә кызы белән башкара. Кат-кат җырлаталар.

«Балан» җыры хакында остазларымның, каләмдәшләремнең фикерләре дә минем өчен бик мөһим. Наҗар ага Нәҗми «Шәл һәм орчык, мич һәм җыр» дигән мәкаләсендә: «Бер җырың белән минем йөз җырымны бәреп ектың», – дигән иде. Бу инде, билгеле, минем күңелне күтәрер, канат куяр өчен әйтелгән сүзләр. Йөз җыр язып та, бөек шагыйрьнең кабатланмас бер юл шигырен дә тудырып булмыйдыр ул. Рәхмәт остазга!

«Балан» җыры татар галәменә таралганнан соң, баланнарга бал тәме йөгерде... Чын бал әчкелтем була шул...» – дип язды Татарстанның халык язучысы Марсель Галиев.

Башкортстан телевидениесенең татар телендәге «Рәйхан» тапшыруы (авторы Халисә Мөхәммәдиева) бу җырга махсус тапшыру багышлады, фильм төшереп, фондта калдырды.

Еллар үтте, инде үзем дә гомер көзенә кердем. Бәхетле язмышлы булды бу җыр. Нидә соң аның сере? Бу җыр әни хакында, минем хакта, бик күп башка хатын-кыз язмышы хакында да. Гомер таңында яшь кызның гади генә балан тәлгәшендә тирән драма тоюы, күзаллавы, сиземләве, алдан күрүе булган икән.

Иртән таныш көйгә уяндым. «Балан» җыры. Мин белмәгән җырчылар башкара. Яшьләр килә, димәк, җыр яши. Димәк, тормыш дәвам итә.

...Әни бездә ята. Инде үзе бала кебек кенә калды, шәм кебек эри. Хәлен сиздермәскә тырыша. Гел догада.

Әни китә... Елыйсы килә...

Халисә МӨДӘРРИСОВА



Тулысынча сайтыбызда укыгыз.

PRESSA.RU



САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУГАН КӨНЕ ЯКЫНЛАШКАН САЕН, МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВНЫҢ «ӘГӘР ХОДАЙ АҢА АННА АХМАТОВА ГОМЕРЕН БИРГӘН БУЛСА, БЕЗ АҢА ҮЗЕ ИСӘН ЧАГЫНДА УК ҺӘЙКӘЛ КУЯРГА ТИЕШ БУЛЫР ИДЕК» ДИГӘН СҮЗЛӘРЕ ИСЕМӘ КИЛӘ ДӘ ТӨШӘ.



Асия МАЛИКОВА

«ҖЫР ИКӘНСЕҢ, ТОРМЫШ...»

Аннан соң шактый вакыт уйланып йөрим... Билгеле инде, танылган шагыйрәгә һәйкәл кую турында түгел... Анна Ахматованың да «яшәрлеге бар иде бит әле», – дим үз-үземә. Ачы язмышлы бөек рус шагыйрәсе хакындагы уйларым әле пенсия яшенә дә җитә алмый якты дөньядан китеп барган талантлы шагыйрьләребезгә, язучыларыбызга, җырчыларыбызга барып тоташа. Яраткан әбиемнең сүзләре исемә төшкәч кенә, бераз сүрелә башлыйм. Якыннарын югалту хәсрәтеннән өзгәләнүчеләрне ул: «тәкъдиренә шулай язылган аның, язмыштан узмыш юк», – дип тынычландыра иде.

Атаклы француз язучысы Ромен Ролланның «Тормышның бар шатлыгы иҗатта. Иҗат итү – үлемне үтерү ул» дигән сүзләре дә якын миңа. Гомеренең соңгы сәгате сукканга кадәр кулыннан каләмен төшермәгән, яшәүнең иң чын бәхет икәнен башкаларга да аңлатып бирә алган нечкә күңелле, батыр йөрәкле кайнанам шагыйрә Саҗидә Сөләймановамы мин үлемсезләр рәтенә керә дип уйлыйм. Билгеле инде, иң беренче чиратта, тормышка мәдхия җырлый торган иҗаты өчен. Кайчандыр шагыйрь Рәдиф Гаташ та: «...Икарлар кебек, «Кызыл каурыйлар»ын кош юлында калдырып, чиксез очышка китеп барды ул. Әмма... үлемгә түгел, бәлки безнең йөрәкләргә, шигърияткә, мәңгелек мәхәббәткә китте...» – дип язган иде аның турында.

Тормыш симфониясе

Саҗидә Сөләймурованың 90 яшьлек юбилее уңаеннан «Татнефть» компаниясенең «Рухият» фондында аның турында саллы гына истәлекләр китабы дөнья күрде. Аны әзерләгәндә минем уй-фикерләремне шагыйрәнең дистәләгән каләмдәше, дуслары, китап укучылар да куәтләп җибәрде. Кемнәр һәм нәрсәләр белән генә чагыштырмадылар аны! Берәүләр сандугачбылбыл, күбәләк, гөлчәчкә дип атаса, икенчеләр музыка коралы белән чагыштырып куя. Гомерен моңлы бер җыр дип атаучылар да бар. Динамикасы, илдә барган драматик вакыйгаларга үрелеп баруы һәм иҗатының тәэсир итү көче белән минем үземә симфонияне хәтерләтә. Ә үзе ул кеше гомерен оркестрның бер кылы белән чагыштыра:

Чор – оркестр гүя,
кеше гомере –
әйтерсең лә шуның бер кылы.

Балачагы турындагы истәлекләрен укыганда, гармун тавышын һәм курай моңнарын, былбыл сайравын, халкыбызның дәртле җырларын ишеткән кебек булам. Башкортстанның Яңавыл, Тәтешле яклары, ямьле Бүә буйлары күз алдымнан үтә. Юклык заманы булса да, булганына шөкер итеп яшәүче халкыбызның батырлыгы, сабырлыгы, тырышлыгы турында сөйли торган вакыйгалар хәтергә уелып кала.

Кайнанамның өмет тулы хыялларга бай яшьлек еллары турындагы истәлекләрен, булачак ире – Мәскәү әдәбият институты студенты, якташы Әдип Маликовка язган хатларын укыганда яшь укытучының йөрәк тибешен ишетәм, аның мәхәббәт хисләре бөреләнеп килүнең шаһиты булам. Яшь парның гаилә корып җибәрүенә куанам. Колагымда шагыйрә сүзләренә соңрак авылдашым Шамил абый Кашапов көй язачак «Туй җыры» мотивлары яңгырый.

Сикәлтәле юлдан «койрык кагып чапкан грузовой» тавышы гаилә корып җибәргән Саҗидәнең тормышында яңа сәхифә ачылу турында хәбәр итә кебек. Сөеклесенә сыенып, әрҗәләр арасында эселә-тәртелә баручы кызның язмышына колак салам: аның туган җиреннән аерылып билгесезлеккә китеп баруында тарантаслы пар атларның ерагая барган тояк тавышларын ишетәм.

Яшьләрне үз балалары кебек кабул иткән Минзәлә шәһәре белән бәйле истәлекләр дә кызыклы. Саҗидә укыта, ире – республика газетасының үз хәбәрчесе. Бер-бер артлы уллары Илдар һәм кызлары Миләүшә туу дөньяларын түгәрәкләп җибәрә. Тик монда озак яшәргә туры килми аларга. «Гасыр җиле, мотор гөре, җырга иңгән яңа авазлар» аларны Әлмәткә чакырып китерә. Ачысын да, төчесен дә татый ул монда. Ачысы – Миләүшәсен югалту, татлысы – улы Әнвәр туу. Күп тә үтми, Әлмәт каласы «аның яшьлек дәртенә, бәхетемәхәббәтенә» әйләнә, биредә җан сөйгән хезмәтен, тугры дусларын таба ул.

Саҗидә Сөләйманова иҗаты белән Мәскәү нәшриятлары да кызыксына башлый. СССР халыклары телләренә әсәрләре тәрҗемә ителә. Аның иҗади яктан шактый бай һәм бәрәкәтле бу чоры турында укыганда шагыйрә сүзләренә язылган «Нефтьчеләр маршы» (М. Имашев), «Без йөргән юлларда» (Р. Яхин), «Әлмәтем, Әлмәтем» (Р. Вәлиуллин), «Урсал тауда» (Р. Нәгыймов), «Әлмәтем-мәхәббәтем» (С. Садыйкова) җырлары искә төшә.

Тормыш җырлап кына бармый икән шул. Зарлануһәйләләүне белмәгән горур кызга язмыш тагын сынау әзерләп куя. Әйтерсең лә, аның: «Авырлыклар күрдем дип әйтә алмыйм. Булганнары вакытлыча булгандай үтә шикелле тоелды. Әткәй тәэсире, аның халык арасындагы абруе һәрвакыт янәшә булгандыр, каршылыкларны җиңелрәк үтәргә ярдәм иткәндер», – дигән сүзләрен ишетеп торганнар!

Төшенкелеккә бирелүдән аны иҗат итеп калу теләге генә коткара.

Шулай итеп, биш елга сузылган яшәү өчен көрәш чоры башлана. Табиблар белән Газраил арасындагы көрәшне ул менә ничек сурәтли:

Кан саркыган ай-балталар тотып,
Газраилләр баса бер якка.
Һәр сәгатьтә яшәү белән үлем
Бәрелешә пычак-пычакка.
Бу көрәштә син бит ялгыз түгел,
И оттырма, кешем, ектырма! –
Кылдан нечкә сират күпереннән
Кылыч тотып чыга доктор да.

...Шомыртлар ак чәчәктә... Тирә-юньгә хуш исе таралган. Ак кәфенгә төренгән ак шагыйрәне соңгы юлга озаталар. «Тормыш, исәнме!» җыры яңгырый. Шул көннән башлап ирем Әнвәр шомырт исен күтәрә алмый...

«Халыкның рухын нурландыручы»

Кайнанамның яман чир белән көрәшеп үткәргән елларда хастаханәләрдә алып барган күзәтүләрен бүгенге көнгә кадәр тыныч кына укый алганым юк әле. Аларда куркырлык бернәрсә дә юк югын, киресенчә, салкын акыл белән язылган. Шулар арасында хирург Виктор Михайлович Поляков ясаган операцияләргә йөргән вакытында язып барган дәфтәр дә сакланган. Кайбер язмаларны ул үзе үлгәннән соң басылып чыгачак «Гөлбадран» повестенда файдалана. Дәфтәрләргә катлаулы чир белән көрәшкән кайбер кешеләрнең хатлары кыстырылган. Төрле рецептлар язылганга күрә шул дәфтәрләр арасында сакланганнардыр инде алар. Ничек кенә булса да, ул хатлар кайнанам күңелендә өмет чаткылары кабызмый калмаганнардыр, мөгаен.

Түземлеген, үзе язганча, «җир тырмалап» җыя ул: зарланмый, рухы нык аның. Шуңа күрә шигырьләре дә якты. Алардан эчке дәрт, көч бәреп тора кебек. Мондый шигырьләр рухи яктан сәламәт кеше йөрәгендә генә туа ала. Аның «Гөлбадран» повесте да нәкъ шундый. Әлмәт китапханәсе хезмәткәрләре әйтүе буенча, биредә иң күп сорала торган китапларның берсе икән.

PRESSA.RU





Бу гаиләгә килүемдә Сажидә Сөләйманова билгеле бер роль уйнады дисәм, һич арттыру булмас.

Яман чиргә юлыккан кешеләрнең һәм аларның якыннарының үз сорауларына җавап, рухи көч эзләвенә бәйледер бу, бәлки». Ничек кенә булса да, шагыйрәнең иҗаты һәркемгә ачык. Аның тормыштагы юлын «мәңгелек михнәт күрергә» дучар ителгән халыкның рухын нурландырып, аны тормышка, яшәүгә юнәлдерүдә дип саный Сажидә Сөләйманова истәлеген мәңгеләштерүгә зур өлеш керткән күренекле шагыйрь, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мөхәммәт Мирза...

Икенче каләмдәше, шулай ук Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Зөлфәт: «Сажидә апа бик кыска вакытта балкып очып үткән йолдыз булды. Аның шигырьләрен беренче укыганда ук андагы фаҗигале фәлсәфи хисләрнең тирәнлегенә, чисталыгына исләрем китә иде минем. Шул шигырь юллары артында ниндидер бер фаҗига җиле исеп тора кебек тоела иде. Ул чын мәгънәсендә мастер иде. Чын мәгънәсендә! Ул бик күп шагыйрьләр ирешә алмаган биеклеккә күтәрелде поэзиядә. Укып карасаң, аның шигырьдәге һәр юлы көтелмәгән... Син аның киләсе юлда нәрсә әйтәчәген сизенә алмыйсың. Һәм аның рифмасын да чамалый алмыйсың син. Күп кешенең рифмасын чамалап була, ә Сажидә апаныкын – юк! Менә бу чын мәгънәсендә оста... Мастер!» – дип соклануын яшерми.

«Их, ышаныйк әле өметләргә...»

Без Әнвәр белән өйләнешкәндә әнисенең вафатыннан соң шактый вакыт узган иде инде. Дуслашып йөри башлаганга өч ай тула дигәндә өйләнештек без. Танышуыбыз да кызык кына булды. Татарстан пионер оешмасында эшләгән елларым... Бик эшлекле кыяфәтле бу егет элегрәк тә күземә чалына иде. Исеме, нишләптер, хәтердә калмаган, ә менә аның комсомолдан эчке эшләр органына эшкә күчүе колакка кереп калган. Бер үк юлда йөри идек без. Кайвакыт эштән дә бер үк транспортта кайтырга туры килә. Янәшә басып торсак та, бөтенләй күрми иде ул мине. Ә хезмәттәшем белән юл буе сөйләшеп кайта. Соңыннан гына белдем: без берничә ай бер үк бинада эшләп алганбыз икән. Мин 1985 елда ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетына эшкә килгәндә, Әнвәр комсомолның Казан шәһәре комитетында эшләгән. Ул елларда өлкә комитеты да, шәһәр комитеты да бер үк бинада урнашкан иде.

Беренче тапкыр опера һәм балет театрында игътибар итте ул миңа. Яхшы хәтерлим: 1992 елның җәе. Илдә демократик үзгәртеп корулар башланган чак. Бөтендөнья татар конгрессы утырышы бара... Дус кызым Фәридә белән театр фойесында очраштык та, утырыш беткәнен көтеп торабыз. Аны да, минем кебек, яшьләр секциясе эшендә катнашырга чакырганнар икән. Әнвәр дус кызымның яхшы танышы булып чыкты. Ул аны ерактан ук күреп алды да, яныбызга килеп басты. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, Фәридә безгә әле яңа гына эшсез калуы турында сөйләп алды. Райкомнарны яба башлаганнар, ди. Ул шул шаукымга эләккән икән. Ә Әнвәрне яңа эшкә – Татарстан Югары Советына чакырганнар, Эчке эшләр министрлыгыннан соң ул «Известия Татарстана» газетасында да эшләп алган. Югары Советта матбугат үзәген оештыру белән шөгыльләнәчәк, ди. Дус кызымның эшлекле сыйфатларын белгәнгә күрә, Әнвәр аның планнары белән кызыксына башлады. Матбугат үзәгенә тагын бер ставка бирергә вәгъдә итүләре турында да әйтте.

«Бу вазыйфада эшләүче кеше газета-журналлар белән элемтәдә тору өчен җавап бирә, еш кына материалларны үзебезгә дә язарга туры килер. Син бу эшкә ничегрәк карыйсың?» – дип сорады ул аннан. «Юк ла, язарга яратмыйм мин. Менә безнең Асия яза», – диде ул, миңа күрсәтеп. Әнвәр бу сүзләргә игътибар да биреп тормады бугай, сораштыруын дәвам иттерде. Матбугат үзәге хезмәткәренә телевидение, радио аша да еш кына чыгышлар ясарга туры киләчәк икән. «Юк, бу яктан да миңа туры килми бу эш, ә менә Асиягә бара, ул радиодан да, телевидениедә дә чыгышлар ясый», – дип кырт кисте дустым, миңа ишарәләп (балалар белән эшләгәндә туры килә иде инде, кая барасың?!). Әйтерсең ул түгел, ә мин эш эзлим!

Шул сүзләрдән соң гына Әнвәр миңа борылып карады да, «Шулаймыни?» – диде бераз гаҗәпләнеп, һәм «Татар телен дә яхшы белергә кирәк бит әле», – дип өстәп куйды. Ә Фәридәне алдан әзерләп куйганнармыни, тагын миңа күрсәтеп: «Ю-у-у-к. Минем татар телем кухняда сөйләшерлек кенә. Ә менә Асия әдәби татар телендә сөйли дә, яза да», – дип тезеп китте. Фәридәнең шул сүзләреннән соң Әнвәр, күзләрен зур ачып, миңа карады:

«Чынлапмы?» – диде ул, бераз вакыт үткәч, ышаныргамы-ышанмаскамы дигәндәй. «Сез кайда эшлисез соң, татар телен кайда өйрәндегез?» – дип сораштыра баш-

лады. Телефонымны сорады. Егетне бөтенләй алыштырып куйдылармыни. Шул вакыт тәнәфес игълан ителде, без Фәридә белән үз эшебез буенча йөгердек...

Тормыш күрсәтте

...Берничә айдан мин эшләгән пионер оешмасы штабын да Ирек мәйданыннан читкәрәк күчерделәр. Телефоныбыз да үзгәрде. Театрдагы уен-көлке катнаш әйтелгән сүзләр дә онытылды. Нәкъ бер ел үткәч, кабат очраштык. Бу юлы күптәнге танышы кебек әллә каян дәште ул. Очраша башладык, һаман үзенә хезмәткәр эзли икән әле, дип йөрдем баштарак.

Аның яраткан шагыйрәм Саҗидә Сөләйманова улы икәнен дә соңрак кына белдем. Әнвәрнең үзеннән түгел, башкалар әйтте. Ул теге чакта, театрда ук, мине әнисенә охшатып калган икән. «Синең күзләреңдә әнием күзләрен күрдем. Без, егетләр, ирексездән әниебезгә охшаган кешене эзлибез бит», – диде ул бер очрашканда, аннан соң әтисе белән таныштырды. Озак та үтмәде, тәкъдим ясады: үзенең кул астында эшләргә түгел, ә тормыш сукмагыннан бергә атларга...

«Бер-беребезне юньләп белмибез дә бит әле», – дигән сәбәп табып, туебызны кичектерергә дә маташып караган идем, тик Әнвәр үз позициясендә нык торды. Ризалыгымны биргәндә аның әнисе – яраткан шагыйрәмне үзенә күрә бер гарант итеп карадым бугай мин. Аның йөрәк парәсе дә үзе кебек ихлас һәм ышанычлы `кеше булырга тиеш дип уйладым. Ялгышмаганмын.

Моның шулай икәнен тормыш үзе күрсәтте. Бала табу белән мин каты авырып киттем. Балабызны күтәреп, бер табибтан икенче табибка чабабыз. Хастаханәдә ятып дәваланырга кушалар. «Балам белән салсагыз гына ятам», – дим. «Җүләрләнмә, кызый, хастаханәдә нинди генә инфекция булмас, бала белән сала алмыйм, ризалаш», – ди миңа баш табиб. Бала карау да, өй мәшәкатьләре дә күбрәк Әнвәр өстенә төште. Иремнән «эх» дигән сүз дә ишетмәдем. Аның авыру караган кеше икәне әллә кайдан күренеп тора иде. Көндәлек тормышта да бик җаваплы кеше ул. Аның ярдәме булмаса, мин озак еллар дәүләт хезмәтендә эшли алыр идем микән? Анда бит эш көне нормалаштырылмаган: көн дә юк, төн дә юк. Шуңа күрә иремнең үзенә генә түгел, аны тәрбияләп үстергән гаҗәеп талантлы, зыялы һәм кешелекле әти-әнисенә дә һәрчак рәхмәт укыйм.

Саҗидә һәм Сабира килене

Иремә кияүгә чыкканда мин аның фамилиясен алдым. Шул көннән иҗат кешеләре арасында «Саҗидә апа килене» дип йөртә башладылар. Моңа башта ияләшә алмый азапландым... Танылган кешеләрнең якыннарына карата таләп икеләтә зур бит. Ирексездән аларның үзләре белән чагыштыра башлыйлар.

Шуның өстенә мин бит әле Сабира килене дә. Икенче кайнанам, шөкер, исән, Әлмәт шәһәрендә яши. Аның белән дә охшашлыгым зур. Төсе-кыяфәте белән ул бөтенләй үз әнием. Килен булып төшкәндә мине ипитоз, якты йөз белән ул каршы алды. Кайнатам белән бергәләп безгә матур итеп туй үткәрүче дә ул. Улыбыз тугач та, беренче булып ул шалтыратты. Авырган вакытларымда хәлемне белеп, киңәшен биреп торды. Кайнатамны бала караган кебек тәрбияләде. Саҗидә кайнанамның каберен тәртиптә тотты. Мин аны да үземнең кайнанам дип саныйм һәм бик ятатам. Исеме җисеменә туры килгән искиткеч тыйнак, эчкерсез һәм сабыр кеше ул. Аны яратмый мөмкин түгел.

Заманында Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов белән бергә Татарстан Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә бухгалтер булып эшләгән ул. Тиздән үләсен белгән Саҗидә кайнанам, җаен табып: «Яныңда Сабира булса, бик әйбәт булыр иде сиңа», – дип, иренә үз фикерен белдереп куйган. Бу турыда аларның гаилә дуслары Гамил ага Афзалның хатыны Нәфисә апа: «Үләсен белсә дә, Саҗидә апа бу турыда беркайчан сүз кузгатмады. Аның Сабираны якын иткәнен сизенә идем мин. Әдип абыйга кияүгә барырга теләүчеләр аз түгел иде. Әдип абый Сабираны сайлады», – дип искә ала.

> *Ихлас шигырьләреннән бөркелеп торган күңел җылысын тоя идем Саҗидә апаның.*

«Әдипнең шундый сүзе булды, дөрес: «Сабира сиңа әйбәт булыр», – дип әйткән иде Саҗидә, калганын әйтеп бетермәде», – ди бу турыда Сабира кайнанам. – Язмыш булгандыр инде, күрәсең. Әдип белән без 28 ел яшәп калдык. Әдип Саҗидә апаны бик хөрмәт итә иде, бик әйбәт кеше иде шул Саҗидә апа. Икесенең дә урыннары җәннәттә булсын!» – ди ул.

Кешегә алтмышта да әни кирәк

Үзе исән булмаса да, Саҗидә Сөләймановaны искә алмаган көнебез бик сирәк. Шуңа күрә без барыбыз да аның мирасын саклау белән шөгыльләнәбез.

Кешегә өч яшьтә дә, алтмыш яшьтә дә әни кирәк. Иремнең дә, сабый чагындагы кебек, әнисенең иңнәренә башын куеп, дөнья мәшәкатьләреннән азга гына булса да арынып торасы, аның белән киңәшләшәсесөйләшәсе килгән минутлары була. Ярый әле юксынганда укырга истәлек язмалары, фотолары сакланган.

Бик рәхмәтле Әнвәр әнисенә. Барысы өчен дә... Өйләнешкәндә татарча авыррак сөйләшкән Әнвәр хәзер әнә үз телебездә шактый иркен аралаша. Улыбыз Әскәр, рус, инглиз телләре белән беррәттән, татар, төрек телләрен дә үзләштерде. Кайнанам аларның бу уңышлары белән, һичшиксез, горурланыр иде дип уйлыйм.

...Ә үземә килгәндә шуны гына әйтә алам, кайнанамның шигырьләрен яшьлектә ничек яраткан булсам, хәзер дә шулай яратып укыйм. Мин аларны ун тапкыр да, йөз тапкыр да укый алам. Моның сәбәбе һич кенә дә аның кайнанам шигырьләре булуында түгел. Чын шигърият кенә шундый тәэсиргә ия.

PRESS.RU



Казанда Төрки дөнья җырчылары бәйгесе бара иде. Ике хатын-кыз мине танып эндәште. Гозерләре бар икән: «Нәкыйбә ханым турында языгыз әле сез!» Нәкыйбә ханым! Кем икән соң ул? Болар бит инде мин аны тәгаен белә дип уйладылар. Белүчеләр табылды. «Нәкыйбә ханыммы? – диде бер танышым. Ул күп йөри, күп белә торган абруйлы җитәкче. – Нәкыйбә ханым ул – «Бәкер»нең асылташы!»
Җәйге якта мин дә барып эләктем «Бәкер»гә. Миңа йөкләнгән гозер инде онытыла төшкән иде. Эссе кояш нурларын бөтен кышка җитәрлек итеп тәнемә сеңдерергә теләп, эскәмиядә җәйрәп утырам. «Нәкыйбә ханым килә! Шулмы, үземе?» – янәшәмдә чүмәшкәннәр пышылдашканга мин дә иренеп кенә күземне ачып карадым. Нинди ханым? Аккош бит бу! Түбәндәге күлне әйләнгәндә мин бу Аккошны көн дә күреп, күзәтеп, сокланып хозурланам. Әй ул Аккошның кадерен, дәрәҗәсен белеп кенә, күл өстен тибрәтми генә йөзүләре, нәзакәтле итеп кенә озын муенын боргалап куюлары... җитәр, күрдегез, дигәндәй, камышлыкка кереп югалулары! Бу ханым да, чәчен биек итеп өеп куйган башын горур тотып, биек үкчәләрендә вәкарь белән генә атлап килде-килде дә, кабинетына кереп югалды. Артыннан киттем... «Баш шәфкать туташы» дигән язулы ишек янында туктап калдым. Шәфкать туташының өлкәне була инде, «башы» да була микәнни?

НӘКЫЙБӘ ХАНЫМ

– Мин «Бәкер»гә 18 яшемдә килеп кердем. Баш табиб Рәшит абый Абашев мине: «Ниһаять «Бәкер»гә мишәр кызы килде!» – дип каршы алды. Шуннан бирле мин монда. «Хезмәт кенәгәсе»ндә эшкә алыну турындагы язу берәү генә. Шулай без, мишәр кызлары, төшкән җирдә таш булабыз. Мишәрлегем хак, Чирмешән районының Иске Кади авылыннан мин. Дүрт балалы колхозчы гаиләсеннән. Килеш-килбәтемнән морзалык эзләп азапланмагыз. «Баш»лыкка да түбәннән – ләм арасыннан күтәрелдем. Менә шул Абашев абый килә-килешкә мине ләм белән дәвалау бүлегенә – иң пычрак, иң авыр бүлеккә куйды. Имеш, бу бүлекне «грязьдән» шушы кыз чыгарса гына инде. Баш-аягым белән чумдым шул грязьгә. Ул чагында хәзерге механизмнар, технологияләр юк. Күлдән күтәрелгән ләмне кешеләргә суга бутамыйча, шул килеш кенә сылыйбыз. Аннары кырып-кырып төшерәбез. Ну файдасы да күп иде инде, малай! Үземдә сыналган – беләм! Биш кенә сеанс алдым. Гомерлеккә ябышты инде әллә дип курыккан чирем бөтенләйгә китте. Яшь вакыт бит, чибәр вакыт, дәртле вакыт. Атна саен авылга кайтасы гына килеп тора. Кайда трактор чанасында, кайда җәяү. Өшеттем мин аякларны. Сызлавына түзәр әмәл юк. Җитмәсә, аксый да башладым. Шуннан соң күндерделәр хезмәттәш апалар: «Бишне генә ал, Нәкыйбә! Бишне генә! Синең болай аксап йөреп торуың безнең санаторийга антиреклама бит», – диләр. «И, ул безнең ләмдәге тере бактерияләр, антибиотиклар, сапропельләр үлгән кешеңне терелтер». Тыңладым.

Аның үзенә дә 35 ел хезмәт дәверендә соң чиккә җиткәннәрне үгетләргә бик еш туры килгәндер. Юкка гына Татарстанның атказанган медицина хезмәткәре түгел лә ул Нәкыйбә Сәлахова.

– Бер танышларым баласызлар иде. Бала сөяселәре килә. Берзаман болар чыштыр-пыштыр йөриләр. Экстракорпораль ысул белән бала табып була икән дип тә, әллә тәрбиягә бала алырга микән дип тә сөйләшәләр. «И бәгырьләрем, – дим боларга, – өлгерерсез анда барырга да. Башта безгә килеп карагыз әле сез». Шулай, әллә нинди клиникаларда акча туздырганнан соң, безгә

килеп бәби табалар. Теге танышларым да берне генә түгел, икене алып кайттылар. Бәкер ләме шифалы ул!

Балалар тусын өчен ләм генә җитми шул әле, мәхәббәт тә кирәк. Нәкыйбә белән Миншәһид менәргә яраткан Каштауга хәзер бүтәннәр менә. Тауның исемен дә үзгәрткәннәр – Мәхәббәт тавы. Әйе, дөнья гел үзгәреп тора шул ул. Менә егерме елдан артык Нәкыйбә – тол хатын. Миншәһид исемле уңган механизатор егет белән нибары унбер ел яшәп калганнар. Ярый әле Нәкыйбә бер-бер артлы дүрт баласын табып өлгергән. Балалар да хәзер өчәү генә инде. Томрап торган баш баласы – алты айлык Динар улы сәгать эчендә менингиттан китеп бара. Бу әле күрәсе хәсрәтләрнең башы гына булган икән.

Миншәһид! Әйе, әйе, Миншәһид... Ул кара төндә мотоциклы белән машинага бәрелгән Миншәһид үзе генә һәлак булмады, Нәкыйбәнең дә гөл сабагын сындырды. Бәгырькәен җирләп кайткан көннең төнен онытасы юк. «Миллионер колхоз иде Бәкер авылында. Колхоз өендә торабыз. Балаларны йокларга яткырдым да, олы якка чыгып, диванга бөрешеп утырдым. Үксеп-үксеп елыйм. 30 яшем дә тулмаган өч балалы тол хатын мин хәзер. Балаларымның олысына 10 яшь, кечесенә – ике. Үз ызбам юк. Туганнарым ерак. Мин – япа-ялгыз! Мәңгегә ялгыз! Инде елавым тыелгысыз ярсуга әйләнеп бара. Шунда яныма улым Илнур чыгып утырды, аннан Диләрәсе, Миләүшәсе... Инде диванга дүртәүләп сыенып утырдык. Дүртәүләп елыйбыз... Бу төнне дә кичтек. Иртәгәсен торып чыксак... Дөньяда туфан дулаган икән! Бөтен тирә-күршенең йорт түбәләре җирдә ята, агачлар ауган, коймалар ишелгән. Бер безнең түбә исән. Менә Ходайның хикмәте! Имеш, түшәм такталары да тол хатыннар хакына ишелмибез, дип әйтәләр икән дип сөйләгәне бар иде беренче фатир хуҗам Зәмзәмия әбекәйнең. Түзәргә кирәк, димәк. Мине Аллаһы Тәгалә үзе саклый! Шул төннән соң мин еламаска өйрәндем».

Өйрәнсә дә, елыйсылары калган әле аның. Ә хәзергә Нәкыйбә тырышып-тырмашып дөнья йөген тарта. Санаторийдагы эшен төгәлләп кайтуга колхоз эшенә йөгерә. Колхоз өендә торгач ни, чөгендерен дә бүлеп бирәләр, борчак чабарга да әйтәләр. Ә дөньяда туксанынчы еллар башбаштаклыгы. Ни кануннары, ни акчалары тотрыклы түгел. Бар ышаныч – ихатадагы малда. «Кеше мачы асрамаганда ике сыер асрадым мин. Кара таңнан курка-курка абзарга сыер саварга чыгам. Улым Илнур, кушмасам да, фонарь тотып, миңа иярә. Бер юлы бу тоткарланыбрак чыкты. «Әни, безнең суыткыч астына елан шуышып кереп китте», – ди бу. Йөрәгем жу итеп куйды. Куркак мин, коелдым да төштем. Тычкан гына түгел, елан бит! Ул арада, минем йөземдәге үзгәрешне абайлаган малай кире өйгә кереп китте. Шундый сизгер ул минем. Бераздан әйләнеп чыкты. Кулында – елан! Карга бәрде бу моны. Бала елан икән. Салкын карга килеп төште. Җәлләдем мин елан баласын. Туңа бит инде. Илаһым, җан иясе бит. Бер Ходаем аңа да җан иңдергән ләбаса. Улыма банка алып чыгарга куштым. Кире өйгә – җылыга алып кердек. Банка өстен марля белән каплап куйдык. Бәләкәй генә елан, ә бит торып басты! Еланнарны зирәклек символы, диләр. Ни нәрсә аңлаткан икән аның бу ишарәте? Мөгаен, яшибез әле (!) дигәндер. Иртәгәсен үзебезнең лабораториягә алып киттем елан баласын. Улыма да сабак булгандыр бу гамәл – әнисе алай ук куркак түгел икән лә! Шулай да Илнурым минем өчен үзен гел җаваплы саный. Эш көнем телефоннан аның сәламен ишетүдән башлана».

Балалар сәламнәр, яхшы хәбәрләр генә ирештереп торса иде дә ул.

– Миләүшә авариягә юлыккан!

Чәчәк кебек төпчек кызы. Шөгер белән Бәкер арасы нибары унике чакрым гына лабаса. Миләүшәнең гомере өчен көрәшеп узган айлар, еллар артта калып бара. Кыз үзе дә үтә чыдам, тырыш бала булып чыкты. Аягында тимерләр йөрткән, үзе култык таягы белән йөргән килеш медицина институтын тәмамлап килә. Аны да язмыш һаман сынап тора. Аны, димәк, ананы да. Тимерләрен алыр көннәр җиткәндә генә, кыз бозда таеп егыла, тимерләрнең берсе сына. Әле мин шушы язма белән утырганда, тимерләр алынды, Миләүшә быел табиб дипломы ала, дигән күңелле хәбәр килеп иреште.

Очкычларга утырырга куркабыз. Һәлакәт, әнә, кул сузымы арада сагалап тора.

Әйе, яшибез әле. Тырмаша торгач, Нәкыйбә ханым да үз йортлы булган – «ызбага тырышканда шырпы да сатып алмадым». – Ире һәлакәтеннән соң беркадәр вакыт узгач, яшь хатынны янәдән аңлаешсыз бер хасталык халәте арбап ала. Терелер сыман түгел.


– Иске Кадига күрше-тирә, әниләр белән бәхилләшеп килим дип кайткач, күрше әби янына кереп, ауныйтәгәри сызланган, ыңгырашкан идем берчак: «Ирем дә булмагач, мантый алмам, сәламәтләнә алмам инде мин», – диеп. Шунда күп җәбер күргән, күп золым татыган әби бер генә җөмлә әйтте: «Кызым, сәламәтлекне аны ир-ат бирми, Аллаһы Тәгалә бирә!» Ходайга ялвар, савыгырсың» Чарасызлыктан эзләп барган Әлки әбие – танылган күрәзәче дә шулай диде: «Савыгасың! Әле үзең күпләрне сихәтләрсең. Кулыңда шифа бар».

Менә син агай! Монда берәү үләргә тора. Ә аңа, син үзең – табиб, диләр. Алай гына да түгел, Әлки әбие, үз мишәрен үтә яратып, атна буе янында тота. Киткәндә: «Кызым, мин сиңа бер кешегә бирмәгәнне бирдем», – дип озатып калды. «Шөкер, ныгыдым. Иремнән тол калганда: «Иркә хатын. Яши алмас!» – диючеләр булган. Шөкер, яшәп торабыз бит әле. Өч балам да югары белемле, үзем – хөрмәттә.

Баш шәфкать туташының – һәр Ходай бирмеш көне «Бәкер» шифаханәсенең мең дә бер мәшәкате белән үтә торган кешенең һәр минуты санаулы, вакытын алмыйк.

Асия ЮНЫСОВА

PRESSA.RU



ПРАГА – УЛ ДИАГНОЗ!



Эльмира ЗАКИРОВА

«МАРСИАНГА ЕВРОПАНЫҢ БЕРДӘНБЕР ШӘҺӘРЕН КҮРСӘТЕРГӘ КИРӘК ДИСӘЛӘР, ПРАГАДАН ДА ШӘБРӘГЕ ТАБЫЛМАСТЫР».

Прагага барып кайткач, язучы һәм журналист Петр Вайль сүзләре белән тулысынча килештем.

Кызыл түбәләр диңгезе

Кызыл чирәп түбәле өйләр, готика стилендәге борынгы замоклар, ратушалар, йөзләгән шпильләр, текә баскычлар, тап-тар урамнар... Боларда ниндидер үзенә бер шарм бар. Урамнарның кайберләреннән кара-каршы килүчеләр бер-берсенә юл бирмичә уза да алмый хәтта! Шуларның берсенә кереп китсәң, ул икенчесенә алып чыга; анысы, үз чиратында, агач ботагы сыман тармакланып, тагын да серлерәк урам-тыкрыкларда адаштыра – нәкъ лабиринттагыча. Корольләр, принцлар... Өрәк, сихерчеләр кыяфәтенә кереп, караңгыда шәйләнгән күләгәләр җанны табан астына ук төшерә! Борынгы фонарьлар, йомры таш түшәлгән тротуарлар, караңгы туннельләр шәһәрне тагын да серлерәк итеп күрсәтә. Күктәге кыйгач ай да ниндидер сер өсти. Чып-чын әкият! Минем шул әкиятне тоясым, шул шәһәргә барасым килә! Үземне әллә ничекләр әзерлим: ялын җайлыйм, акчаны туздырмаска тырышып җыям, интернетта эзләнәм...

Чехия белән бәйле кадерле истәлекләр күңелдән түгелә. Иң беренчесе, әлбәттә, хоккей матчлары! 80 нче елларда безнекеләр Чехословакия командасы белән уйнагандагы тамаша, эйфорияне күрсәгез икән сез!.. Җанатарларның гүләү-







сикерүеннән өйләр дер селкенә, тәрәзәләр зыңлап тора сыман! Без чех хоккее легендасы Вацлав Недоманскига, уенчылар Голечек, Поспишил, Мартинецларга гашыйк! Алар үзебезнең Мальцев, Третьяклар, Харламов кебек үк якын... Тагын... мәктәптә укыганда сәхнәдә чех биюен биюебез хәтердә. Темпераментлы хәрәкәтләр, күңелле му-зыка... Мәскәүнең «Прага» кибетендә чират торып алган кызыл босоножкаларым ЦЕБО фирмасыныкы иде! Уңайлы, чыдам, модалы! Хәзер ул фирма Bata икән... Чехия минем өчен җырчы Карел Готт, киноактриса Яна Брейхова, Ярослав Гашекның герое солдат Швейк та әле ул. Koh-i-noor карандашлары, «Scoda» автомобиле, «Том и Джерри» мультфильмы... Әле тагын Прагада үзебезнең Дилбәр дә бар!.. Ниһаять, юлламалар алынды, Шенген визасы әзер. Хыяллар сеңлемРитаныкы белән тәңгәл килде – сәфәргә җыена башладык.

...Самолет җиргә якынлашуга, түбәндә, яшеллек эчендә – кызыл түбәләр диңгезе, костел-замок шпильләре, таулар тезмәсе, зәңгәр тасма булып сузылган Влтава елгасы аермачык күренде. Прага җәйдән дә аерып булмастай сентябрь челләсе белән каршылады безне. Кай ягы беләндер бераз Рига белән Таллинны, Германия шәһәрләрен, нәрсәсе беләндер Хельсинки белән Стокгольмны хәтерләтте ул миңа.

«Добри дэн!»

Иң башта ят телдә сөйләшүләр колакны ярып керде. Русчага да, алманчага да охшаган кебек. «Добри дэн» – «Исәнмесез», анысы аңлашыла инде. Күпчелек сүзләрдә әллә ничә тартык янәшә килә икән бит: «насхледаноу» (сау булыгыз), «пршедкрм» (кабымлык), «крк» (тамак)... Чү! Чат саен нигә «позор!» дип язып элгәннәр соң әле бу чехлар? Аптырадык. Ә ул «игътибар!» дигән сүз икән безнеңчә! Рус теленә охшаган дип йөрсәң, мәзәк хәлләрдә калуың да бар. Карабодай – поганка, кыяр – окурки, ислемай – вонявка, ашамлыклар – потравины, җиләк-җимеш – овощи, яшелчә – зеленина, туңдырма – змрзлина...

Русча рәхәтләнеп аңлашырга була. Өлкәнрәк яшьтәгеләр заманында мәктәптә рус телен өйрәнгән. Яшьләр – белми.

Шулай итеп, добри дэн, Прага! Отельгә урнашуга, тәрәзәдән картина булып кергән каштаннарны, шәһәр манзарасын күздән кичерәм. Тизрәк, тизрәк шул дөньяга кереп югаласым килә. Кроссовкаларымны салып куеп, чемоданнан җиңел чүәкләрне чыгардым да, тәүге тапкыр шәһәргә җыендык. Разведкага! Монда ялгыш та үкчәледән йөрмиләр! Күзгә чалынсалар да, бик сәер һәм көлке күренерләр иде! Аларның брусчаткаларында, дистәләгән чакрымнар үтәсе җәяүлеләр сукмакларында, озын биек баскычларында йөрер өчен соң!.. Җәяүләп кенә киттек. Һәр йорт – үзенә бертөрле, бер-берсенә бөтенләй дә охшамаганнар! Башлар әле уңга, әле сулга каерыла. Кызык! Урам тулы вьетнамнар!.. Монда алар кибетләр тота ди хәтта. Кара, кара, әллә этләрсез йөри алмый инде бу чехлар? Бала урынына карыйлар бит. Рюкзак, сумкалар эченә үк утыртып куйганнар!.. Ай, нинди чәчәкләр!!! Шаккатып, сокланып, тирә-якны, кешеләрне күзәтәбез. Хатын-кызлары бизнемичә дә матур! Киемнәре дә тыйнак, күзгә чәчрәп керми. Үзләре тыныч, мөлаем.

Сүзләрне сузып әйтсәләр, яһүд акценты белән русча сөйләшәләр кебек тоела.

Акча, транспорт, яшәү, туклану – һәммәсе мөһим. Турфирма акчаларны еврога алмаштырырга киңәш иткән иде. Чехиядә үз кроналары әйләнештә. Аптырыйсы юк, акчаны Сбербанк банкоматыннан кроналар белән алып була. Кибет кассаларында да сбербанк карталарын кулланасың. Кайда акча алмаштырырга дип аптырап йөрисе юк. Прагада андый пунктлар дөнья! Әллә ничә төрле акча бирәмлеге кулланылышта булгач, башлар

PRESSA.RU



■ Биюче йорт. Прагалылар аны, шаяртып, атаклы биючеләр хөрмәтенә «Джинджер һәм Фред» дип тә йөртәләр. Усалрак теллеләр өчен ул – «исерек йорт». Бинаның эчендә халыкара офис үзәге урнашкан, иң югары катында – ресторан.

Биек үкчәле туфиләреңне ала күрмә дип, алдан ук кисәттеләр!

буталып бетә. Ки́беткә кергән саен күңелдән генә арифметик мәсьәлә чишәм. 1 крона, димәк, безнеңчә 3 сум тирәсе; 1 евро 70 сумнарда тирбәлә.

Җәмәгать транспорты, алга киткән илләрдәгечә, минутына кадәр төгәллек белән йөри. 30 минут утырып барсаң, метрода да, трамвайда да 24 крона (72 сум) түлисе, 90 минутлык ара 32 крона (96 сум) белән исәпләнә. Транспортка утыру белән билетны тиштерергә кирәк. Юкса контролерлар 800 крона штраф түләтәчәк!

Тәэсирләр бихисап! Җитмәсә, минем уңайлы дигән мактаулы чүәгем дә аякны кырырга өлгерде инде. Ул кадәр йөрүгә соң!.. Ташламалы бәягә Bata босоножкаларын кереп алырга бер сәбәп булды ул!

Төньякка китсәң – Дрезден, Көньякта – Вена...


Отельдә иртәнге аш кына каралган – «швед өстәле». Көндезләрен барган җирләрдә капкаларга була. Хәер, без ашамыйча да йөрергә риза! Соң гына кайтып, үзебез белән алган тәм-том белән чәй йотабыз да... Иртәгә нинди маршрут әле, Рита? Иртүк торабыз да тагын чыгып чабабыз (ярый әле вакыт бездәгедән 1 сәгатькә артта!). Сәяхәткә баручылар Вацлав мәйданында, ат өстендәге король һәйкәле янында җыела. Термаль чишмәләре белән дан тоткан курорт-шәһәр Карловы Вары, колмактан сыра кайнатучы атаклы «Крушовице» заводы, Глубока над Влтавой замогы... Прагадан Германиянең Дрезден, Мюнхен, Нюрнберг шәһәрләренә, Австриянең Венасына, Венгриянең Будапештына барып кайту берни түгел. Дрезден – иң якыны, 2,5 сәгать кенә барасы, Чехия чигеннән нибары 20 километр гына кала анда. Крумлов замокларыннан Австрия болыннарына кул сузымы гына арада. Бу шәһәр тулаем ЮНЕСКО мирасы исемлегендә! Әйтәм аны көтү-көтү кореялылар очрый. ЮНЕСКО шәһәрләренә барып, шунда фотога төшү зур дәрәҗә санала икән аларда... Крумловның кечкенә генә урамнары әкият шәһәрен хәтерләтә. Андерсен «Снежная королева»сын шушында язган инде!

Автобуста гид колакчыннар өләшә. Мавыктыргыч хикәясен тыңлап, урта гасырларга кереп адашасың. Юл буена сине озатып килгән күренешләр фотоаппаратка эләгеп бара. Ул юллар, ул табигать! Төзек авыллар. Колмак басулары, виноград бакчалары кала. Кырда җыелмаган кабаклар тәгәрәшеп ята. Һәм, әлбәттә, кызыл чирәп түбәләр!.. Автобусыбыз бер-ике урында шоссе юл аркылы салынган күпер астыннан узды. «Бу күпер болан, куяннар өчен, – дип аңлатты гид. – Юкса машина астына керүләре бар».

V–VII гасырларга караган риваятьләрне тыңлый-тыңлый, Европа буйлап сәяхәтебезне дәвам итәбез...

«Мин сөйләгәннәрнең чиреге генә исегездә калса да, сез инде шактый нәрсә беләчәксез», – дигән иде гид Ксения. Славяннарның Чех һәм Лех җитәкчелегендә яңа җирләр эзләп Көнбатышка килүе, Чехның Ржип тавында үз дәүләтенә нигез салуы...

ЧЕХИЯ КУХНЯСЫ



■ **Трдельник** *(рәсемдә)* һәр чат саен сатыла. Чүпрәле камырны агач шампурларга урап, өстеннән шикәр комы сибеп, учакта, мангалларда кызарганчы пешерәләр, кайнар килеш ашыйлар. Эченә туңдырма да салалар.

■ **Кнедлик** ипине алыштыра. Гади оннан йә бәрәңге оныннан парда пешерәләр. Табынга гарнир итеп тә бирәләр.

■ **Полевка** безнеңчә аш була. Алар, гадәттә, әчкелтем-татлы, соус кебек куе. Сарымсак ашы, тозлы кәбестә ашы дисәләр дә, аларга әле сыр, бәрәңге, суган, сарымсак салып пешерәләр. Яшелчәләр кыргычтан уыла, йомырка сарысы кушыла.

■ **Брамбораки.** Майоран кушып пешерелгән гап-гади бәрәңге көлчәсе әнә шундый катлаулы исемдә. Бик тәмле!

■ **Гермелин** сортлы йомшак сырны кызарганчы кыздырып, кайнар килеш ашыйлар.

■ **Утопенцы** – суган, борыч белән тәмләтелеп, маринадланган сарделькалар.

■ Кафелардагы бәяне ишек төбендә зур итеп язылган менюдагы сыра хакыннан чамалап була: 50 кронадан артып китсә, бу кафе кыйммәт санала.

■ Чех аш-сулары күбрәк дуңгыз итеннән әзерләнә. Әмма Прагада вегетарианнар өчен «Пиццерия»ләр дә шактый.

Мәхәббәт һәм нәфрәт романнары... «Сарайдагы король яраннары башларына галәмәт биек прическалар ясап йөргән. Ә муеннары гофре якалар белән капланган. Йокларга ятканда анда ит, ризык кисәкләре куеп калдыралар икән... – Ксения юри пауза ясап тора да: – Чәч арасына оялаган тычканнар төшеп ашасын өчен», – дип көлдерә.

...Дрезден. Эльба ярындагы бу шәһәр үзе музей кебек! Борынгы костеллар, Дрезден галереясы, исkиткеч күренешләр... Тикмәгә генә аны «Европа балконы», «Эльбадагы Флоренция» дип йөртмиләрдер инде. Административ биналар янәшәсеннән үткәндә, гид Маргарита экскурсиянең ял көненә туры килгәненә үкенгәндәй: «Гадәти эш атнасында күрсәгез икән сез, – ди. – Узган килүдә монда утызлап велосипед тезелеп тора иде. Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләүчеләрнең транспорты – велосипед. Германиянең вице-канцлеры, Саксония хөкүмәте башлыгы Зигмар Габриэльне дә велосипедта күргәнем бар! Ул эшкә шулай килә», – дип, Россия туристларын гаҗәпләндерде.

Экскурсиядән соң капкалап алырга, шәһәр карап йөрергә 2 сәгатьтән артык вакытыбыз бар иде. Әлбәттә инде, супермаркетка юнәлдек! Немецлар ничек киенә икән, бәяләр нинди, бездәгедән аерыламы? Халык кафега китте. Ә без кысмырланырга булдык әле. Коры-сары белән дә тамак ялгап була ла. Кибеттән күмәч (ә ул кап-кайнар иде!), әллә кефир, әллә йогурт алдык шунда (тел белмәү бәласе!)... Майлылыгы 30% диген язу гына шпаргалка иде. Кефирыбыз... шундый тәмле каймак булып чыкты! Авылда сепараттан яңа аертылган сөт өсте белән мичтән генә алган көлчәләрнең тәмен хәтерлисезме әле? Без шундыйрак бәхетле халәттә идек! Өстәвенә, тәмле һәм арзан да! Кешеләр 20 еврога әбәт ашаса, безнең икебезгә нибары 2 евро тотылды! Аннары Эльба ярында утырдык. Шәһәрдә йөгерешчеләр күп иде булса кирәк. Зәңгәр футболкалы меңләгән студент, елга буйлап йөгереп, көзге кросста катнашты. Монда халык шундый: канцлер да, мәктәп укучысы да спорт ярата!

Король резиденциясеннән Президентныкына әйләнгән Пражский Градта җәяүләп йөргәндә гид Лидия сөйләгәннәр аеруча хәтердә калган.

«Чехлар – тыныч халык. Алар ашыкмый, каударланмый. Машиналар сезгә кычкыртмый. Президент машинасы узганда да сиреналар уламый. Туристларны, шәһәребез кунакларын куркытып, аларның нервыларын тынгысызлыйсылары килми. Кешеләрнең тынычлыгын кайгырту беренче урында тора бездә. Чехиядә ЕГЭ юк! Балаларның психикасын бозудан куркалар. Ә Праганы антистресс-шәһәр дип йөртәләр. Аның бренды – тынычлык халәте. Бездә черкиләр дә юк. Кондиционерлар да юк. Эссе дә, бик салкын да түгел – талгын һава. Җан рәхәте. Сентябрь башындагы Прага үзе Влтава ярында ыспай гына кояшта иркәләнеп ятучы песине хәтерләтә. Җылы, җайлы! Прагага бер килгән кеше гомере буена сагына бу шәһәрне, аны яратмау мөмкин түгел. «Прагага тагын ничек барырга инде! Үзем бер булган шәһәргә бөтенләй дә барасым килми, ә Прагага кабат китәр идем!» – дип язган Марина Цветаева да. Менә шулай... Прага – ул диагноз!..»

Ул, сүзеннән бүленеп, якыннан гына узучы машинага күз салды да: «Юк, Президент үзе юк икән... – дип куйды. – Әйттем бит, сигнал биреп сискәндермиләр... Ә президент еш уза моннан. Ул да безнең кебек үк кеше. Без йөри торган докторларга ул да язылып бара... Шундый кызык хәл сөйлиләр. Берчак аңардан: «Нишләп башка җиргә йөрмисез?» – дип сораганнар. «Мин дә кеше бит. Ветеринарга йөриммени?!» – дип җавап биргән, имеш. Прага үзәгендә тәмле чизкейклары белән популяр Kogo рестораны бар. Чехия президенты Милош Земанны еш кына шунда кофе эчеп утырганда күрәләр. Бернинди саксыз, озатып йөрүчеләрсез генә...»



Аһ! Бу күренешләрне эләктереп алырга фотоаппарат та җитешә алмый...

Дилбәр Прагасы

Дилбәр... Ул минем коллега. Мәктәптә укыганда ук «Ялкын», «Сабантуй»ларга язып торып, «Артек»ларга барып кайткан, журналистика факультеты студенты чагыннан ук республика матбугатында эшләп йөргән Дилбәр Исламова. Ире Алик Гыйльми белән Прагада яшәп яталар (Алик «Сәләт»нең якын дусты, «Азатлык» радиосында эшли). Кызлары Алия, уллары Булат һәм Тимур татарча, чехча, алманча сөйләшә. Дилбәр белән электрон почта аша аралашабыз. Прагага җыенуым турында аңа хәбәр иттем.

...Сөйләшкәнчә, Вацлав мәйданында очраштык. Тамчы да үзгәрмәгән: үсмерләр кебек җыйнак гәүдәле, яшь, сөйкемле Дилбәр (өч бала әнисе димәссең дә!) Ул бик теләп безнең гид булды һәм көне буе Праганың үзе яраткан почмакларында йөртте.

Сувенирлар сатыла торган базарга сугылабыз. Магнитлар, Прага постерлары, брелоклар, футболкалар, бокаллар... Һәм курчаклар! Дилбәрнең яраткан курчаклары! Кәттә королевалар, куркыныч шайтаннар, шамакай клоуннар, чып-

PRESSA.RU



■ Европа уртасында татарча сөйләшә-сөйләшә, үзебезнең Сөн буенда үскән мәтрүшкәләрне искә төшереп (өчебез дә Актаныштан бит!), бөтнекле чәй эчәбез. Аннары ашыкмыйча гына Старомест мәйданыннан атлыйбыз. Астрономик сәгать янында ха-лы-ык! Сабантуйдагыдан да күбрәк бугай!
15 минут саен суга сәгать. Ә сәгать саен анда апостоллар күренә, туристлар җыелып курантлар җырын тыңлый. 1939 елда, ни сәбәптәндер, сәгать туктап калган; немецларның илне оккупацияләве дә нәкъ шул вакытта... 2002 елда сәгать тагын туктап калган, анысында инде Чехияне су баскан, ди...




Прагадагы һәр көнебез сәяхәткә багышланган иде.

чын убырлы карчыклар, солдат Швейкларның нindиләре генә юк! Чарли Чаплиннар бик күүүп! Балачага сыман сөенеп, шул курчакларны сыйпап карап, әниләреннән алдырасы килгән кечкенә кызлар кебек бераз нәүмизләнеп, юлыбызны дәвам итәбез. Ярар инде, башка вакытта... Ару да сизелми. Инде Карл күперенә үк килеп җиткәнбез! Изге Ян Непомуцкий сынына кул белән кагылып, һәркайсыбыз эчтән генә теләк тели – тормышка аша ди!

Күперне чыккач, сулга борылып, Влтавага төшәбез. Су өсте тулы аккошлар! Күз алдында Праганың яңа манзарасы ачыла. Зәңгәр су, зәңгәр күк, ак кошлар, кызыл түбәләр... Ничек инде фотога төшермисең! Яр буеннан күтәрелеп, Франц Кафка музее янында тукталабыз. Юк, бу юлы кереп тормыйбыз. Башка вакытта... Дилбәр безне Малостранскадагы аулак тын бакчага – кызы Алия белән серләшеп утырырга яраткан борынгы Воян паркына чакыра. Күптән түгел Кафканың «Превращение»сен укыган икән, берничә сүз белән генә эчтәлеген сөйләп ата, ымсындырып куя. Укыйсы булыр.

Мондый да рәхәт урын, розалар! Алмагачтан кызыл алмалар коела, грушалар өлгергән! Үтә күренмәле күлдә балыклар сикерә, тавислар кукыраеп йөри; эскәмиядә китап укып утыручы эшләпәле ханым да, яшел чирәмдә тәгәрәшеп уйнаучы бәләкәй кызлар да, гәп куертып утыручы зыялы картлар да ниндидер тыныч халәткә күчерә. Чып-чын оҗмах бакчасы! Рәхмәт сиңа, Дилбәр! Искиткеч ял оештырдың безгә! Кайда икәнебезне дә оныттык бугай. Әллә Прагада, әллә Казанда, әллә туган якта – авылда без... Һәм бик бәхетлеләр!

ПРАГАДА НӘРСӘ КАРАРГА?



■ **Пражский Град.** Шәһәрнең иң зур, иң борынгы замогы. Праганың теләсә кайсы ноктасыннан да күренә! Анда гомер-гомергә дәүләт белән идарә итүчеләрнең резиденциясе урнашкан.
■ **Карл күпере.** Ул дөньяның бер могҗизасы. 1357 елның 9 июлендә 5 сәгать 31 минутта нигез салынган. Шуңа да 1-3-5-7-9-7-5-3-1 саннары алты гасырдан артык инде прагалылар өчен изге санала. Күпер аша үткәндә шуларны истән чыгармыйча теләк теләп, Ян Непомуцкий сынын сыйпап узсаң, теләкләрең тормышка аша, ди!
■ **Злата улочка.** Аны гномнар төзегән диярсең! Әкияттәге сыман төрле төстәге кечкенә өйләр! Бүген аларда – сувенирлар лавкасы.
■ **Старомест мәйданы.** Башкаланың тарихи үзәге. Прага һәм Чехия тормышындагы бөтен вакыйгалар шушында уза.
■ **Тынский костел.** Символик «нуленче нокта» – Европа башкаласындагы экскурсияләр биредән башлана, төрле якка тар урамнар йөгерә.
■ **Вацлав мәйданы.** Адашканнарның традицион очрашу урыны. Мәйданнан битәр, бульварны хәтерләтә. Изге Вацлав һәйкәле дә шунда гына...
■ **Зоопарк.** Зурлыгы ягыннан Прага зоопаркы дөньяда дүртенче урында тора. Ялыгызның бер көнен икеләнмичә аңа багышлагыз.

КОНТАКТ ТА : ://syuyumbike

ГАББАСОВ Рәнис

Казан дәүләт мәдәният институты

Өйләнмәгән.

Карьера: Рәшит Ваһапов исемендәге татар мәдәнияте фонды

Тормыш шигаре: «Тырышкан табар, ташка кадак кагар».

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Мине 13 саны куркытмый!

Сәхнәдә исемем яңгырый башлауга әле күптән түгел. 2015 елда Р. Ваһапов исемендәге фестивальнең яшь башкаручылар конкурсында лауреат исемен яулаган идем. Әкрен генә репертуар туплап киләм, яңа җырлар өйрәнәм. Тиздән исә минем өчен зур вакыйга көтелә: 13 ноябрь көнне Татар дәүләт филармониясендә беренче сольный концертым булачак. Дулкынланам! Зур сынау, зур имтихан бу... Иң мөһиме – концертымны тамашачы көтә! Шулай булгач, ырымнарга нәрсәгә игътибар итим?!

Үзгәрешләр көтәбез!

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов татар эстрадасының бүгенге хәле канәгатьләнерлек булмавы турында әйтте. Димәк, бу өлкәдә зур үзгәрешләр башланачак: профессионализм, сыйфат ягыннан таләпләр көчәер дип өметләнергә тулы нигез бар. Республика җитәкчесенең милли сәнгатькә карата булган әлеге игътибары безне – яшьләрне бик нык сөендерде. Чөнки без үзебез дә сыйфатлы җыр сәнгате турында уйлыйбыз һәм хыялланабыз.

Тамырлар онытылмый

Дөнья дигәндә, мин үзебезнең татар дөньясын күз алдымда тотам... һәм соңгы вакытта татар дөньясындагы иң зур вакыйгаларның берсе дип Түбән Новгород өлкәсендә бөек җырчылар Р. Ваһапов һәм Х. Бигичевка һәйкәл куюны саныйм. Үземә дә ул тантанада катнашырга, чыгыш ясарга насыйп булды. Безгә кадәр кемнәр булган, бездән соң кемнәр килер? Яшьләр өчен тәрбияви әһәмияте зур дип саныйм мондый чараларның.

сөендерде / көендерде

Халык хак әйтә икән...

«Татарның башын татар ашый», дигәнгә моңарчы ышанмый идем. Ничек кенә икән әле?! Шаккаттым! Концертым турында реклама күренүгә, моңарчы дуска санаган кайберәүләрнең үземә кинәт кырын карый башлауларын сиздем. Хәтта аяк чалырга теләүчеләр дә табылды... Нишләп бер-беребез өчен сөенә белмибез икән соң без? Көнләшәләр дисәң... Бу бит минем зур уңышка ирешүем дә түгел, нибары беренче адымнарым әле.

Картлык югыйсә һәркемгә дә киләчәк

Республикада «Өлкәннәр декадасы» бара. Миңа да бу көннәрдә өлкәннәр хөрмәтенә куелган концертларда чыгыш ясарга туры килде. Аларның безнең игътибарга, яклауга, җылы сүзебезгә никадәр мохтаҗ икәнлеген беренче тапкыр шунда тойдым бугай... Балалары булып та, картлыкларын ялгызлыкта үткәрүчеләр дә байтак икән. Монысы мине бигрәк тетрәндерде... Әти-әнидән дә кадерле кеше юк бит ул!

Гаепледәр хөкемгә тартылырмы?

Телевизор экраннарында Сириядән гел бер үк кадрлар кабатлана: бомбалар яңгырыннан җимерелгән шәһәр һәм... балалар. Алар мәктәпкә йөрми, укыйяза белми, уенчык уйнамый. Бу малайкызларның балачагын сугыш урлады. Күпләренең әти-әниләрен, яшәгән йортларын да... Алар ни күргәнне, кичергәнне күз алдына китерү дә авыр. 3 миллионнан артык бала, исән калу өчен, гаиләләре белән торган җирләреннән китәргә мәҗбүр булды, диләр. Тагын никадәр җимерелгән язмыш!

PRESSA.RU

16+

МИН ХАТЫН-КЫЗ БЕЛӘН ИХЛАС



Илфат ХӘКИМОВ, Әтнә районы Тукай исемендәге хуҗалык директоры.
Гаилә стажы – 15 ел;
Балалары: Ислам – 14 яшь;
Мәдинә – 9 яшь.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– «Сөембикә»не укучы ханым һәм туташларга охшар өчен: «Эчке дөньясына», – дип җавап бирәсем бик килсә дә, дөресен әйтим – иң элек хатын-кызның киеменә игътибар итәм. Аннан соң инде башкасына... Киендереп куйсаң, теләсә кайсы хатын-кыздан курчак ясарга була.

2 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Бу очракта, урыс әйтмешли, «два в одном» булса яхшы инде: ирне илһамландыручы хуҗабикәләр. Бер мәзәктәге кебек, кунакта – гүзәллек патшабикәсе, аш бүлмәсендә – хуҗабикә, йокы бүлмәсендә – сөяркә...

3 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Элегрәк мин ир-ат белән хатын-кыз арасындагы дуслыкка бөтенләй ышанмый идем. Әле дә ул фикердән ерак китмәдем. Әмма бер гаилә булып озак яшәүче ир белән хатын арасында дуслык була ала икән. 15 ел бергә яшәгәннән соң, Алсу белән без әле моны яңа тоя, аңлый башладык. Ә чит ир белән хатын арасында дуслык була алмый, андый мөнәсәбәтләр нигезендә кайсы да булса якның файда алу омтылышы ята.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Без Алсу белән Казан мәдәният институтының актерлык бүлегендә бергә укыдык. Беренче курс азагында очрашып йөри башладык. Гадәттә, минем көнчелек аркасында (ә мин бик көнче!) еш кына талаша идек. Аннары, әлеге дә баягы, минем үҗәтлек аркасында (үҗәт тә әле мин!) кабат дуслаша идек. Безнең курста укыган бөтен кеше Алсуга: «Чыкма Илфатка кияүгә – бәреп үтерә ул сине көнләшүеннән», – дип әйткән... Диплом алган көнне дә буран уйнатып кычкырыштык. «Инде монысыннан соң бергә була алмабыз...» – дигән идем үземә... Шулай таралыштык, ә җәй көне, уйламаганда-көтмәгәндә, Бауман урамында күзгә-күз очраштык. Язмыштыр инде – шунда бер-беребезне үлеп сагынганны, беребездән башка беребез тора алмаганны аңладык... Озак та үтмәде, мин Алсуга тәкъдим ясадым...

5 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Килешеп бетә алмыйм бу фикер белән. Әмма шуны әйтә алам: урамда берәр хатын-кызга күзем төшсә, ул, гадәттә, минем хатыныма охшаган була.

6 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Миңа калса, хатынның ирдән күбрәк мал табуы – ул дөрес түгел, табигый түгел. Тормышта төрле хәлләр булырга мөмкин, ләкин ир бу очракта үзен ничек тотарга тиеш – белмим, аның хәленә керә алмыйм, керергә дә язмасын! Бүгенге көндә, Аллага шөкер, гаиләнең матди тотрыклылыгы минем өстә, бу яктан ир вазыйфасын үтим, киләчәктә дә шулай булырга язсын. Бүтән гаиләләргә дә шуны телим! Хак динебездә ир белән хатын вазыйфалары бик дөрес билгеләнгән. Хатын-кызның төп бурычы – гаилә учагын саклау, балалар тәрбияләү, югарыда әйтелгәнчә, ирне илһамландыру. Ә хатын иреннән күбрәк мал таба башлау, йөз процент ышанып әйтәм, гаиләнең тотрыклылыгына зыян китерә. Сәламәт гаилә булмаячак ул, андый гаиләдә балалар да дөрес тәрбия алмаячак, әтине – әти, әнине әни, дип танып үсмәячәк. Мин үзем, тормышта катлаулы мәсьәләләр туганда, шәригать кануннарына мөрәҗәгать итәм. Бөтен сорауларга да аңлаешлы җавап бар анда. Гомумән, барлык гаиләләр дә мөнәсәбәтләрен шәригатькә таянып корса, бик күп проблемалардан азат булырлар иде. Гаилә мөнәсәбәтләреннән башлап, югарыга таба – туганлык, милләт, ил, дәүләт дәрәҗәсендә дә тотрыклылык булыр иде.

7 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Маңгайга бәреп: «Мин сине яратам!» – дип әйтүләренә тискәре карыйм, әлбәттә. Ләкин хатын-кыз сөюен сиздерергә тиеш, дип әйтмим – ул аны барыбер сиздерә

инде, ир-ат аның хисләрен арка мие белән дә тоя. Шулай да, хатын-кызның беренче булып: «Яратам!» – диюен хупламасам да, без, ир-ат арасында кыюсыз, кирәгеннән артык тыйнак кардәшләребез барлыгын да истән чыгармаска кирәк. Үзенең юлдашы итеп шундый ир-атны сайлаган хатын-кызлар бар икән инде, искәрмә рәвешендә аларга беренче адымны ясарга ярый. Мәңге дә беренче булып авызын ачмаячак андый зат белән бер-берсен тапканнар икән, хатын-кыз дилбегәне үз кулына алсын да, бәхетле булсыннар.

8 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хатын-кызны үз-үзен булдырган ир-ат җәлеп итә, урысча әйткәндә, «состоявшийся мужчина». Матди өлкәдәме, рухимы – аерма юк, иң элек ир кеше шәхес булырга тиеш. Мөһим түгел – юктан миллион эшләгән эшмәкәрме ул, сәнгатьтә үз юнәлешен тапкан хәерче рәссаммы – хатын-кыз өчен ул үз өлкәсендә билгеле бер дәрәҗәгә ирешкән, нинди дә булса даирәләрдә танылу тапкан кеше булырга тиеш.

9 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Мин яшь чактан ук, йомшартып әйткәндә, чибәрлек белән аерылып тормадым. Шулай да, мактану дип кабул итмәгез, беркайчан да хатын-кыз игътибарына мохтаҗлык кичермәдем. Ник алай, үзем дә аңламыйм... Мәктәптә укыган чакта бик хөрмәт иткән дус укытучы абый (аның кызы белән бергә укыдык) фән генә түгел, тормышны да өйрәтә иде миңа. Аның киңәшләре күп ярдәм итте, шулай да берсе белән тулысынча килешмәдем һәм килешмим. «Хатын-кыз белән аралашканда бик ихлас булырга ярамый», – дия торган иде ул. Ә мин уйлыйм – ихласлык кирәк! Мәктәптә укыганнан алып бүгенгәчә нинди яшьтәге хатын-кыз белән аралашсам да – сабый баламы ул, җиткән кызмы, олы ханыммы, ак әбиме – мин гел ихлас булырга тырышам.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Артык чибәрләрдән мин куркам... Андыйлар янына барып, сүз кату турында әйтмим – анысы проблема түгел. Үтә чибәрләрнең тотрыксыз булуларыннан куркам. Андый гүзәлләр гел игътибар үзәгендә, комплиментлар да кирәгеннән артык ява аларга, машинада барсалар да, шоферларның күзе аларда. Мондый караш, миңа калса, аларны боза, шайтан котырта башлый һәм ахыры начар тәмамланырга мөмкин. Ә көчлеләр мәсьәләсенә килгәндә, иң элек бит андый хатын-кызлар көчләрен гаиләгә түгел, карьера ясауга, ир-ат белән тигезлек дәгъвалауга юнәлтә, хәтта өстен чыгарга тырыша. Курыкмыйча, санамыйча бала табуга, шуларны чын кеше итеп тәрбияләп үстерүгә сарыф итсен иде хатын-кыз Ходай биргән егәрен.

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Ир-ат – хатын-кызны, хатын-кыз ир-атны аңламаган очраклар күп була инде ул. Аларны хәтердә саклау да, сәбәпләрен ачыклау да кирәкми, минемчә. Чыннан да, ике галәм инде без. Ә галәмнең чиксезлеген, хисапсыз серләрен акыл белән барыбер аңлап бетереп булмый – ышанырга гына кала. Ир белән хатын арасында да шулай – ике галәм булып яшәп тә, бер-береңә ышанырга гына кирәк.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны — туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Ачы тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, бу очракта исбатлау бернинди нәтиҗә бирмәвен раслыйм. Яшьрәк вакытта исбатларга тырыша идем, яши-яши моның файдасыз икәнен аңладым. Вакыт узгач, хатын үзе килә ул кирәкле фикергә. Тик шулай да була: кайчак үз карашыңны исбатлаудан баш тарту гаеп итеп тә кабул ителергә мөмкин – нишләп син әле минем белән бәхәсләшмисең, әллә битарафмы, янәсе?!

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...


– Мондый очрак безнең гаиләдә булырга мөмкин түгел һәм аның сәбәпләре күп. Беренчедән, минем Алсуым – энергиясе ташып торган хатын. Мин аның диванда ятып торганын күз алдына да китерә алмыйм. Икенчедән, без Алсуның әнисе белән бергә яшибез. Шуңа күрә бездә ашарга пешми калу түгел, ә пешергәнне ашаучы булмау мәсьәләсе генә туарга мөмкин.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар соңга калучан.

– Безнең гаиләдә, киресенчә, мин пунктуальлек белән мактана алмыйм. Берәр җиргә җыенсак, Алсу инде әллә кайчан әзер була, ә мин әле йә телефонда, йә телевизор каршында яки бөтенләй эштән кайтмаган булам. Яисә инде йөгерә-йөгерә юынып, киенеп йөрим. Шуңа күрә мин түгел, Алсу минем белән көрәшә, ачуланып та карый. Ничек кенә булмасын, әлегә бу көрәштә хатынга җиңелгәнем юк!

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Чынлап әйтәм, ошамаган бүләкне мин хәтерләмим. Беренчедән, мин беркайчан да нииндидер зур бүләк өмет итмим – игътибары кадерлерәк. Икенчедән, мин үземне зәвыклы кеше, дип санап йөрсәм дә, Алсуның зәвыгы минекеннән күпкә өстенрәк. Миңа нәрсә ошыйсын Алсу үземнән яхшырак белә. Бер истәлекле көнне дә онытып калдырганы юк. Ә миндә бар андый гөнаһ... Әле күптән түгел, йокларга яткач: «Бер чәчәк тә бүләк итмәдең, ичмасам!» – диде. Нинди көн иде соң бүген, дип башымны ватам. Өйләнешкәнебезгә 15 ел икән... Эш белән хәтердән чыгып киткән, дип акланасым килми. Нәрсә өчен эшлибез соң – шул гаилә иминлеге өчен бит! Тик онытылган шул, онытылган... Хатынымның туган көнен мәңгегә истә калдырыр өчен бер тапкыр онытып кара, диләр бит. Иншалла, гаиләбез туган көнне бүтән исемнән чыгармам!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU





«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

«Хатын-кыз галәме»нең бүгенге кунагы – Татарстанның атказанган артисты Зөлфия ВӘЛИЕВА. Театр сөючеләр аны Кәрим Тинчурин театры артисты буларак белсә, җыр-моң яратучыларга ул «Зә-Ләй-Лә» кызларының берсе буларак таныш. Җырчы Зөлфиянең дә, артист Зөлфиянең дә үз тамашачысы бар. Театрда аны – берсеннән-берсе кызыклырак рольләре, эстрадада – дәртле җырлары, өендә гаиләсе көтә. «Иртән – эшемә, кичен ирем, балаларым янына ашкынып кайтам. Өйдә тәмле ризыклар пешереп, кадерлеләреңне сыйлый алу бәхет бит ул», – ди Зөлфия. «Сөембикә» укучыларына бүген ул үзенең «фирменный» рецептының серен ачмакчы. Рәвешенә охшатып, Зөлфия аны «кытай фонаре» дип атый икән. Сезгә дә ошар ул «фонарьлар», пешереп карагыз әле.

«КЫТАЙ ФОНАРЬЛАРЫ»







Кирәк:

- (ике кешелек гаилә өчен) 1 яшь ташкабак (эре кыярдан чак кына зуррагы);
- 1 зур гына бадымҗан;
- 2 зур помидор;
- 200 г чамасы сыр;
- 5-6 шампиньон гөмбәсе;
- үсемлек мае, тәменчә тоз.

Эш барышы:

■ Ташкабакның юка гына итеп кабыгын әрчибез. Сабак төбен кисмибез. Бадымҗанның исә кабыгын әрчергә кирәкми.

■ Ташкабакны да, бадымҗанны да юка гына итеп буйга теләбез. Игътибар: телгәндә төпкә кадәр кисеп чыгармыйбыз!

■ Бер кулга ташкабакны, икенче кулга бадымҗанны алып, аларны бер-берсенә кидерәбез, ягъни ике яшелчәне дә кара-каршы китереп, берсе эченә берсен тыгабыз. Төпкә кадәр батырмагыз, бушрак калсын.

■ Помидорларны урталайга ярып, телемләп турыйбыз, сырны да шулай ук юка кисәкләргә кисәбез. Моның


Фото: Юлия Лекарева

өчен түгәрәк сыр кулайрак.

■ Баягы ташкабак белән бадымҗан телләре арасына помидор белән сырны аралаштырып тутырабыз. Телемләп туралган шампиньон гөмбәләре дә кыстырырга була.

■ Әлеге «кытай фонарен» майлы табага күчереп, өстеннән бераз гына үсемлек мае һәм тәменчә тоз сибәбез дә, 30-40 минутка 150 градус кызулыктагы мичкә куябыз.

■ Мичтән алып, өстеннән уылган сыр сибәбез, сыр өстенә телемләп туралган чи гөмбәләр тезеп, тагын 10 минутка мичкә тыгабыз.

■ Ә үзебез ул арада соус әзерлик. Кызыл төстәге ике баллы борычны мичкә тыгып, кабыгы көя башлаганчы тотабыз. Мичтән алып, кабыгын чистартабыз да, эрерәк кисәкләргә турыйбыз.

■ 2 зур помидорны кайнар суга тыгып торып, кабыгын салдырабыз һәм эре кисәкләргә бүлгәлибез.

■ Туралган борыч, помидор, 2-3 тырнак сарымсакны блендер белән издерәбез, 1 аш кашыгы үсемлек мае, тәменчә тоз өстибез.

■ Әзер «фонарьны» аркылыга кисеп, салат яфрагы түшәлгән тәлинкәгә күчерәбез һәм петрушка яфраклары белән бизәп, табынга чыгарабыз. Янына кечкенә савыт белән соус куябыз.

■ Ашларыгыз тәмле, көннәрегез ямьле булсын!


ТАТЛЫ БУКЕТ

Җиләк-җимештән ясалган татлы букет – чәчәкләрдән җыелган классик гөлләмәгә бер дигән алмаш була ала. Аны ясау серләре белән Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА бүлешә.

Барысын да шаккаттырасыгыз йә булмаса, балагызны сөендерәсегез килсә, сезгә нибарысы җиләк-җимеш, яшелчә, бераз үлән, суши таяклары, матур кәгазь кирәк. Эш ысулы гади: җиләк-җимешне юабыз, суши таягына элдерәбез, аларны бергә бәйлибез һәм матур кәгазьгә төрәбез. Менә шуның белән шул – букет әзер!



PRESSA.RU



Күзләр җитте! Күзнең үз матурлыгы, үз яме! Күр син бу алтын яфракларны, күр син бу фирүзә күк йөзен! «Сөембикә» укучыларының күптәнге дусты, алтын куллы Зөлфия САЛИМҖАНОВА, көзнең затлы бизәкләрен кулланып, бик матур брошка ясарга тәкъдим итеп тора әле менә. Японнарның борынгы «шибори» техникасында эшләнгән, күзгә «кояш нуры төшкән» брошка теләсә нинди киемне ачып җибәреп, тантаналы төс бирәчәк. Башкару өчен дә катлаулы түгел.
Брошканың зурлыгы 5,5х7,5 см.



Мастер-классны Зөлфия САЛИМҖАНОВА үткәрә.

«АЛТЫН КӨЗ» БРОШКАСЫ



Кирәк:

- 10 см озынлыктагы сары-көрән төсмерле «шибори» тасмасы;
0,5 см диаметрлы сары төсле өч түгәрәк сәйлән;
- икесе – 2 см, берсе 1,5 см зурлыгындагы сары һәм гәрәбә төсләрендәге «тамчылы» ташлар;
- 0,5 см тамчы сыман гәрәбә төсле пыяла сәйләннәр (дропслар) (10–12 данә);
- 0,5 см ачык сары төстәге пыяла биконуслар (кырлы-кырлы озынча сәйлән) (15–17 данә);
- 3 мм зурлыгындагы гәрәбә төсендәге пыяла рондельләр (кырлы-кырлы түгәрәк сәйлән) (12-13 данә);
- сары, гәрәбә, алтынсу төсендәге эреле-ваклы түгәрәк сәйләннәр;
- 1 мм зурлыгындагы кара зәйтүн төсендәге сәйләннәр (45–50 данә);
- брошканың читенә тезү өчен 1 мм зурлыгындагы сары төсле сәйләннәр (100 данәләп кирәк);
- алтын төсендәге ике каплавыч (колпачки);
- каптырма;
- 9х9 см зурлыгындагы каты фетр (моделируемый дип аталганы).
Ул булмаса, 5-6 кат ябыштырылган флизелин да ярый;
- шундый ук зурлыкта саргылт төсле күн кисәге;
- катыргы;
- үтә күренмәле нечкә кыл;
- сәйлән энәсе һәм гади тегү энәсе.



Эш барышы:

■ кәгазьдән усак яфрагы рәвешендәге шаблон кисеп алабыз. Шушы шаблонны фетр аслыкка куеп, фломастер яки маркер белән төшерәбез. Бу – булачак брошканың чикләре. «Яфрак»ның очы брошканың аскы ягы булачак.

■ Тегү энәсенә тасма төсенә ярашлы нечкә җеп саплап, тасманың бер читен тегеп бөрәбез. «Шибори» тасмасы вак-вак бөкләмнәрдән тора, бөргән вакытта һәр бөкләмне эләктерергә кирәк. Тасманың бу очын «яфрак»ның өске ягына тегеп куябыз. Аннары тасманың «яфрак»тан чыгып калган артык өлешен кисеп алабыз. Бу башын да шулай ук бөрәбез һәм фетрга тегеп беркетәбез.

■ «Яфрак» читенә тасманы вак-вак атлатып типчибез. Энәләр белән кадап куйсаң, теккәндә уңайлырак. Тасма артык кабарынкы булып калды. Аны бераз яссыландырып, яфрак рәвешенә кертү өчен, өч-дүрт җирдән энә-җеп белән фетрга чәнчеп тегеп куябыз. Пөхтә эшләргә тырышыгыз, җөйләр вак кына, беленмәслек кенә булсын.

■ Тасманың очларын фетрга теккән урынны каплавыч белән яшерәбез. Каплавыч тирәли сары төсле вак сәйләннәр тезәбез, өстен гәрәбә төсендәге сәйлән белән бизибез.

■ «Яфрак»ның урта сызыгы сәйләннәр белән чигелә. Моның өчен сәйлән энәсенә кыл саплап, фетрның сул ягыннан кадап алабыз да бер рондель һәм бер гәрәбә төсендәге сәйлән элэктереп кыйгачлап тегеп куябыз. Тасма чите җөй астында калырга тиеш. Икенче җөйне салганда энәне уң якка беренче рондельгә терәп үк чыгарабыз да янә бер рондель һәм бер сәйлән алып, кыйгач атлатып тегәбез. «Яфрак» очына җиткәнче шулай кабатлана.

■ Тасманың икенче чите тирәли, нәкъ шулай ук кыйгачлап, гәрәбә төсендәге тамчылы сәйлән (дропс) белән зәйтүн төсле вак сәйләннәр тезәбез.

■ Фетрның буш калган өлешенә тамчылы бижутерия ташларын тегеп куябыз. Аннары бер дә буш җирлек калдырмыйча, эреле-ваклы сәйләннәр «сибәбез». Монда нинди дер төгәл кагыйдәләр юк, фәкать фантазиягә генә нигезләнгән иректә эш бу.

■ Кечкенә кайчы белән «яфрак» читенә үк терәп, ләкин сәйләннәрне теккән җепләрне элэктерми генә, фетрны кисәбез.

■ Катыргы кәгазьгә шаблон ярдәмендә тагын бер «яфрак» төшерәбез. Ләкин кискән чагында аны 1-2 мм эчкәрәк кереп кисәбез. Күн кисәгеннән дә «яфрак» кисәргә кирәк булачак. Тик бу юлы инде, киресенчә, шаблоннан чак кына зуррак итеп, 1-2 мм читкәрәк чыгып кисәбез.

■ Катыргы «яфрак»ны җилем белән күн «яфрак»ның сул ягына ябыштырып куябыз. Катыргыны брошканың аскы ягы шома булсын, җепләр беленеп тормасын өчен ябыштырабыз.

■ Тегү энәсенә кыл саплап, күннең уң ягына каптырма тегелә. Каптырма тегүнең үз сере, үз үзенчәлеге бар. Түшкә беркеткәч, брошка бер якка янтаймасын өчен, каптырма аның ташлар белән бизәлгән авыр өлешенә, өске якка тегелә. Бу мөһим. Каптырманың энә тишекләрен алтын төсендәге вак сәйлән белән яшерәбез.

■ Күн «яфракны» җилем белән фетр «яфракка» ябыштырабыз. Яфракның кыры тирәли алтын төсендәге вак сәйләннәр тезәбез. Аның тәртибе болай: сәйлән энәсенә кыл саплап, фетр аша кадап, уң якка чыгарабыз һәм беренче атламда энәгә ике сәйлән элэктерәбез. Энәне янә фетр аша кадап алып, икенче сәйләннең эченнән уздырабыз. Энәгә тагын бер сәйлән элэктереп, янә фетр аша кадап алабыз. «Сөембикә» журналының 2015 елгы февраль санында без аның тәртибен бер аңлаткан идек инде. Аннан да карый аласыз. Шул рәвешле, брошка тирәли сәйләннәр тезеп чыгабыз. Инде брошкабыз әзер. Киләсе айда Әниләр бәйрәме. Бу брошка аларга бик яхшы бүләк була ала.

PRESSA.RU

Җыясы җыелган, утыртасы утыртылган, көз көне бакчада нинди эш булсын, дияргә ашыкмагыз әле. Ә агачлар, куаклар, күпьеллык чәчәкләр? Аларга да тәрбия, игътибар кирәген онытып җибәрмәдегезме?
Җимеш агачлары – бакчаның төп байлыгы. Аларны быелдан утырттың да, киләсе елдан ук уңышын җыям дип әйтә алмыйсың, җимешләреннән авыз иткәнче, кимендә өч-дүрт ел үтәчәк. Өстәвенә, яңа үсентеләр шактый ук кыйммәт, аларны табуы да мәшәкатьле. Шуңа да, булганнарын карап, кадерләп тотыйк.



КӨЗГЕ БАКЧА

Көз айлары – агач-куакларны, чәчәкләрне кышка әзерләп калдыру өчен бер дигән вакыт. Яфракларын койганнан соң, агачларга 3 процентлы бордо сыекчасы бөркесәң яхшы. Бу киләсе ел өчен авырулардан да, корткыч бөҗәкләрдән дә профилактика була. Шулай ук аларны кышка кергәнче мул итеп сугарып калдыру да файдалы. Суыкка артык чыдам булмаганнарының төбенә тирес, черемә, коры яфраклар түшәп калдырсаң, кар ятканчы ук җирдәге туң калынайса, агачларның тамырлары өшер дип куркасы булмый. Хәзер күп кенә бакчаларда җылы як кунагы булган виноград, өрек, шафталулар да үсә. 5-6 еллык алмагачларның кәүсәләрен кышка төрмәсәң дә була әле (яшьрәкләренекен капларга кирәк), әмма инде җылы яратучы нәзберекләрнең кәүсәләрен иске капчык, узган елдан калган лутрасил (махсус каплагыч материал), калын кәгазь, чүпрәкише берәр нәрсә белән чорнап калдырсаң ышанычлы. Беренчедән, салкыннан коткарса; икенчедән тычкан, куян ише кимерүчеләрдән саклый. Кәүсәне төрсәң, иртә язда караган кояш җылысында агачның кайрысы да ярылмаячак. Алмагачларның кәүсәсен кышка төрмичә дә калдырырга була дидек тә диюен, әмма җиңел сулап куярга ашыкмагыз әле. Кышын алардан куяннар авыз итәргә ярата.

■ Кышны агачларыгыз исән-имин чыксын дисәгез, менә бу катнашманы ясап карый аласыз. 300 г нафталин, 100 г бакыр купоросы, 2 л үсемлек мае, 300 г сабын һәм 400 г скипидарны 10 литр суга бутап, агач кайрысына сыларга кирәк. Кайсыбер бакчачылар кәүсә тирәсен чыршы яки нарат ботаклары белән дә каплый. Ылыс исенә кимерүчеләр килми икән.

■ Алмагач-грушаларның кәүсәләрен агарту өчен рецептның монысын кулланып карарга була: 10 л кайнар суга 2 кг сүндерелгән известь яки төелгән акбур (акбур кулланган очракта суга 100 г агач (столяр) җилеме, 1 кг кызыл балчык, 1-2 көрәк сыер тизәге дә өстәргә кирәк булыр) эретеп, шушы эремә белән агачларны акшарлыйбыз. 250 г бакыр купоросы кушарга да мөмкин. Әмма аларны суга салганда известь белән бергә кушарга ярамый. Иң яхшысы: икесен ике савытта эретеп, аннары гына бергә кушарга. Бакыр купоросы урынына агач көле дә кулланып була. Сыер тизәге кушылган акшар белән агарткан агачлар ап-ак булмаса да, бу состав агач өчен бик файдалы.

■ Кар ятканчы карлыган куакларын да кысып бәйләсәң яхшы. Югыйсә кышын ботакларга кар ятып, алар сына, имгәнә – куакның рәвеше китә. Шулай ук кура җиләге дә игътибар сорый. Бердән, ул әле салкынга да чыдамсыз. Октябрьдә аны кыскартып кисүне тәгәллиләр, төпләрен тирес белән мүлчәләп, ботакларын җиргә егып, бәйлиләр. Кышны кар астында чыккан куакларның чәчәк бөреләре өшемәгәнлектән, җимешләре эрерәк тә, күбрәк тә була.


Кучкар. Ниндидер бер бурычыгызны кайтарырга туры киләчәк. Эшегездә уңыш һәм дәрәҗә көтелә. Яңа эшкә чакыру алырга мөмкинсез. Ничек кенә булмасын, уңышлы һәм сөенечле вакыйгаларга бай ай көтелә.


Үгезбозау. Файдасы тиярдәй яңа танышыгыз барлыкка килер. Үзегезгә бик тә кирәкле мәгълүмат алырсыз. Тормышыгызның нәкъ шушы өлешендә дөньягызны яңача корырга, яңа юлдан китәргә мөмкинлек туачак.


Игезәкләр. Үзегезне күрсәтер өчен ихтыяр көчегезне тупларга туры килер. Сатурн йогынтысында, тормышыгызда күңелле үзгәрешләр булыр, алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылыр. Үзегезгә ышаныгыз, ләкин якыннарыгыз киңәшенә дә колак салыгыз.


Кысла. Тормышның күп кенә «сюрпризларына» оптимизм белән карагыз. Җитди ниятләрегезне тормышка ашырырга керешү өчен нәкъ вакыты. Максатыгызга ирешү юлында көтелмәгән мөмкинлекләр ачылачак.


Арыслан. Күңелле һәм нәтиҗәле ай көтелә. Теләсә нинди вакыйга сезнең файдага булачак. Барысы да җиңел генә хәл ителеп, тормышыгыз майлаган кебек барачак. Фәкать бер нәрсәне генә онытмагыз: бөтенесен берьюлы колачлап булмый.


Сөмбелә. Айның беренче яртысы Сатурн йогынтысында бик уңышлы узар. Икенче яртысында җиң сызганып эшләргә туры киләчәк. Тирә-юньдәгеләргә игътибарлы булыгыз, коллегаларыгызның киңәшләренә колак салыгыз.


Бизмән. Эчке тоемыгыз искиткеч! Йөрәгегезне тыңласагыз, бер дә ялгышмассыз. Ниятләрегез җиңел генә тормышка ашачак, илаһи көчләр бу айда үзләре сезгә ярдәмгә килер. Ай ахырында күңелле сюрприз көтелә.


Чаян. Көч-куәтегезне тулыландыру өчен бер дигән вакыт. Җаегыз булса, бераз ял итегез. Инде бер дә эштән туктый алмыйсыз икән, һичьюгы аралашуны киметегез. Марс планетасы тәэсирендә бераз рухи киеренкелек сизәрсез.


Укчы. Вакыйгалар өермәсе бөтереп алыр. Көч-куәтегезгә үзегез үк шаккатарсыз. Сәфәр чыгу ихтималы бик зур. Тормышыгызга йогынты ясардай искиткеч кеше белән танышырсыз. Бу ай һәр өлкәдә уңыш вәгъдә итә.


Кәҗәмөгез. Тормышыгыз үз җаена барыр, ниндидер көтелмәгән вакыйгалар күренми. Егәрегез ташып торыр, моңарчы тотынырга кыймый йөргән эшләргә алына аласыз. Айның беренче яртысында инде күптәннән көтелгән керем алырсыз.


Сукояр. Уңышлы һәм бик рәхәт ай булыр. Нәрсәгә генә тотынсагыз да, алтын итеп коярсыз. Тәвәккәл булыгыз, теләгегезне белдерүдән тартынмагыз. Планнарыгызны тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр ачылачак.


Балыклар. Тырышлыгыгыз, тайпылмыйча максатка бара белүегез үзенең нәтиҗәсен күрсәтәчәк. Тормышыгыз күпләр кызыгырлык булыр. Ай ахырында киләчәктә ярдәме тиярдәй кеше белән очрашырсыз яки бик кирәкле мәгълүматка тиенерсез.

октябрь *дә кабынган йолдызлар*

Татарстан



Гөлсем Болгарская (15.10.1896–9.01.1968) **– Татарстанның – халык, Россиянең атказанган артисты.**

Казанда туа. 1910 елдан «Сәйяр»дә эшли башлый. Совет власте урнашкач, РСФСР-ның Мөселманнар хәрби үзәк коллегиясе оештырган труппада эшли. 1922 елдан 1968 елга кадәр – Галиәсгар Камал исемендәге академия театрында (1939 нчы елга кадәр ул «Кызыл Октябрь исемендәге Татар дәүләт үрнәк драма театры» дип атала). Халык артисты исемен беренчеләрдән булып алган артистка (1923 ел). Беренче ире – актер Барый Болгарский. 1918 елда Хәмит Колмәмәт белән гаилә кора. Кызлары Фирдәвес (композитор Әнвәр Бакировның хатыны) һәм уллары Гаден туа. Беренче профессиональ артистларыбыздан булган Гөлсем Болгарская – «Почет Билгесе» һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары иясе.

Россия



Галина Вишневская (26.10.1926–11.12.2012) **– опера җырчысы, актриса.**

Санкт-Петербургта туып, Ленинград блокадасы кичерә, 16 яшеннән фронтка китә. 1943-1944 ел арасында (ярты ел) Римский-Корсаков исемендәге олылар өчен музыка мәктәбендә укый. 1944 елда Ленинград өлкәсенең оперетта театры хорына эшкә урнаша. 1952 елда исә, консерватория белеме булмаса да, Зур театрга төп солист итеп кабул ителә, Ленин ордены белән бүләкләнә. 1974 елда, А. Солженицынны яклап чыкканы өчен эзәрлекләнеп, илдән китәргә мәҗбүр була. Фәкать 1990 елда гына илгә кайтып, «Провинциальный бенефис», «Александра» фильмнарында уйный. 1984 елда аның үзе турында үзе язган «Галина» исемле китабы дөнья күрә.

Чит илләр



Кэрри Фишер (21.10.1956) **– киноактриса, сценарист, прозаик.**

Калифорниядә – актриса Дебби Рейнольдс һәм җырчы Эдди Фишер гаиләсендә туа. Сәхнә артында үскән балаларның актер булып китүе гаҗәп түгел. Кэрридан кала, бу гаиләнең тагын ике кызы да актриса. Ә менә Кэрри үзе дөньяга «Йолдызлар сугышы» фильмындагы Лея Органа роле белән танылa. Тамашачы исә аны беренче тапкыр 1973 елда – «Ирэн» мюзиклында күрә. Әдәби иҗатына килгәндә, аның әнисе белән үзара катлаулы мөнәсәбәтләре тасвирланган «Открытки с края бездны» дип аталган автобиографик романы буенча режиссер Майк Николс 1991 елда шул исемдәге фильм төшерә.

PRESSA.RU





КОЯШКА МАНЫЛГАН СУРӘТЛӘР

Җанан Бәрбәр кечкенәдән кулына кылкаләм алып, балачак күген үз төсләре белән бизи башый. Ә 1977 елда Истанбулда яшәүче 10 яшьлек төрек кызы инде Һиндстанда узган Бөтендөнья балаларының рәсем бәйгесендә катнашып, Берләшкән Милләтләр Оешмасы каршында эшләп килүче ЮНИСЕФ фондының махсус призына ия була. Кызык бит: узган ел бу фонд, әлеге рәссамның эшләрен үзенең котлау открыткаларында файдалана башлый.

Берьяклы гына рәссам түгел Бәрбәр. Аның тупланмасында киндергә иңдерелгән картиналардан тыш, сыннар, керамик эшләнмәләрне дә күрергә мөмкин.


Казанлылар исә аны үз өслүбе, үз егәре, үзенең кабатланмас җете-җылы төсләре, милли йөзе булган рәссам буларак ачты, яратып калды. Төрек рәссамының «Хәзинә» милли сәнгать галереясында узган «Салават күпере» дип аталган шәхси күргәзмәсе чыннан да җетелек, шәркыйлык, чаялык белән истә кала. Җанан Бәрбәр, әйтерсең, эшләрен салават күперенә манып-манып алган да, күзләрне камаштырырлык нур иңсен әле дип, кояшка чыгарып элгән. Чамасыз яктылык, нур бөркелә ул эшләрдән. Җитмәсә, рәссам, җаен туры китереп бик отышлы файдаланган асылташлар, төймәсәйләннәр, стразлар, көзге, пыяла кыйпылчыклары көзнең тансык кояшында җем-җем килеп, һәркайсы сиңа күз кыса. Монысы – Женевада, Лондонда Швейцариянең Adler зәркәнчелек бренды белән дизайнер буларак хезмәттәшлек итү йогынтысы. Хәер, аның көяз ханымнарын, кәләшләрен әлеге ялтыравык бизәнү әйберләреннән башка күзаллап та булмый. Рәссам иҗатында тагын бер әйбергә – мулдан «сибелгән» анар, алма кебек «символ» җимешләргә игътибар итәсең. Шул бер символ белән әллә ничә мәгънә бирә автор. Бер карыйсың, ул үзе гүзәллек алиһәсе иткән туташларының баш өстенә анар җимешләре куеп, аларны таҗлы хакимә ясый. Икенче юлы, анарның урынын алыштыра да, «минем киленнәр өлгергән-җитлеккән – алар дөньяга яңа буын тудыручылар, алар тормыш чыганагы», ди кебек. Әмма шул ук вакытта Җананның хатын-кызлары күзгә туры карарга да кыймаган оялчан, әдәпле, инсафлы затлар да әле. Тышкы яктан никадәр янып тормасыннар, күзләрендә ниндидер әйтелмәгән моң-сагыш та бар әле үзләрендә. Әмма ни генә булмасын, символларның – бу очракта анарның – янып торган төсе дә, формасы да, эчке төзелеше дә рәссам файдасына «эшли». Камиллек белән бергә уңыш-уңдырыш, гаилә бөтенлеге, үрчем, дөньяның берлегенә дә ишарә ясала монда. Тулышкан алмаларны да ул, бер карыйсың, хатын-кызның ике күкрәгенә куя, икенче юлы, «күз тимәсен» дигәндәй, анысының да хәстәрен таба. Шунда ук борынгы келәм тукучылыктан килгән яхшы теләк рәвешендәге тамга-бизәкләр дә җитәрлек бу эшләрдә. Күпме булуларына карамастан, аның тормыш тәгәрмәчләре дә, балыклары да, киленнәре дә, хатыннары, күбәләкләре дә бер-берсен һич кабатламый.

– Миңа аеруча үзем үскән, яшәгән Анатолия төбәге илһам бирә. Төрле тамга-символларны да шушы җирдән алам, – ди рәссам. Һәм ул Казанны да яратып, кабат күрешүгә өмет белән китә.

Расиха ФАИЗОВА









«Дәрвишләр биюе»
«Кошлы кыз»
«Мәхәббәт»
«Архаик мәхәббәт»
«Анар»

ҖАНАН БӘРБӘР

PRESSA.RU



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204

13–23 октябрь көннәрендә «Почта России»ның барлык почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз!

Әниләр көненә бүләк эзләгәндә «Сөембикә»не сайлагыз!



Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин.



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+